1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН



2015 ИЮЛЬ № 7

Сөембикә

БАРГАН ҖИРЕНДӘ ТАШ БУЛ
бәхетле гаиләләр күбрәк

МӘХӘББӘТ ХАТЛАРЫ
моңлы язмыш

ЭЛЬМИРА ИСМӘГЫЙЛЕВА СЫЙЛЫЙ:
ташкабак «торт»ы

Гөлшат МАЛЫШЕВА:

«ЮГАРЫДА ДА ГАДИ КАЛА АЛГАННАРГА СОКЛАНАМ»





70
1945–2015

Сугыш язган хатлар

Аларның әтиләре Фатыйх ага Адаматов Апас районының иң зыялы, алдынгы карашлы кешеләренең берсе була. 1932-1938 елларда ул «Бригадир» газетасының редакторы булып эшли, аннан райкомга күчә. Хатыны Срур белән алар җиде бала тәрбияләп үстерәләр. 1923 елны туган уллары Мәсгут Казан химия-технология техникумына укырга керә. Өченче курстан соң аны Апаска окоп казырга җибәрәләр. 1942 елның җәендә исә сугышка алына. 1943 елның 11 февралендә соңгы хаты килә... 1925 елгы Дәүләт тә абыйсы укыган техникумга керә. Армиягә ул 1943 елны китә. Ижауда артиллерия училищесында укый. Балтыйк буе илләрен азат итүдә катнаша. Соңгы хаты 1945 елның 18 мартында килә, ә 25 мартта ул геройларча һәлак була...

«Исәнмесез кадерлеләрем әткәй, әнкәй, шулай ук барлык туганнарым! Сезнең барыгызга да миннән бик тә күп сагынычлы сәламнәр язам. Сәлам соңында үзем исән-сау, шулай ук сезне дә исән-саулар дип белеп калам. 4 дә язган хатыгызны бүген алып укып, бар язылган хәбәрләрне дә белдем. Мин үзем шулай бер килеш исән-сау яшәп ятам әлегә. Укулар гел бер килеш, ныклы адым белән алга баруын дәвам итә. Ашау-эчү яклары да шулай ук үзгәрешсез, начар түгел. Хәзер, билгеле, көз вакыты, ашлар да күбрәк яшелчәдән тора, шулай да начар түгел. Әнкәй! Бер дә хат алганым юк дип зарланып язасың. Мин һәрвакыт хатлар язып торам. Алар сезгә кичегеп бара торганнардыр, шуңарга бер дә алганым юк дип язасыз булыр. Кичә безнең ял көне иде, бәйрәм көн. Хәрби ант кабул иттек. Кичәдән башлап мин чын кызылармеец инде. Апастан хат алган юк әле бу арада бер дә. Бабайларга да күптән түгел генә хат салган идем. Ярый, хушыгыз, миндә артык язарлык үзгәрешләр юк. Исән-сау яшәвегезне теләп калучы улыгыз Мәсгут. 14 сентябрь, 1942 ел.»

«Бер атнага якын вакыт язарга мөмкинлек булмады. Шундый кыенрак урында булырга туры килде. Сез хат булмаганга кайгырмагыз. Минем белән берни дә булмас. Син, әнкәй, һәр хат саен хатыңны часто яз, дип сорыйсың, мин мөмкин кадәр язарга тырышырмын. Бу арада бер урыннан икенче урынга күчеп йөрергә туры килде. Бүгенге көндә прямой наводкадан немецтан ерак кына түгел торабыз. Рәтле эш юк диярлек, чөнки күп йөрергә ярамый. Төннәрен күбесендә йөрергә туры килә. Менә шулай бер килеш кенә тормыш үтә. Тиздән немец та капут булыр. Ашау яклары монда җитәрлек. Мәхмүт һаман да шул урындамы икән? Аңа әллә ничә хат язган идем, но аңардан җавап алмадым әле. Сездә хәзер тормыш ничек соң? Былтыргыга караганда яхшыракмы? Быел яхшырак дип уйлыйм.

Ярар! Минем башка үзгәрешләр юк. Тормышым начар түгел, начальство белән ничево торам. Сау булыгыз! Сәлам белән Дәүләт. 3 март, 1945 ел. Хатны тагын кыска яза ди торгансыздыр инде.»

«Исәнмесез! Әткәй, әнкәй, шулай ук барлык туганнарым! Миннән сезгә күп сагынычлы сәламнәр язып калам. Сәлам соңында сезнең соңгы хатларыгызны алып укыдым. Сездән хатларны бу арада күп алгаладым. Но шулай да сез миңа тагын хат сирәк яза ди торгансыздыр. Минем тормыш пока шул килеш кенә. Элеккечә оборонада торабыз. Хәзер минем занятиеләр дә юк. Көннәр монда җылынды. Атнага якын зур салкыннар һәм бураннар булды. Но хәзер тагын җылынды. Кар эреп бетте диярлек. Землянка да җылы, зур. Немецлар ясаган землянкада урнаштык пока. Шулай бер килеш кенә торабыз. Ярар! Минем башка сүзем юк. Сау булыгыз! Сәламнәр белән Дәүләт. 14.03.45.»

Мәсгут белән Дәүләттән килгән 47 хатны
Апас районының туган якны өйрәнү музеена
сеңелләре Роза АДАМАТОВА тапшырган.
Хатлар кыскартылып, үзгәртелмичә бирелә.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Гаиләгездә фронттан килгән хатлар саклана икән, редакциягә җибәрә аласыз. Хатларны сайтыбызда (www.syuyumbike.ru), ә иң кызыклыларын журналда бастырырбыз. Сайтыбыз аша сугыш кырларында ятып калган якыннарыгыз турында мәгълүмат таба аласыз.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!





© «Сөембикә» 2015

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сюембике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814



2007, 2008, 2009 елларда журнал Россия матбугатының Алтын фондына кертелде.

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте



Директор-баш мөхәррир
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Нурия Беломоина, Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Розалина Шаһиева, Гөлназ Шәйхи.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77
Директор урынбасары
Рәмзия Кашапова 222-09-78
Баш мөхәррир урынбасары
Гөлнур Хәсәншина 222-09-78
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Сайт мөхәррире:
Сөмбел Гаффарова



Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Гөлшат Малышева
Фото: Анна Арахамия

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Роза Камалетдинова
Асия Юнысова
Фотокорреспондент
Газинур Хафизов
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы: 73002

Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ, 420097, Казан, Академия урамы, 2

Кәгазь форматы 60х90 1/8.
Күләме 8 басма табак.

Басарга кул куелды: 7.07.2015 ел.
Заказ О-1786.
Тираж 6156.

ТР Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Журналны тарату мәсьәләләре белән абунәчеләр – җирле элемтә бүлегенә; элемтә бүлекләре – нәшриятның газета-журнал экспедициясенә (420066, Декабристлар урамы, 2 нче йорт. Тел.: 562-10-66) мөрәҗәгать итә ала.

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
р/с 40702810700000005657
к/с 30101810100000000815
в АИКБ «Татфондбанк» г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205815
КПП 165802002

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Казан, Декабристлар урамы, 2.

Журналда полиграфия кимчелеге булган очракта нәшриятның техник контроль бүлегенә мөрәҗәгать итегез. Тел.: 519-44-61.

Сатуда бәясе ирекле.

Сәкинә ХӘЙРУЛЛИНА

Җәй уртасы

Җәйнең кыл уртасы җитте,
Такыя үрә болын.
Туйганчы сулыйсы килә
Яшел үләннәр тынын.

Иң рәхәт ямьле дөнья бу,
Иң-иң хозур патшалык.
Яланаяк чирәменнән
Атлап йөрим таң калып.

Туган җиремнең җылысы
Буыннарга тарала.
Сөял, диеп иңен куя
Мәһабәт карт карама.

Җилдә тибрәлгән чәчкәләр
Серләшәләр шикелле.
Гөлбадран йөзенә яткан
Җәйнең сары сипкеле.

Шулчак кошлар җыр сузалар,
Яфраклар лепердәшә.
Җәйге урман, иркен болын
Сердәш булырга дәшә.

Чистарып кала күңелләр,
Яшәрүе бу җанның.
Әйтерсең, гомерләрнең дә
Кыл уртасында калдым.



«Ясмин». Ольга Сушкова эше.





БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА







16 АЛТЫН ҖИРДӘ ЯТМАС
Г. Сафиуллина

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ





8 БӘХЕТЛЕ ГАИЛӘЛӘР КҮБРӘК
Ф. Мостафина



20 БӨРТЕГЕ ДӘ КАДЕРЛЕ
М. Авзалова

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ





24 ИСЕМЕМ БУЛСЫН САТУЧЫ...
Г. Сафиуллина



28 КИЛЕН СӘЛАМЕ
Р. Кашапова

ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



36 ЙОЛА
А. Хәсәнова

ЯШӘЕШ 



48 СОҢГЫ ХЫЯНӘТ
Э. Закирова



52 МӘХӘББӘТ ХАТЛАРЫ
А. Сәгыйтова

ШУЛАЙ УК: 

30 КҮЗ ЯШЬЛӘРЕ БЕЛӘН...
С. Чанышева

44 ТЕЛИ БЕЛСӘҢ, ТЕЛӘК...
М. Кашапова

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 



58 ГАЕТ БҮЛӘГЕ

КИЛӘСЕ САНЫБЫЗДА: 

КҮКТӘ... БИШ МЕҢ СӘГАТЬ! Милләттәш

Рифә Рахман. ТОЛЫМ. Хикәя

«ЗИНҺАР ӨЧЕН, КЕРМӘ ТӨШЛӘРЕМӘ»

КҮҢЕЛ БИЗМӘНЕ: БАЛАМЫ, МӘХӘББӘТМЕ

ЧИГЕЛГӘН КҮН ЯНЧЫК: мастер-класс





Сугыш тәмамланганга – 70 ел. Сугыш ветераннары гына түгел, ә шул афәт аркасында ялгыз картайган апалар да берән-сәрән генә калып бара инде. Бу хатым шундый ике апа, ике олуг зат – Гатина Мөхтәрәмә һәм Йосыпова Минҗан хакында.

Сугыш башланганда Мөхтәрәмә апага 26 яшь була. Радиодан «Миңлекамал» спектаклен тыңлаганда мин гел аны күз алдына китерәм. Зифа буйлы иде ул. Озын буйлы кызларга авылда яр табуы авыр. Шулай да сугыш алдыннан күңеленә ошаган кешене очрата Мөхтәрәмә апа. 1941 елның 22 июнендә егет аны сорый килергә тиеш була. Әмма... беренче көннән үк сугышка китеп югала ул.

Мөхтәрәмә апа тулысы белән колхоз йөгенә җигелә. Башкалардан күбрәк күтәрә, күбрәк эшли. Мин белгәндә дә әле һәммәсе аны һаман җигелеп эшләргә тиеш дип кабул итә иде. Потлы-потлы капчыкларны берүзе җилтерәтеп кенә йөртә иде ул. Ә янындагы тап-таза ирләр (сугыштан исән кайтканнары да, сугыштан соң үсеп җиткәннәре дә) тыныч кына аның эшләгәнен карап тора. «Тукта, авыр күтәрмә!» – дип берсе-бер әйтми иде.

Ул чорларда орлыклык ашлыкны саклауга тимер подаукалар белән санап салалар иде. Иләнгән орлыкны тирән такта арба белән китерәләр. Мөхтәрәмә апа шуны подаука белән берүзе амбарга бушата. Подаука саны белән орлыкның исәбен чыгара. Бер подаукада 16 кг икмәк?! Көнозын шуның кадәр йөк бушатып, ничек түзде икән ул? Кышларын Мөхтәрәмә апа кырдагы эскертләрдән печән, салам ташый. Ярдәмчесе Минҗан апа олау башында тора. Әнә шулай, дәшми-тынмый гына, кая кушсалар, шунда «җигелеп» эшләде алар.

Күпне таләп итми, рәхмәт-кадер сорамый, беркемгә дә мәшәкать китерми яшәделәр. Сугыш беткәч, кияүгә чыксалар да булыр иде. Ләкин... Мөхтәрәмә апаның кулында 80 яшьлек гарип әнисе – Минсара әби һәм яшьли вафат булган апасы Бибиһаҗәрнен өч нарасые. Балаларның әтиләре яхшы кеше дә бит, әмма йомшак. Ә үги әни чын мәгънәсендә үги. Балалар Мөхтәрәмә апа ярдәме белән үсеп, югары белем алдылар. Мөхтәрәмә апаның болай да җиңел булмаган тормышын абыйсы Габделхакның әсирлеккә эләгүе дә катлауландырды. Алай да беркайчан зарланмады, кешеләрне һәрчак үз итте. Бик укымышлы, зирәк кеше иде ул. Китапханәдә ул укымаган китап булмагандыр. Ындыр табагында яки басуда эшләгәндә укыган китапларын безгә дә сөйли иде.

Ә сандыгында... кияүгә чыгарга дип әзерләгән бирнәсе ятты. Гомере буе саклады ул аны. Чигүле аякчулар, ирләр күлмәге, урын-җир әйберләре һәм үзе чиккән искитмәле матур туй күлмәге... Ул бу матурлыкны елга бер тапкыр тыштагы бауга җилләтергә элә иде... һәм һәр елны бер үк көндә – 22 июньдә. Мин моңа хәзер генә игътибар иттем, ә ул вакытта уйлый да белмәгәнмен. Без читән кырыена тезелешеп, баудагы матурлыкка сокланабыз. Аеруча истә калганы шул – ул бизәкләрнең күбесе зәңгәр чәчәк һәм сары башак иде...

Күп еллар безнең гаиләнең дә терәге, ярдәмчесе булды Мөхтәрәмә апа. Минем инәй аларның килене иде. Әтине белмәдем мин. Өч сугыштан исән-сау кайткан әтием – Хәмзә Шәрип улын мулла нәселе, сәүдәгәр калдыгы дип, илленче елларда туган җиреннән сөргәннәр. Инәй 3 бала белән калган. Без Мөхтәрәмә апалар белән янәшә йортларда яшәдек. Безгә күз-колак булучы да, тәрбия бирүче дә, кул эшләренә өйрәтүче дә – Минсара әби белән Мөхтәрәмә апа булды.

Мөхтәрәмә апа озын буйлы булса, Минҗан апа, киресенчә – бик кыска буйлы иде. Сеңелләре бер-бер артлы кияүгә киткәч, Минҗан апа авыру әнисе белән гарип әтисен, кече сеңлесен карап кала. Инде тормыш җайлана дигәндә, курчак кебек чибәр сеңлесе бәхетсезлеккә юлыга. Авылга килгән уполномоченный ир ябь-яшь кызны мәсхәрәләп ташлап китә. Авыл җирендә бик сирәк була торган, нәселгә кара тап төшерерлек бу хәлдән чарасыз кала Минҗан апа. Тик нишлисең, башны ташка орып булмый. Чарасын күреп карыйлар да бит, туасы җан барыбер туа... Малайны үзенә алып калып, сеңлесен читкә озата Минҗан апа. Әмма бәхетсезлек барыбер үзенекен итә – бик тере булып туган бу малайның, үсә-үсә, бер күзе сукырая,

колагы ишетми башлый, сөйләме начарлана. Көндәлек авыл тормышын үз җилкәсендә күтәреп, этиәнисен дә, гарип энесен дә сыкранмый-нитми карый Минҗан апа. Малай үсә, Минҗан апаның карт көнендә таянычы, ярдәмчесе булып өлгерә.

Инде Минҗан апа да, Мөхтәрәмә апа да бу дөньяда юк.

Үзем авыл клубында эшләгән елларда ветераннарга багышлап бик күп чаралар үткәрә идем. Шулай бер-ике тапкыр «Сугыш толлары» дигән тематик кичә үткәреп, Мөхтәрәмә апа белән Минҗан апаны да чакырдым. Шунда аларның әйткән бер җөмләсе мине бик гаҗәпкә калдырды. «И иркәм, безнең хакта сөйләмә син. Безгә, Аллага шөкер, яшәү күпкә җиңелрәк булды. Сугышта ирләребез үлмәде, эшкә баргач, балаларыбыз ач-ялангач дип өзелмәдек... Шуңа үзебезне гаепле итеп сизгән вакытлар да булды. Үткән – үткән инде, үкенмибез, шулай тиеш булгандыр... Тик ир җилкәсенә башны куеп бер елый алмавыбызга һәм яраткан кешедән туган балабызны имезү насыйп булмавына үзәк өзелә. Без дә бит хатын-кыз!»

Сүзен сүзгә җиткерсәм дә, аларның күз карашын, үкенү, кимсенү, шундый язмышка дучар булуларына әрнүләрен биреп җиткерә алмам...

Гөлсия ШӘРИПОВА.
Лениногорск районы,
Иске Иштерәк авылы.

Җиңү көннәре җитсә, күңелем иң якын кешеләрем: әбиемне, әткәй-әнкәй, туганнарымны юксына. Алар күптән бу дөньяда юк инде.

Хәлемнән килсә, ак яулыклы, чуар күлмәкле, йөзләрен мең җыерчык бизәгән әбиемне утыртып, авыл уртасына һәйкәл куяр идем. Алар бабам Ибраһим белән биш ир бала үстергән. Бабам үзе бик иртә дөнья куйган. Уллары исә, бернәрсәгә дә карамый, белемгә омтылган. Өченче уллары Әсгать ике энесе белән Казанда ук укыганнар. Сугыш башланганда Әсгать абый Белоруссия чигендә хезмәт иткән. Ул сугышка шуннан гына кергән. Әтием Гаянур белән Шаһинур абыйны да беренче көннән үк сугышка алганнар. Аларны берсеннән-берсе кечерәк балалары озатып калган. Әткәй сугышка киткәндә, мин – алтынчысы – әле туарга да өлгермәгәнмен. Әсгать абыйдан нибары бер хат килгән: «Үлем беркемне дә аямый. Чигенәбез, корал җитми», – дип язган ул. Әбиемнең Казанда юридик техникумда укучы ике улы исә төрле районнарга тикшерүче итеп билгеләнгән. Бераздан аларны да сугышка алганнар. Шулай итеп, әбиемнең биш баласы да Ватанны саклауга үз өлешләрен керткән.

Сугыш вакытында безне ач үлемнән иң олы абыем Фәнһәр саклап калды дисәм, һич арттыру булмас. Сыерга кыш чыгарлык печән әзерләү, кышлык утын булдыру 12 яшьлек шушы абыем өстендә булды. Апрель аеннан ук аның үзен дә колхозга эшкә чакыралар иде.

Әбиемнең сугышка киткән биш баласыннан тик безнең әткәй генә әйләнеп кайтты. Калганнарыннан хәбәр булып кара мөһерле хатлар гына килде. Кайтмый калган дүрт улын сугыштан соң тагын егерме еллап көтте әле әби. Капка шыгырдаса да, тәрәзәгә җил кагылып китсә дә, улларым, дип йөгереп чыгар иде. Әткәй исә сугышта күргәннәрен безгә бер кинофильм кебек итеп сөйли торган иде. 1903 елгы әтине яшь солдатлар «бабай» дип йөрткәннәр. Бик каты бәрелеш алдыннан: «Бабай, Коръән укы әле», – дип сорый торган булганнар. Бер төнне әткәй, атка төяп, сугыш коралларын алгы сызыкка күчерә киткән. Юлда бик каты шартлау булып, әткәйне әллә кая алып ташлаган. «Аңыма килсәм, – дип сөйли иде ул, – ярты гәүдәм кар астында, аягым сынган. Туарылган атым янәшәмдә басып тора». Иптәшләре аны аты кешнәгән тавышка килеп тапкан. Сугыштан соң ул төрле эшләрдә эшләде. Алты бала янына тагын ике сеңлебез туып, без бер малай, җиде кыз үстек. Инде дөньялар әйбәтләнә дигәндә, сугыштан кайта алмаган Шаһинур абыйның хатыны Нурия җиңгәбез үпкә чиреннән дөнья куйды. Ятим калган дүрт сабыйны үстерергә дип, әбием аларга күченде. Ике кечкенә баланы, туберкулезлы кеше белән контактта булган өчен, дип, балалар йортына алып киттеләр. Әткәй аларны да җәй көне үзебезгә алып кайта торган иде. Ул вакытларда безнең йорт алды пионер лагерендагы кебек, бала-чага белән тулы була торган иде. Әнкәем Рабига бик тыныч холыклы, бала җанлы кеше булды. Безгә – җиде кызына матур күлмәкләр тегеп кидерә, оекбашлар, шәлләр бәйли иде. Болар өстенә бер көн дә колхоз эшен дә калдырмады. Еш кына Әсгать абыйның хатыны Мөкәррәмә апа белән кызы Динара да кунакка кайталар иде. Мөкәррәмә апаның Әсгать абыйны эзләтеп төрле җирләргә язган хатына: «Подполковник Галәветдинов Әсгать батырларча һәлак булды», – дигән җавап кына килеп ирешә. «Кайчан? Кайда?» сорауларына әле дә җавап юк. Әбием исә яу кырында ятып калган улларын гел сагынып, алар өчен кайгырып яшәде. «Яткан җирләрегез кайдадыр, кәфенегез дә юк, ясинегез дә», – дип, аларга атап догалар кылыр иде. Дүрт баласын сугыш йоткан әбиемнең берәр төрле пособие алганын хәтерләмим. 1965 елда колхозчыларга пенсия бирелә башлагач, аңа да, сигез бала үстергән әнкәйгә дә 12 сум пенсия билгеләнде. Әткәй гел авыр эшләрдә эшләде. Ахырдан аякларында гангрена булып үлеп китте. Әбием исә күп елаудан күзләре сукыраеп, аяклары сызлап, 90 яшенә кадәр яшәде. Инде минем үземә дә хәзер 73 яшь. 30 ел балалар йортында тәрбияче булып эшләдем. Бу язмамны әти-әнием, әбием, сугыштан кайтмаган абыйларым турында бер истәлек булып калсын дип язам.

Лениза ӘМИРХАНОВА.
Башкортстан.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан,
Декабристлар урамы, 2.
e-mail: ssuum@yandex.ru

Нәрсә соң ул гаилә? Бу сорауны тигез гаиләдә үскән сабыйга бирсәң, ул кулына төсле каләмнәр алып, сурәт ясарга утырачак. Кәгазь уртасында әти белән әни, алар балаларын җитәкләгән. Күктә кояш елмая, аяк астында аллы-гөлле чәчәкләр үсә. Кыскасы, сурәтнең һәр өлешеннән бәхет бөркелә. Сабый гаиләне шулай күрә, шулай булырга тиеш дип уйлый, аның бөтенлеген сакларга тырыша. Гаиләнең традицион асылын саклау өчен зур тырышлык күрсәтә торган бер катлам бар. Болар – гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе (загс) хезмәткәрләре. Шул хакта загс идарәсе башлыгы Альбина Рафаил кызы ШӘВӘЛИЕВА белән әңгәмә кордык.



Фәнзилә МОСТАФИНА



АЛЬБИНА ШӘВӘЛИЕВА: «БӘХЕТЛЕ ГАИЛӘЛӘР КҮБРӘК»

«Мин традицион гаилә яклы»

Революциягә кадәрге Россиядә никахлашу турында бердәм закон булмаган. Өйләнешү-кавышу дини кануннарга нигезләнеп башкарылган. Бөтен гражданнар өчен дә бердәм канун кертелү, сезнеңчә, дөрес гамәл булганмы, Альбина ханым?

– Патша Россиясендә һәр чиркәүдә, һәр мәчеттә махсус «Метрика кенәгәсе» алып барылган: анда никахларны да, бала тууны да, кешенең үлемен дә теркәп барганнар. Хәзер бу эшләрне загс башкара. Ир белән хатынның бер-берсен ошатып, бер түбә астында яши башлавы гына гаилә дип танyла алмый. Никахны рәсми рәвештә теркәү милек статусын башка дәрәҗәгә чыгара (гаиләдә табылган милек уртак булып санала башлый), шул гаиләдә туган балаларның ата-анасы белән бәйләнешен ачыклау җиңеләя.

Бүген загста язылышуга паспорттагы мөһер дип кенә карауучылар, никах укытып кына яшәүчеләр бар...

– Гражданлык никахы – загс органында теркәлгән никах ул. Хәзер бу төшенчәне дөрес аңламыйлар. Рәсми рәвештә язылышмый бергә яшәүне гражданлык никахы диләр. Ә мин үзем загста язылышып, никах укылып төзелгән гаилә яклы. Ата, ир кеше үз бурычларын болай да таный икән – бик әйбәт. Әмма хокукый яктан – хатыны, балалары алдындагы бурычларына, уртак милеккә карата – аларны загста язылышу гына рәсмиләштерә.

Хәзер гаилә институты нәрсәгә таянып тора икән: мәхәббәтме ул, нәсел калдыру теләгеме, гадәтме?

– Бик борынгы заманнардан шулай килә: һәр кеше үзенең тиң ярын очратырга тели. Шуңа күрә, минемчә, идеаль гаилә мәхәббәттән башлана, аннан

соң нәсел дәвамчылары – балалар туа. Ата-ана булган ир белән хатын гомер буе бер-берсенә терәк булып яши. Һәрхәлдә, шулай булырга тиеш. Гаилә – кеше тормышындагы иң кадерле нәрсә, дип юкка гына әйтмибез бит.

Загс хезмәткәрләре яшьләрнең ни өчен өйләнешергә теләве белән кызыксынамы?

– Загс органнары каршында яшь гаилә мәктәпләре эшләп килә. Аның эшендә загс хезмәткәрләре генә түгел, читтән чакырылган белгечләр дә катнаша. Алар гаилә юлында очрарга мөмкин булган хәлләрдән чыгу юлын өйрәтә. Социаль ярдәм күрсәтү органнары белән берлектә эшләнгән «Гаиләгә психологик ярдәм күрсәтү» дигән проектыбыз бар. Нindидер авырлыклар белән очрашкан гаиләләргә генә түгел, өйләнешергә гариза биргән яшь парларга да психолог кирәк ул. Шуннан соң гаилә мөнәсәбәтләренең нәрсә икәнен яхшырак аңлыйсың. Еш кына бер-берсен яраткан парлар загска канатланып килеп, гариза калдыра, өйләнешә, тик күпмедер вакыттан соң мөнәсәбәтләре чатный, төрле авырлыклар барлыкка килә. Психолог менә шундый киртәләрне әйләнеп үтү яки бергәләп хәл итү юлларын эзләргә ярдәм итә дә инде.

Яшьләр белән очрашуга озак еллар бергә гомер иткән гаиләләрне дә чакырабыз. Алар бәхетле гаилә төзү серләрен уртаклаша.

«Аерылышуларны булдырмаска тырышабыз»

Гаилә туганда гына түгел, ул таркалганда да загс хезмәткәрләре үз сүзен әйтә...

– Балигъ булмаган балалы гаилә суд карары нигезендә генә аерылыша ала. Барлык аерылышуларның 20 проценты – загста, калган 80 проценты суд карары нигезендә башкарыла.

Парларның гаризасын кабул итеп, моның белән ризалашырга да булыр иде. Тик без гаиләнең таркалуын читтән генә карап тора алмыйбыз. Бу юлы да аерылышырга теләгән бу икәүгә психолог ярдәме тәкъдим итәбез. Шунысы куанычлы: психологтан соң аерылышырга теләүчеләр саны шактый кими. Алар яңадан татулашып яши башлый, балалары туа. Хәзер Россиядә ир белән хатын аерылышканда арадашчы ярдәме күрсәтү гамәлгә кереп килә. Аның вазыйфасы – низагны судка кадәр җиткермичә тыныч кына хәл итү. Тиздән загста шундый хезмәтне үзебез булдырырга уйлыйбыз.

Соңгы елларда аерылышулар саны кими башлады. Бәлки, моңа кайбер белем бирү йортларында «Гаиләне алып бару» дигән дәресләр кертү дә ярдәм итәдер.

Бала хакына дип, яисә кеше сүзеннән куркып кына бергә яшәүче бәхетсез гаиләләр дә бар...

– Минемчә, хәзер андый гаиләләр юктыр. 50–60 ел элек аерылышу гайре табигый күренеш саналган, җәмгыятьтә ачыктан-ачык гаеп ителгән. Шуңа күрә парлар бер-берсен яратмасалар да, бала хакы, уртак



■ **Белеме:** 1999 елда В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетын тәмамлаган, юрист.
■ **Гаилә хәле:** кияүдә, ике бала анасы.
■ **Гаилә бәхетенең сере:** «Бер-береңне тыңлый һәм ишетә белүдә, бер-берең турында кайгыртып яшәүдә, иреңнең йә хатыныңның тормышын әйбәтрәк итү өчен сабырлык күрсәтеп барысын да эшләүдә ул. Балаларның шат көлүе яңгырап торган гаилә – әлбәттә, бәхетле гаилә!»

милек, дип, гаилә булып яшәвен дәвам иткән. Хәзер җәмгыять аерылышуга җиңел карый.

Һәр кеше бәхетле гаилә төзү турында хыяллана. Әти-әни бәхетле булса, балалар да шат, алар тиешле тәрбия ала, гаиләдә матур үрнәк күреп үсеп, үзләре дә бәхетле гаилә төзү турында уйлый башлый. Аерылышуларның кимүе республикада бәхетле гаиләләр күбәйгән дип уйларга нигез бирә.

Гаиләдә авырлыксыз булмый, аларны бергәләп хәл итәргә өйрәнергә кирәк.

Заманында кызларны: «Барган җиреңдә таш бул», – дип кияүгә биргәннәр. Бүген өйләнешмәс борын аерылышу ихтималын уйлап куялар. «Никах килешүе» төземәсләр иде югыйсә...

– «Никах килешүе»н юрист төзи. Һәм ул нотариаль конторада раслана. Без кызыксынган парларга «Никах килешүе»н кайда төзеп булуы турында мәгълүмат кына бирәбез. Гаилә рәсми рәвештә теркәлгәннән соң, әлеге документ үз көченә керә. Килешү белән кызыксынучылар бар, шулай да күп түгел. Барыбер Россия өчен яңа күренеш әле бу.

Соңгы вакытта республикада күп хатынлылык турында сүзләр куера. Аны шәригать кануннары гына түгел, дөньяви законнар да танырга тиеш, дигән фикерләр бар...

– «РФ Гаилә кодексы»нда партнерның башка берәү белән никахта торуы гаилә коруга каршылык булып санала. Законда язылганча, гаиләдә бары тик бер генә ир һәм бер генә хатын булырга тиеш, минемчә.

Россия гражданнары өйләнешү турында гариза биргәндә загска паспорт белән килә, анда гаилә хәле турында аерым бит бар. Чит ил гражданнарына да шундый ук таләп: безгә килгәндә кулларында гаилә хәле турында документ булырга тиеш. Ирнең йә хатынның әле өзелмәгән никахы барлыгы беленсә, РФ кануннары нигезендә, икенче никахны теркәүдән баш тартабыз.

Күп милләтле Татарстанда катнаш никах та шактый киң таралган күренеш бит әле. Гомумән, бу проблемамы, әллә моңа күнегергә вакытмы инде?

Фото интернеттан алынды

Казанның 129 нчы һәм 93 нче гимназияләрендә ике ел элек тәҗрибә рәвешендә «Гаиләне алып бару» фәне кертелгән иде. Узган ел әлеге курс республиканың 422 белем бирү йортында укытыла башлаган. Хәзер проектның авторлары югары сыйныфлар өчен дәреслек әзерләү белән мәшгуль. «Мәрхәмәт» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе «Гаиләне алып бару» курсын барлык урта белем бирү йортларына да кертергә тәкъдим итә. Әлеге фән белән техникум һәм көллиятләр дә кызыксынган. Бүгенгә 370 укытучы «Гаиләне алып бару» фәнен укыту буенча өйрәнү курсын узган, сентябрьдә тагын 80 педагог әлеге рәтне тулыландырачак.

– Бу проблема түгел. Республикада теркәлә торган никахларның күпчелеге – бер милләт вәкилләре арасында. Бу елның беренче июненә кадәр 8032 никах теркәлгән булса, шуның 1623 е генә катнаш. Барлык никахларның 20 проценты дигән сүз бу.

Хәзер ирләр дә, хатын-кызлар да җитәрлек, тиң ярыңны очратырга һәм бәхетле гаилә корырга мөмкин.

Туганнан үлгәнгә кадәр

«Гаилә балалардан башлана», дигән А. Герцен. Республиканың демографик хәле турында да әйтеп китегез әле, Альбина ханым.

– Соңгы елларда бездә балалар туу арта. Бу юнәлештә дәүләт дәрәҗәсендә күп эш башкарыла, икенче һәм аннан соңгы балаларга матди ярдәм күрсәтүнең дә нәтиҗәсе һичшиксез бар.

Заман белән бергә, балага куша торган исемнәр дә үзгәрә. Совет заманында Энгель, Октябрина, Тракторлар яңалык булып килеп керде, әле кайчан гына Рим, Роберт, Эльвиралар ят исем кебек тоела иде. 2014 елда сабыйларга кушылган исемнәр арасында бөтенләй колакны торгызырдайлары бар: Ямпиха, Зевс, Ахиллес, Олимпиада... Үзенчәлекле исем куштырырга теләүчеләргә загста нинди мөнәсәбәт?

– Хәзер яшьләрнең фантазиясе бик бай, нинди генә исем уйлап тапмыйлар! Алынма исемнәрне күп кушалар, мөселманнар – шәрыкка, православлар гарепкә иярә. Гайшә-Фатыйма кебек куш исемнәр кушу шулай ук киң тарала бара. Мондый очракта загс хезмәткәрләре каршы килми, исемне терки. Тик кайвакыт әти-әниләргә сүзлекләр биреп, алар сайлаган исемнең мәгънәсен карарга тәкъдим итәбез. Мәгънәсен белми генә исем кушу күңелсез нәтиҗәгә китерергә мөмкин бит.

Хәзер туу турында таныклыкны бала тудыру йортыннан ук алып чыгалар. Республика шәһәрләрендәге һәр бала тудыру йортында загс хезмәткәре утыра. Әти-әниләр сабыйга инде исем сайлаган булсалар, шунда ук таныклыкны кулга тоттыралар. Районнарда загс хезмәткәрләре бала тудыру йортына барып, туу турында таныклыкны теркәп бирә. 80 процент бала исемне һәм таныклыкны бала тудыру йортыннан ук алып чыга.

Рәсми документ алганнан соң, исем кушу тантанасын бәйрәм итү өчен загска мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Бу вакытта инде әни кеше бераз хәл алган була; әбибабайларны, якын туганнарны да чакыралар. Мондый тантаналарда әти-әниләр сайлаган исем турында сөйлибез, чараны бәйрәм рухында уздырабыз. Бу яңа йоланы Санкт-Петербург шәһәреннән оттык без. Анда бик матур «Сабыйлар сарае» бар. Ул бала тууны теркәү белән генә шөгыльләнә. Без дә бу йоланы кертергә телибез.

Исем алыштырулар да күбәйгән. 2015 елның беренче кварталына китерелгән хисаптан күренгәнчә, Яшел Үзәндә – 12, Арчада – 8, Чистай белән Зәйдә – 7, Казанда 148 исем алыштыру очрагы теркәлгән. Исемен үзгәртергә теләгән кешедән сәбәбен сорыйсызмы?

– Гариза бланкында «Исем алыштыруның сәбәбе» дигән пункт бар, кеше аны тутырырга тиеш. Исем алыштыру дигәндә фамилияне һәм әтисенең исемен алыштыру да күздә тотыла. Өйләнешкәндә хатыны ир фамилиясен алмаган була, тик бераздан уртак фамилиягә күчәргә тели – күпчелеге шундый эшләр. Исемен ошатмыйча алыштыру да бар.

Алтын туйларын билгеләп үтүче парларны загска чакырып, алар өчен тантана уздырулар да бар. Андый гаиләләр күпме?

– 2014 елда республикада 1773 пар алтын туйларын билгеләп үткән. 60 ел гаилә булып яшәп, «бриллиант туй»ларын билгеләүче гаиләләрнең саны 369 булган.

киңәш



«Әгәр дә мәгәр, бүген-иртәгә, сиңа: «Миңа кияүгә чыгасыңмы?» – дисәләр, нишләр идең? Шатланыр идең әлбәттә! Ә аннары? Аннары әбиләрдән калган гадәт буенча «туй мәшәкате» дип аталган баш ваткыч чор башланыр иде. Күлмәген каян алырга да, кайсы ресторанда туй итәргә? Шулар гына булса, ерып чыгар да идең, арасында бит әйбәт фотограф, видеограф, шәп алып баручы табу, бөтенесен таң калдырырлык люкс машина яллау, бию өйрәнү, макияж, маникюр, чәчкә прическа ясату, йөзек, декор, чакыру кәгазеише очы-башы күренмәгән мең төрле вак, әмма һичшиксез мөһим эш бар. Кесә хәлләре саллырак булганнар, бу көнне энәсеннән җебенә хәтле җайлап майлар өчен менеджер-оештыручы яллый да, шуның эшен телефоннан тикшереп кенә утыра. Калганнарга нишләргә? Казан ИТ-паркының инкубаторында үстерелүче проектларның берсе шушы мәшәкатьләрне җиңеләйтү өчен тормышка ашырыла да инде.

Wedding Planner, ягъни Туйны Планлаштырырга ярдәм итүче сайтта Казанның бөтен фотографы, тырнак ясаучысы һәм барысы-барысы бик җайлы рәвештә бер каталогка тупланган. Таныш һәм сайла гына! Екатерина Гудкова җитәкчелегендә пәйда булган бу сайт – кешеләрнең тормышын уңайлырак итәр өчен ире белән алар башлап җибәргән яңа һәм уңышлы проектларның берсе генә. Кызларга әлеге сайттан – файда, ә Екатеринаның үзеннән үрнәк алырга кала.

Сирәк булса да, 70 һәм 75 ел бергә яшәгән парлар да бар. Юбилярлар катнашында тантана үткәрәбез, анда яшь парларны да чакырабыз. 8 июльдә – бөтен ил күләмендә «Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык» көнен билгеләп үткәндә – Татарстанда 25 елдан артык бергә яшәп, балалар үстергән һәм үз хезмәтендә уңышка ирешкән 70 парга медаль тапшырылды.

Загс хезмәткәрләре күңелле вакыйгаларны гына түгел, үлемне дә терки. Күпләр белеп бетерми: кешенең үлемен теркәү ничек башкарыла?

– Загс туганнан үлгәнгә кадәр кирәк, дип юкка гына әйтмиләр шул. Үлем фактын теркәү өчен табиб биргән документ булу зарур. Кешенең үлеме 3 көн эчендә теркәлергә тиеш. Кайбер очракта (мисал өчен, хәбәрсез югалганнар) үлем акты суд карары нигезендә теркәлә. Чит илләрдә вафат булган Россия гражданнарының үлеме, күпчелек очракта, кеше бакыйлыкка күчкән илдә теркәлә. Җәсәден медицина документы белән илгә алып кайта алсалар, монда теркибез.

Загс биргән үлем акты булмый торып, күмү мөмкин түгел диярлек. Ай саен тикшерү үткәреп, законсыз күмүләр барлыгын ачыклый калсак, җирле үзидарә органнарына хәбәр итәбез, киләчәктә мондый хәлләрне булдырмау юнәлешендә эшлибез. Үлемне терки торган бүлек ялларсыз эшли – 1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр.

Загс бүген нинди эшләр белән шөгыльләнә, Альбина ханым?

– Күптән түгел «Гражданлык хәле турындагы актлар» федераль законына электрон гариза бирү турында пункт керттеләр. Бездә беренчеләрдән булып, өйләнешергә теләүчеләр өчен төбәк порталында никах теркәү урынын һәм вакытын алдан броньлау мөмкинлеге булдырылды.

Яшь парларның 90 проценттан күбрәге электрон гариза бирә. Документларны алыштыру турында гариза бирү дә кереп бара. Дәүләт салымын түләп, чиратка языласың да, билгеләнгән вакытта загска килеп кенә китәсең. 10 ел элеккеге җәй көнен исегезгә төшерегез... Загска гариза тапшыру өчен озын чиратлар сузыла иде. Без иртүк эшкә киләбез, ә анда инде чиратка тезелеп басканнар. Хәзер бу хәлләр тарихта калды. Электрон гариза бирсәләр дә, язылышу көненә бер ай кала, пар загска килеп, ниятләре үзгәрмәгәнлеген раслап, имза куярга тиеш иде. Хәзер, законга үзгәреш кертелгәч, тулысынча электрон гариза бирү мөмкинлеге ачылды. Парларга язылышу көнендә генә загска килергә кала. Хәзер бу юнәлештә актив эш алып барабыз.

Загска килү өчен бала тууны яисә алтын туй җиткәнен генә көтәргә кирәкми, ел дәвамында халыкка ачык без. Әйтик, һәр ел саен гаиләнең туган көнен билгеләп үтәргә була. Күпчелек очракта ир яки хатын бер-берсенә шундый сюрприз ясый, яисә балалары тырышлык күрсәтә. Һәр пар өчен аерым сценарий төзеп, фотографиялэрдән күргәзмә ясап, чын мәгънәсендә гаилә бәйрәме оештырабыз. Загс хезмәткәрләре кәгазь белән дә, кеше белән дә эшли. Эшебез сабырлык һәм иҗадилык сорый.



«Бик бәхетле яшәдек!» – Диләрә Шакир кызы Еникеева белән Сөләйман Сафа улы Вәлитов сүзне нәкъ менә шулай башлады.

Алар институтта бергә укыганнар. Диләрә – беренче, Сөләйман икенче курста укыганда комсомол җыелышында танышканнар. Сугыш үтеп кайткан егетне бер күрүдә ошата кыз. Күңел түренә шул беренче очрашуда ук үрелгән хисләр соңгы курста укыганда ташып чыга. Ординатурага укырга керүгә үк өйләнешергә булалар. «Загска икәү генә килдек. Без язылышкан көн – 1955 елның 8 марты – бик ямьсез, салкын көн иде. Загс хезмәткәре генә котлады да, без җитәкләшеп урамга чыгып киттек. Казан урамнары буйлап җәяүләп туй сәяхәте ясадык», – дип, бөтен йөзе белән балкып елмая Диләрә ханым.

Уртак тормышларында шул беренче көн генә салкын булып исләрендә калган аларның. Бергә яшәгән 60 ел бер мизгел кебек кенә үтеп киткән. Эшен дә эшләргә өлгергәннәр, уллары Искәндәргә тәрбия бирергә дә вакыт тапканнар. Диләрә ханым белән Сөләйман әфәнде Казан дәүләт медицина университетында да хөрмәткә лаек кешеләр. Сөләйман Вәлитов – доцент, 15 ел педиатрия факультетын җитәкләгән кеше. Диләрә Еникеева – фән докторы, профессор. 85 яшен тутырса да, һаман студентлар арасында әле ул.

Уллары Искәндәр белән киленнәре Наилә өч оныкүләк иткән үзләренә. Булат әби-бабасы юлын сайлаган, Мәскәүдә эндокринолог булып эшли, медицина фәннәре кандидаты. Камилә – тарих укытучысы, Оскар – икътисадчы. Алар үскәндә «бала баласы балдан татлы» дип кабатлаган әби-бабай хәзер оныклары Булатның 5 яшь ярымлык улы Тимурны сөеп туймый.

Узган ел Татарстан Республикасы көнендә Президент Рөстәм Миңнеханов та зурлаган әле аларны бриллиант туйлары белән. Озак еллар бергә гомер иткән 54 гаиләне чакырып, зур бәйрәм оештырганнар. «Без – гади эш кешеләре. Гомер буе тыйнак яшәдек. Бәйрәмдә Президент белән бер өстәл янында утырасыбызны белгәч, бер мәлгә югалып калдык. Хезмәтебезне күреп, үрнәк гаилә итеп шулай зурлаганнары өчен рәхмәт», – ди Диләрә ханым. Мәхәббәт, хөрмәт, бер-береңә ышану, юл куя белү – аларның бәхетле гаилә рецепты менә шундый. Диләрә ханымга сорау бирсәм – иренә, ә Сөләйман абыйга мөрәҗәгать итсәм, җәмәгатенә карап куя. «Кем кемне күбрәк яратты икән?» – дим. Елмаешалар. Һәм бер секунд та уйлап тормыйча, җавап та бирәләр: «Икебез дә бертигез яраттык! Шулай булмаса, 60 ел бергә яши алмас идек».



Реклама хокукында







БАЛАЧАК ИЛЕ

Гөлнур
ХӘСӘНШИНА

Иртәнге кояш нурында уйнаган чык тамчылары, кичке шәфәкъның матурлыгы, йолдыз сибелгән җәйге төнге күкнең серлелеге, урман шавы, тукран тукылдавы, күке кычкыруы, сандугачлар җыры... Шәһәр баласы боларның барысыннан да мәхрүм! Мәктәп һәм өй: компьютер, ноутбук, айфон яки айпад. Күбесенең тормышы шушы чикләрдән чыкмый. Аларның «эш көне» – дәресләр, түгәрәкләр, өй эшләре – күп вакыт өлкәннәрнекеннән озынракка да сузыла. Көтеп алган җәйге яллар инде ничек узар? Тагын шул компьютер яки телевизор каршындамы? Авылда оныкларын сагынып торган дәү әни-дәү әтиләре булмаган әти-әниләр бигрәк тә баш вата. Каникуллар – баланың киләсе уку елына көч туплау вакыты да. Аны күңелле генә түгел, файдалы да итеп уздырасы килә бит әле. Мондый чакта иң элек җәйге лагерьлар турында уйлыйсың. Тик кайсын сайларга? «Татнефть» ААҖнең балаларны җәйге сәламәтләндерү лагерьларе унөчәү. «Анда, мөгаен, компания хезмәткәрләре балалары гына ял итәдер бит», – дияргә ашыкмагыз. Теләге булган һәркем улын яки кызын унөч лагерьнең берсенә җибәрә ала. Юлламасы булса. Дөресрәге, аны алырга өлгерсә! Чөнки юлламага чиратка гыйнвар аенда (!) ук басалар. Юлламаның әти-әниләргә күпмегә төшкәне турындагы сөйләшүне читкәрәк куеп торып, башта алардагы шартлар белән якыннанрак танышыйк әле. Исегезгә төшерәм: без бүген Россия нефть, газ һәм төзелеш тармаклары профсоюзлары ел саен үткәргән конкурс нәтиҗәләре буенча илдә иң яхшылардан саналган лагерьларда кунакта!









«Яшьлек»

– Бассейн!

Соравымны ахырга кадәр тыңлап та бетермәделәр. Бөтенесе беравыздан: «Бассейн! Безгә монда иң ошаганы бассейн!» – дип җавап бирде. Аннан берсен-берсе бүлә-бүлә сөйли башладылар... «Көн саен бер тапкыр йөзәбез бассейнда!» «Алар безнең икәү: берсе – ябык, икенчесе – ачык. Анысы чын диңгез буе кебек: шезлонглар да бар, чатырлар да». «Бүген безнең экватор! Лагерь вакытының яртысы бетте дигән сүз ул». «Беренче отрядтагыларны күрсәгез – алар шундый зурлар!»

Минем янга унберенче отряд тезелешеп утырды: Полина, Соня, Камилә, Маша... Иң кечкенәләр төркеме. Кемдер беренче сыйныфны тәмамлаган, кайсы мәктәпкә әле быел гына бара. Тыңлап, баш кагып кына өлгер: «Ә минем туган көн җитә!» «Мин песиемне, Феяны сагындым...» «Ә мин әнине!» «Миләүшә кичә кич өен сагынып елап алды...» Шулай, балалы йортта сер тормый... «Без монда көне буе урамда. Рәхәт!» «Боткалар ашыйбыз. Шундый тәмле пешерәләр!» «Футбол уйнарга өйрәндек. Безнең отряд беренче урынны алды!» «Ә Җиңүнең 70 еллыгына багышланган рәсем ясау бәйгесендә икенче булдык!» «Без хәзер пионербол да, флорбол да уйный беләбез!» «Ә Полина киемнәрен үзе юа! Мин өйрәнмәдем әле...» «Лагерьда дусларым егерме дүрткә күбәйде!»

«Яшьлек» («Әлмәтнефть» идарәсе) – «Татнефть» лагерьлары арасында иң өлкәне. Лагерь начальнигы Лилия Марат кызы Агиева «иң-иң»нәрне тагын бик күп санап китә әле: «Иң беренче бассейннарны бездә төзеделәр, бездә иң әйбәт кадрлар эшли, безгә иң әйбәт балалар килә...»

Кышын лагерьлар гаилә белән ял итү базаларына әйләнә.

Балаларның буш вакыты юк диярлек – көн минутлап бүленгән. Һәр иртә зарядкадан башлана: зур кызлар аэробика белән шөгыльләнә, егетләрне тренер көтә, ә кечкенәләр зарядканы вожатый апалары белән ясый. Иртәнге аштан соң – хезмәт десанты. Лагерь нарат урманы эчендә, җыймый торсаң, сукмак-юлларны хәзер нарат күркәсе басачак.

Бүгенге балаларга хәрәкәтләнү җитми. Баштагы ике-өч көндә ла-

герьда бу сизелә әле, аннан... Аннан туктатам димә! Волейбол, баскетбол, теннис, флорбол, йөзү, су полосы буенча турнирлар, шашка, бильярд буенча... Футбол ярышлары чын футбол мәйданында уза. Трибуналарына кадәр бар! Өлкән тренер Светлана Леонтьева – балаларның иң яраткан кешесе.

Беренче сменада «Яшьлек»-тә быел 273 бала ял итә, ә гаризалар 700 дән артык кергән булган!

Һәр смена саен яңа премьера белән Әлмәт дәүләт драма театры килеп төшә. Аларны курчак театры алыштыра. Аннан – планетарий. СПИДка каршы көрәш үзәге лекцияләре, янгын сүндерүчеләр... Кирәклесе, файдалысы, кызыклысы – барысы бергә! Ә кичен клубның зур сәхнәсенә балалар үзләре хуҗа: конкурслар, ярышлар башлана. Бөтен лагерь алдында чыгыш ясау өчен сәләт тә, тәвәккәллек тә кирәк. Бүген Бөтенроссия конкурсларында катнашучы Дамир Нуретдиновның талантлы бала икәнен беренче тапкыр «Яшьлек»тә күреп алалар.

«Балалар лагерьда үзгәрәләр, – унбиш елга якын педагог-оештыручы булып эшләүче Лилия Одилова һәм Венера Нургатиналар фикере бу. – Беренчедән, алар коллектив эчендә яшәргә, мөстәкыйльлеккә өйрәнәләр. Бер команда булырга. Яшьтәшләре белән уртак тел табарга – беркем дә бернәрсәне дә берүзе генә хәл итми бездә. Лагерь – аралашу мәктәбе ул. Туры һәм күчерелмә мәгънәдә: бүгенгеләргә күзгә-күз карап сөйләшү дә шулкадәр җитми бит».

Лагерь начальнигы әйткән тагын бер «иң-иң» калган бит әле. «Балалар көнгә биш тапкыр туклана. Иң яхшы аш-су осталары бездә! – диде ул. – Әниләр борчыла: «Өйдә балаларга ничек, нәрсә пешерербез, бөтенебез дә сезнең кебек оста түгел бит», – диләр».

«Кояшлы»

– Яшьтәшләре белән аралашу Исламга бөтен даруларны алыштыра! – Нәфисә ханым лагерьда оныгы белән бергә ял итә. – Узган ел бераз шикләнебрәк килгән идек, ә быел туган йортка кайткан кебек. Монда бөтен нәрсә ошый безгә: торган бүлмәбез, вожатыйлар, урман... Балалар церебраль параличы дигән диагнозны Исламга бер яшьтә генә куйдылар. Өч яшькә кадәр ул үзе генә утыра да алмады. Хәзер дә бер кулы һәм бер аягы йөрми. Коррекция интернат-мәктәбенә мин аны иртән илтеп куям, кич кенә алам. Быел дүртенче сыйныфны тәмамлады. «Дүртле» һәм «бишле»гә генә укый! Әтисе аңа яшь тә ике ай булганда ук үлде, кызым Гүзәл белән миңа кояш кебек инде ул Ислам, аңардан башка безгә тормыш юктыр шикелле... Әнисе эшли, мин лаеклы ялга чыкканнан бирле шушы оныгымны карыйм. Мәктәптә алар бер класста алты бала, барысы да үзе ишеләр. Ә монда бит бөтенләй башка мохит! Балалар баштагы ике көндә генә тартынып тордылар, бармак белән төртеп күрсәтүчеләре дә булды... Ә хәзер: «Ярыймы сезнең янга керергә?» – дип сорап кына торалар. Бергә-бергә резинкадан беләзек үрәләр әнә – Исламның кулларына менә дигән гимнастика. Иртәнге зарядканы да калдырганыбыз юк безнең!

«Уңай мохит» программасы буенча «Кояшлы»да («Елховнефть» идарәсе) узган җәй биш бала ял иткән, быел да шуның кадәр булыр дип көтәләр. Лагерьларда соңгы вакытта ачылган корпусларның һәммәсендә дә мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен махсус бүлмәләр җиһазландырылган. «Алар да социумда яшәргә тиеш, – ди лагерь начальнигы Амосова Елена Геннадьевна. – Ислам әнә ничек үзгәрде. Яшьтәшләренә ияреп, ул хәтта күбрәк хәрәкәтләнергә дә тырыша. Гел: «Үзем!» – ди».

Дуслары Исламның коляскасын этеп, клубка таба китте – көндәгечә анда бүген дә нindидер чара. Ә без яшеллеккә, чәчәккә күмелгән лагерьны карап йөрибез. (Балалар ял белән бергә хезмәт тәрбиясе дә ала – чәчәкләргә су сибү алар эше.) «Татнефть»нең барлык лагерьларындагы кебек үк өч-дүрт катлы корпуслар, бөтен шартлары тудырылган ике-өч кешелек бүлмәләр. Ике бассейн, аквапарк, полипропилен белән

киңәш



- Баланың лагерьга алып барасы әйберләрен икәү бергә җыеп тутырыгыз: нәрсәнең кайда ятканын күрсен. Кояш кыздырганда яки салкын, җиллерәк көнне ул нәрсә кияргә икәнен бергә хәл итегез.
- Рюкзагына салган кием-салымның исемлеген төзесәгез тагын да яхшырак: беренчедән – югалтмаска, икенчедән – үзе белән нәрсәләр алганын тәгаен белергә.
- «Лагерь иртәсе» дигән уен уйнап карагыз: бала урын-җирен үзе җыйсын, нәрсә киясен үзе хәл итсен.
- Ничә яшьтә булса да, балага яңа урынга ияләшү өчен вакыт кирәк. Ул: «Ошамый, кайтам, килеп алыгыз!» – дип, икенче көнне үк шалтыратуга, янына чыгып чабарга ашыкмагыз. Аны да тынычландырыгыз, үзегез дә сабыр итегез. Бу – уза торган күренеш.
- Баланы лагерьга озатырга бөтен туган-тумачаны җыеп бармасагыз да ярый: кайтмаска китми бит ул. Автобус кузгалып киткәндә генә биргән соңгы киңәшләр гел «ярамый» дип тәмамланмасын.
- Кыз бала, лагерьга барганчы, чәчен тарап-үрергә, юарга өйрәнсен.
- Баланы лагерь белән кызыктырам, дип, барысын да ал да гөл итеп күрсәтергә тырышмагыз: андагы тәртипләргә буйсынырга, вожатыйлар сүзен тыңларга туры киләчәген әйтергә онытмагыз.

капланган спорт мәйданчыклары, затлы ашханә... Бай китапханә. (Узган ел Россия күләмендәге бәйгедә җиңеп, премия белән бүләкләнгәннәр – шул акчага электрон китаплар сатып алганнар. Моңа иң сөенгәне зуррак отрядларда ял итүчеләр булган. Ә без балаларны укымый дибез...) Унга якын түгәрәк, җыр, бию студиясе. (Балаларының мондый сәләтләре дә барын беренче тапкыр кайбер әти-әниләр лагерь оештырган концертта гына күрә.)

Ачылганына быел 47 ел булган лагерьның, әлбәттә, үз традицияләре бар. Әти-әниләр балаларын «Кояшлы»га тыныч күңел белән җибәрә – монда тәртип. Өлкәннәргә иң ошаганы шул – балалар лагерьда хәтта кесә телефоннарыннан да аерылып тора. Өйгә алар корпуслардагы телефоннардан шалтырата ала. Шәһәрдәге кебек гел телефон тотып утырсалар агачтан агачка сикергән тиеннәрне, сукмактан ашыккан керпеләрне кайчан күрсен соң алар? Гөлләрнең чәчәккә бөреләнүләрен, кояшка күзләрен ачуларын... Бүгенгеләр өчен сенсация дисәң дә ярый – бер сәгать, бер көн түгел, егерме бер көн дә телефонсыз, «ВКонтакте»сыз яшәү мөмкин икән!

Бу сменада лагерь... «Нефтьчеләр шәһәре»нә әйләнгән әле. Бер отрядта – геологлар, икенчесендә – бораулаучылар, өченчесендә монтажчылар яши... Предприятие үзенә алмашчылар әзерли! Патриотизм хисе бер көндә генә тәрбияләнми...

Елена Геннадьевна да без инде башка лагерь җитәкчеләреннән ишеткән сүзләрне кабатлый: «Ел саен бер үк балалар ял итә. Беренче отрядтан сигезенчегә кадәр күз алдында үскәч, алар, әлбәттә, үзеңнеке булып бетә». Аның үзен әнисе «Кояшлы»га 1 нче сыйныйфны тәмамлагач алып килгән. Шуннан бирле – ул биредә. Лагерь начальнигы булып эшли башлавына да 15 ел. Инде әнә кызы шушында үсә.

«Дуслык»

– Лагерь – яшәү рәвеше ул. Хәтта мин аны йогышлы чир кебек дияр идем. Йоктымы, гел сине үзенә тартып тора!

Оксана Леонидовна Журавлева («Җәлилнефть» идарәсе) лагерьга беренче тапкыр эшкә килгән вожатыйларга гел шушы сүзләрне кабатлыйм, ди. Чынлыкта, нәкъ лагерь начальнигы әйткәнчә килеп чыга да! Студент чакта вожатый булып килгән егет-кызлар, уку йортларын тәмамлагач та, җәйләрен лагерьга эшкә урнашалар. Яллары хисабына!

Ишекләрен ярты гасыр элек ачкан «Дуслык» лагеренда да балалар рәхәтләнеп ял итә алсын өчен барлык шартлар тудырылган. Саф һава, уңайлы корпуслар, спорт мәйданчыклары... Әмма балалар беренче чиратта яраткан вожатыйлары янына килә! (Республиканың көньяк-көнчыгыш районнарыннан гына түгел, Мәскәү, Санкт-Петербург, Екатеринбург шәһәрләреннән кадәр!) Ике арада: «Сез кайсы сменада, кайсы отрядта буласыз?» – дип сөйләшүкилешүләр кыш көне үк башлана. Планнар ел башында ук корыла.

«Дуслык»та Бөгелмә педагогия колледжы студентлары практика уза. Тормыш мәктәбе дип атасаң дөресрәктер. Кечкенәләр өчен әниләрен дә, әтиләрен дә алыштырырга туры килә кайчакта. Иртәләрен отрядтагы унбиш кызның чәчен үрергә, кичләрен, кайберләренең янына ятып, йоклатып җибәрергә... Беркемгә сөйләмәгән серләрен тыңларга, беренче мәхәббәт хисләренә шаһит булырга... Үзләре монда ял иткән балаларның, үсеп җиткәч, вожатый булып килгән очраклары адым саен.

...Урман өстенә кичке караңгылык иңә. Балаларның шат тавышларыннан гөрләп торган тирә-юнь тынып кала. Лагерьлар йокыга әзерләнә. Хәер, юк, башта бу көннәрдә туксан яшьлеген билгеләп үтүче «Артек» лагереннан башкаларга күчкән «кич утыру» («свечка») йоласы бар әле: отряд бер түгәрәккә җыелып утыра. Бүгенге көн ничек узды? Нинди тәэсирләр калдырды? Һәркем берничә җөмлә белән генә узып китеп барган көнгә нокта куя. Аннан – җыр, әкрен генә, ишетелер-ишетелмәс кенә...



Гомәр ЯРУЛЛИН, «Татнефть» ААҖнең профсоюз комитеты рәисе:

– «Татнефть» – бер генә социаль бинасын да үзе генә кулланмый! Компаниянең җитәкчеләренә рәхмәт, туксанынчы елларда, бөтен дөнья җимерелгәндә дә алар лагерьларны ташламады, саклап калды. «Моннан егерме ел элек «Актүбәнефть»нең профсоюз комитеты рәисе Азат Вәлиев: «Әйдәгез, лагерьларны бер җиргә җыеп сөйләшик, балаларны, җитәкчеләрне чакырыйк», – дигән тәкъдим белән чыкты. Беренче шундый фестивальне үзләрендә – Актүбәдә үткәрделәр. (Сүз уңаеннан, унөч лагерьны берләштергән егерменче фестиваль быел «Лениногорскнефть» идарәсенең 70 еллыгына багышлана.) Балаларның ялга, аралашуга мохтаҗ икәнен күрсәтте ул очрашу. Лагерьлардагы барак тибындагы йортларны сүтеп, алар урынына таш йортлар салдык. Һәр НГДУ, үзара ярыша-ярыша, балалар өчен шартлар тудырырга кереште. 2000 нче еллар башында: «Лагерьлар кирәкме?» – дигән сорау тагын калыкты. «Татнефть»нең ул чактагы генераль директоры Шәфәгать Тәхаветдинов лагерьларны бер кат үзе йөреп чыкты да: «Юк, нинди генә шартларда да лагерьларга кагылмыйбыз!» – диде.

Элек җәй буена өч смена ял итә иде, хәзер дүртәү, әмма барыбер теләүчеләрнең барысын кабул итү мөмкин түгел. Барлык уңайлыклары булган яңа корпуслар ел саен өстәлә тора: Түбән Камада, Нурлатта, Җәлилдә, Лениногорскида ачтык. Җайлылык, куркынычсызлык, мөмкинлекләр ягыннан Россия Федерациясендә иң яхшы лагерьлар бездә! Берничә ел элек фестивальгә Бөекбританиядән кунаклар – андагы профком әгъзалары килгән иде. «Балалар белән эшләүдә без сездән әле бик арттa калганбыз», – дип киттеләр.

Лагерьлардагы сменаларны ачу тантанасына, гадәттә, хезмәт ветераннарын чакырабыз: балалар туган яклары, әти-әниләре эшләгән оешманың тарихын белеп, яратып, горурланып үссеннәр. Яшь буынны тәрбияләүдә иң мөһим адымнарның берсе бу.

АЛТЫН ҖИРДӘ ЯТМАС

– Ә МЕНӘ ТЕГЕ ТОРМЫШТА...

Бергә үткәргән бәхетле кичләрдә, үткәннәр хакында сөйләшкәндә, Көлсылу үзен ак атта килеп алган шахзадәсенә сүзен еш кына: «Теге тормышта...» – дип башлый торган булгандыр...

Гөлнур САФИУЛЛИНА



Фото: Анна Арахамия

Ул тормышта Гөлшат – шәфкать туташы. Югары Ослан районының үзәк сырхауханәсенә эшкә килгәндә яшь-яшь була әле. Янәшәдән Казан–Мәскәү, Казан–Ульяновск трассасы уза – аварияләр еш булып тора. Ничек онытасың: берсендә берьюлы авыр хәлдәге унсигез кешене китерәләр! Ыңгырашу, елаш, кан... Кайсына алданрак ярдәм итәргә?! Хәер, табиблар гел җитми – күп вакыт батыраеп үзеңә тотынырга туры килә... Әмма бер түгел, ике кеше өчен эшләсәң дә, шәфкать туташы акчасына гына тормыш итәрлекмени?! Массаж ясарга өйрәнә Гөлшат. Берсендә баш табиб аны чакырып ала да: «Мәскәүдә югары белем алырга, косметологка укырга була», – дип тәкъдим итә. Уйлап та тормыйча ризалаша – матурлык ярата ул! Өч ел сизелмичә дә уза. «Кызыл диплом» янына инде яңа мәшәкатьләр өстәлә: авырулар яныннан чыгуга хәзер аны клиентлар – район җитәкчеләренең хәләл җефетләре көтә. Казан кул сузымында гына – анда да барып эшли аласың. (Эшли дә!) Теләгең булсын да, вакытны гына җиткер... «Безнең Гөлшат баскычның беренче басмасына басуга һәрвакыт аның икенчесенә, өченчесенә күтәрелү турында уйлады», – апасы Чулпан шулай ди. Тик берьюлы берничә җирдә эшләү үзеңне, хатын-кыз икәнлегеңне оныту түгел әле ул: төнге сменадан кайтып, шейпингка чыгып китәргә дә көч таба. Күп укый. Рухи дөньясын баетырга тырыша. Иң мөһиме – өлгерә! Ә бүгенгесенә генә канәгать булып яшәгән ир... «Мин аның үземнең кешем түгеллеген бик тиз аңладым», – ди ул бу хакта сүзне озынайтмыйча. Ике бала белән билгесезлеккә атлавын исә менә беркайчан «ялгышлык» димәячәк!

Җиңел булмый! Туксанынчы еллар бу. Бер елга якын хезмәт хакы күрмиләр. Балалар бакчасы өчен дә өч-дүрт айлык бурыч җыела. Өч яшьлек Камиләне бакчага алмый башлыйлар. «Бер көнне баланы

киендердем дә, үзем белән эшкә алып киттем, – дип искә төшерә ул. – Табибларның «пятиминутка»сы башланыр алдыннан иң алгы рәткә кертеп утырттым да, үзем эш урынына киттем. «Калдырыр җирем юк», – дим. Камилә бик тыныч бала, утырасын да беләм, әмма үземнең үзәк өзелә генә... Бер сәгатьтән баш табиб: «Машина бирәм, баласын илтеп куйсын, бакча мөдире белән сөйләштем», – дип, яныма кеше җибәрде. Балалы әниләр үзем генә түгел идем бит, кызлар барысы да рәхмәт укыды инде».

– Миңа кызларым арасындагы яшь аермасы булышты, – ди ул. – Камилә туганда Лилиягә ун яшь иде. Мин өч айдан эшкә чыктым. Лилия ул елны икенче сменада укыды: сәгать бергә кадәр сеңлесе белән ул була, аннан бала караучы бер кыз килә иде. Сеңлесенең иртән чәчен үрү, ашатып-эчертеп, киендереп бакчага озату апасы өстендә булды. Әмма эш дип мин балаларны беркайчан ташламадым, алар өчен вакытны булмаган чакта да таптым. Әткәй шикелле...

Һәркем оясында күргәнне кабатлый. Башкалар өй юганда, бакча казыганда, тирә-юньне җыештырганда, «өлгерербез», дип, әтиләре Галимулла абый 1 Май көнне үзенекеләрне генә түгел, тирә-күршедәге бала-чаганы да җыеп, ике-өч чакрымдагы тауга алып китә торган була. Ел саен! Озын кыш буе көтеп алган бәйрәм була ул! Җырлашып учак янында утырулар, яңа чыккан яшел чирәмдә уйнаулар... Әниләре белән әтиләренең елга ике-өч тапкыр (!) алты баласын ияртеп Кайбыч районы Борындык авылыннан Казанга килүләрен әйтәсеңме... Музейларга йөртәләр, зоопаркка, циркка алып баралар, шәһәр күрсәтәләр. Ә кичен алар сигез кеше элеккеге күршеләре Мөнирә апа белән Булат абыйларның бер бүлмәле фатирына барып керәләр. Сыялар! (Алга китеп булса да, әйтим, Нократ Аланында кибет ачканда Гөлшат бик озак мөдир эзләп йөри. Ышанычлы, таянырдай кеше кирәк. «Мөнирә апаларның кызы Зөлфия апа шунда яшәргә тиеш», – дип абыйсы искә төшерә. Элеккеге күршеләр яңадан табыша. «Андагы кибет өчен җаным тыныч», – дип, Гөлшат сөенеп туймый. Шулай, кылган игелекләр җирдә ятмый...)

Ел буе эшләп, акча җыеп, мәктәпкә киемнәр алырга барганда, маяның бер өлешен гел аерып куя Гөлшат: монысы балалар белән кафега керергә. Керәләр! Озак итеп утырырга, күңелләр булганчы сөйләшергә, аралашырга... Иделнең каршы як ярындагы шәһәргә чыгулар, урам, паркларда йөрүләр, музейларны кат-катураулар – алары атна саен диярлек. 1 июнь – Халыкара балаларны яклау көнендә махсус ял алып кызларга бәйрәм ясаулар. Кызларына яшь, чибәр, матур әни булырга тырышулар. «Аэробикага», дип өйдән өчәүләп чыгып китәләр, атнага бер Казаннан хореография укытучысы килә – анда да өчәү бииләр...

– Лилия буйчан кыз булып үсеп китте. Яшүсмерләр озын булудан ояла бит, бу да кыенсына башлады. Минем Казанда, Республика клиникасында белемемне күтәреп йөргән чагым иде. «Лик» мода театры мәктәпкә кызлар җыя» дигән белдерү күземә чалынды. «Әйдә, кызым, йөреп карыйк әле», – дим. Ризалашты. Кыш иде ул. Иртәнге биштә кузгалабыз. Идел өстеннән, боздан җәяү чыгабыз. Аракчинода электричкага утырабыз. Лилияне «Лик»ка кертәм дә, үзем укырга китәм. Кич тә бергә кайтабыз. Тагын Идел аша, тагын җәяү... Атнага өч тапкыр. Унберләрдә кайтып керә идек. Лилия өйдә кала, ә мин, чана тартып, дус кызым Таняларга, Камиләне алырга китәм. Укып бетергәч Лилияне эшкә алдылар. Кая гына чакырсалар да, үзен генә җибәрмәдем, дөресен әйтәм, кызымны югалтудан куркытым.

«Эфир» телеканалының «Мисс Җәй-2001» бәйгесе үткәрергә җыенуы турында да башта Гөлшат ишетә. Ә нигә тәвәккәлләп карамаска?! Сайлап алу турында 350 кыз катнаша, финалга унбише уза, шул бәхетлеләрнең берсе Лилия була... Репетицияләр башлана. Иртәгә конкурс дигән көнне пароходка соңга кала алар. Ерак бер туганнарын эзләп барып, ишек ачканнарын көтеп әниле-кызлы өч сәгать подъездда утыралар... Гран-прига машина бирәчәкләр, ә кызлар барысы да... беренче урын – «Алмаз-холдинг»ның йөзе булу турында хыяллана. Мәскәүдән ювелир компаниясе җитәкчеләренең берсе – Фәрит Гомәрев үзе килә.

Лилия тамашачыны иң элек татарча сәламли. «Мин аны шунда ук күңелемә салып куйдым», – ди соңыннан Фәрит Фәһимович. Жюри барысын да алдан хәл итәргә өлгергән булса да, ул үзенчә эшли: Лилия Малышеваны «Алмаз-холдинг»ның йөзе дип игълан итә. Тамаша беткәч, Мәскәү кунагы сәхнә артына күтәрелә. «Сентябрьдә Халыкара күргәзмәдә «Алмаз-холдинг»ны тәкъдим итәргә кирәк булачак», – дип сөйләшеп торганда, алар янына Гөлшатның апасы Чулпан килеп баса. «Кызыбыз яшь, аның үзен генә беркая да җибәрмәячәкбез», – дип сүзгә кушыла ул. «Без Лилияне, әлбәттә, әнисе озатып бару шарты белән генә чакырабыз», – дип дәвам итә Фәрит Фәһимович. Берсе: «Әнисе сез буласызмы?» – дип сорамый, икенчесе: «Әнисе мин түгел, билгеле», – дип әйтергә өлгерми...

Без Лилия белән бергә үстек, аннан Камиләне үстердек...

Җәй ахырында Казанга, «Яхонт» кибетенә шушы сәфәр хакында сөйләшергә килгәч, аларга Фәрит Фәһимович кабинетына узарга кушалар.

– Лилиянең апасы бигрәк чибәр икән...

Өстәл артында утырган ир-ат, башын күтәрүгә, шулай уйлый. Беренче унбиш секунд барысын да хәл итә...

Камиләгә алган сандалига, Лилиянең яңа шарфына, үзенең ак халатына өчәүләп утырып сөенгән чаклар – теге тормышта кала. Ирсез килеш, ничә еллар сыер асрап азапланулар... (Аның каруы, Лилиянең кулын сорарга бик абруйлы кешеләр килгәч, булачак кодаларына ул: «Кызым сыер да сава, терлек тә карый белә. Тормыш итәргә әзер», – дип икеләнмичә әйтә.) Чөгендер-





Кушылганыбызга инде ундүрт ел, әмма анын белән бер сукмактан атлап китүемә бер тапкыр да үкенгәнем булмады. Фәрит бик ышанычлы кеше ул. Акыллы. Гадел. Гаҗәеп тәрбияле. Бөтен туганнары шундый аның.



кишерне, суганны сатуга үстерүләр... (Ставка ярымга эшләп 200 сум хезмәт хакы алган вакытта, бер елны ул ике меңлек яшелчә сата!)

Кояш чыкканда торып, бүгенгем өчен Ходайга елый-елый рәхмәт укыган көннәрем күп минем.



Олы кызын зур таянычка санап, йортка янкорма төзергә икәү тотындылар... «Идел буенда яшим, әллә балык тотып сатарга инде?» – дигән уе исә ният кенә булып кала. «Жигули» машинасын исә алырга өлгерә! Югары Осланда рульгә утырган хатын-кызларның иң беренчесе ул була!

Ә бу тормышта... Бу тормышта Гөлшат – эшмәкәр ханым. Кибетләр хуҗабикәсе. Хәер, юк, иң элек ул бәхетле хатын әле. Без Югары Осланда, аларның тәрәзәдән Идел дулкыннары шавы ишетелеп торган иркен йортларында сөйләшәбез. Янібызда: «Дәү әни!» – дип, оныклары Рената белән Камил бөтереләләр. Әниләре Лилия дә янда гына, сүзгә ул да кушылгалый.

– Мин үземне башка тормыш көткәненә, киләчәктә янымда таянырдай ирем буласына һәрвакыт ышандым. Алай гына да түгел, мин аны Ходайдан сорап китердем. Хәтта үземнән өлкәнрәк булуы да мин теләгәнчә... Югары Осланда бервакыт халык зур-зур йортлар сала, затлы машиналар ала башлады. Берәүдән дә көнләшмәдем! Киресенчә, соклана идем. Аннан, үзем дә кул кушырып утырмадым бит, эшләдем дә эшләдем – бер урында егерме ел. Фәритләрнең әниләре – кайнанам дөнья бәһасе торырлык акыллы хатын иде, ул балаларына һәрвакыт: «Кулыгыздан эш төшмәсен, күңелегездән Аллаһы Тәгалә китмәсен», – дип кабатлаган. Бу сүзләрне ишеткәч шаккаттым – мин дә бит шулай яшәдем!

Һәр көнем бәйрәм минем! Ышансагыз – ышаныгыз, ышанмасагыз – юк... Әйе, кечкенә генә бәйрәм! Фәрит шулай тәүлекләрне бер гомергә әйләндерә белә. Без бит соң табыштык, бер-беребезнең кадерен инде аңлар чакта. Икебезгә генә күңелсез булганы юк безгә. Беркайчан да! Эштән кайткач, сәгать-сәгать ярым йөреп керәбез. («Җитәкләшеп!» – монысын Лилия өсти.) Һәм бертуктамый сөйләшәбез! Нинди генә темалар кузгатмыйбыз. Бер-беребездән армыйбыз! Өч көн дә аерым торганыбыз юк.

Әмма гаилә – хезмәт ул. Туктаусыз хезмәт... Мәхәббәтне, яратуны гел роза гөле белән чагыштырам мин үзем. Матур да ул, һәм шулкадәрле нәзберек тә. Вакытында су сипми кара син аңа! Фәритнең эше бик катлаулы, авыр. (Фәрит Гомәрев – «Алмаз-холдинг» зәркән компаниясенең һәм «Алмаз» ювелир заводының (Казан) генераль директоры). Эштәге проблемаларны беркайчан да өйгә алып кайтмый ул. Ләкин күз карашыннан барысын да аңлыйм... Авыр чакларда терәк була алганым өчен рәхмәтле икәнен яшерми Фәрит. «Минем уңышларда синең өлешең дә зур», – дип гел кабатлый.

Тормышта бер-береңне аңламыйча үпкәләүләр була. Андый чакта Фәриткә: «Әйдә, утыр, сөйләшәбез», – дия идем. Мондый сүзне күбрәк рульдә үзем утырганда башлыйм – төшеп кала алмый. «Мин шулай-шулай дип уйладым, ә син ничек уйладың?» – дим... Болар өчен ул кайтып-кайтып хәзер дә рәхмәт әйтә: «Син аңламаган булсаң, без хәзер бергә булыр идекме икән?» – ди. Әйе, беренче вакытларда үземнән нәрсә теләүләрен аңлап та бетермәгән чаклар булды. Мин бит моңарчы үз-үземә генә ышанган, аякта нык басып торган хатын-кыз идем.

Җигелеп тормыш итәргә күнгән кеше хуҗабикә булып кына өйдә утыра аламыни?! Гөлшат та бер көнне иренә сүзката, үзе әйтмешли, куркып, шикләнеп кенә: «Кибет ачып карыйсым килә, Фәрит...» Хәер, башта «теге тормышта» калган бер вакыйганы сөйләп китәсе килә әле. Лилиянең мәктәпкә яңа



киткән чагы. Ял көнендә авылга, Борындыкка кайталар. Иртән кече якта әниләренең уфтанган тавышына уяналар: «Алкамны югалттым... Сыңар алкамны!» Алка табылмый. Шул вакыт Лилия колагындагы алкасын салып, дәү әнисенә суза: «Сиңа булсын!» 128 сумга алган, әниле-кызлы икесенә бер пар алка була ул... Мөнирә апа башта: «Кирәкми, алмыйм!» – дип каршы төшә, аннан, елый-елый теләк тели: «Мине сөендергән өчен Ходай сезгә йөзе-меңе белән кайтарсын!» Ананың теләкләре фәрештәләрнең «Амин!» дигән чагына туры килә, күрәмсең...

Беренче кибетен Гөлшат Кукмара районында ача. Аннан өч ел эчендә кибетләр алтыга җитә: Нократ Аланында, Мамадышта, Буада, Тәтештә... Бүген дүртесе эшли. Безнең әйберләре, алтын-көмеш – көн саен ала торган ипи ризыгы түгел. Дөнья: «Кризис!» – дип шаулаганда, үкчәгә көндәшләр басып килгәндә бизнесны ничек саклап калырга?

– Бизнесны зур бер корабль, ә кибетләремне андагы кечкенә генә каюта итеп күз алдына китерсәк, корабль давылга эләккәндә, каюта чайкалмыйча кала алмый...

Беренче урында һәрвакыт сыйфат тора безнең. Мин «Алмаз-холдинг» бренды астында эшлим. Ул иремнең, аның туганнарының гаилә бизнесы. Аларның йөзләренә ничек кызыллык китерә алыйм?! Аннан мин бит үзем дә хатын-кыз. Берәүнең, хәләл акчасын биреп, бриллиант урынына фианит тагып йөрүенә намусым ничек риза булсын?! Кибетләребездә ялган әйбер юк, булмас та! Кат-кат тикшерү үткәннән соң гына чыга алар сатуга. Мин шуңа да кибет ишеген ачып кергән һәркемнең күзенә туры карыйм – оялырга сәбәбем юк.

Һәр сатып алучыга, кесәсендә күпме акча булуына карамастан, без иң югары дәрәҗәдә хезмәт күрсәтергә тырышабыз. Кеше безгә матурлык артыннан килә, әйе, ул икмәк түгел... Статистика буенча, хатын-кызга иң еш бүләк ителгән әйбер – косметика, аннан – акча. Зәркән эшләнмәләр – өченче урында. Ә сораштырулар исә 99 процентка якын хатын-кызның бүләккә алтын-көмеш алырга теләвен күрсәтә! Нигәме? Косметика бетә, акчаны туздырабыз, ә бу – гомерлеккә. Шуңа да безнең әйбере сатып алган көннең һәр хатын-кыз күңеленә бәйрәм булып кереп калуын телим.

Эшнең җайлы, көйле баруына кул астымда эшләүчеләр белән булган үзара мөнәсәбәтләр дә зур роль уйный. Мин алардан өйрәнәм, фикерләренә колак салам, тыңлыйм, киңәшәм. Зур дулкыннар каплап китмәсен өчен нишләргә – хезмәттәшләрем белән бу хакта гел уйлanaбыз. Халыкара күргәзмәләргә йөрергә, заман белән бергә атларга тырышабыз. Халык теләге дә искә алына – ассортиментны кибет мөдирләре белән бергә сайлыйбыз.

«Кул астындагы сатучылар бик ярата аны. Бизнесы да гаилә кебек, җылы», – Камилә сүзләре бу. Кайчандыр: «Тормышыбыз үзгәрергә тора», – дип апасы белән әнисе көйләп-җайлап кына Фәрит абыйлары турында сүз башлагач: «Сез нәрсә, өйгә ир-ат алып кайтмакчы буласызмы? Беркайчан да!» – дип каршы төшкән төпчеге. Быел әнә Казан дәүләт финанс-икътисад институтының IV курсын тәмамлаган. (Сүз арасында Камилә серен чишә: «Мәскәүдә эш таптым. Юк, юк, «Алмаз-холдинг» белән бәйле түгел. Алтын-көмеш яратмыйм мин. Кечкенәдән хыялым башка булды. Беренче адымнан барысын да үзем башлыйсым килә. Чемоданым инде җыелган, әнинең «Риза» дигән сүзен генә көтәм. Аның хәер-фатихасыннан башка чыгып китәргә теләмим. Ә ул һаман икеләнә: «Син кечкенә әле», – ди».)

Әни: «Минем иң зур шатлыгым – алты балам», – дия иде.

– Безнең әни киң күңелле, кешелекле...

Лилия белән Камилә бер-берсен ишетмичә дә бер үк сүзләрне кабатлыйлар. «Безнең өйдә гел кеше, гел кунак. Әнинең туганнары, аларның балалары... Һәркемгә урын җитә». «Әнинең өч кыз, бер ир туганы бар. Апалары Гүзәл, Фирая, Чулпан, абыйсы Илһам белән әни бер йодрык кебек. Әни алар белән беркайчан сүзгә килмәячәк! Ни генә булса да, алар гел янәшә...» «Дус кызларым аңа киңәшкә йөри». «Минем дә «Мисс-гимназия» титулына ия булганым бар. Әни миңа ул чакта өч меңгә якын ялтыравыклы конфет кәгазеннән күлмәк ясаган иде...» «Әнинең бүген тормышы җитеш, мул, әмма ул үзгәрмәс инде безнең! Яшелчәне, җиләк-җимешне әни хәзер дә үзе үстерә. Быел яз кунакка киләбез: карыйм, әни җир казый, ә бакчачы аның янына басып сөйләшеп тора. Ярата ул җирне!» «Ә чәчәкләрне ничек яратуын белсәгез!» «Дуслары да шул ук калды безнең әнинең. Татьяна белән алар инде егерме тугыз ел бергә». «Әни белән Лилия апа бик якыннар, ә без Фәрит абый белән икәү... Тарихны аңардан башка өйрәнә алмас идем мин мәктәптә, математиканы да...» «Әнинең балалары күбәйде: киявенә ул «улым» дип кенә дәшә!» «Ул хәзер бик бәхетле, янында – яраткан кешесе...» «Әни кебек бәхетле буласы килә!»

...«Теге тормыш», «бу тормыш...» Әйе, чыннан да, Көлсылу әкиятенә охшаган тарих, диярсез. Ә әкиятләр һәрвакыт матур тәмамлана. Чынбарлыкта да шулай булсын!



БУ ХУҖАЛЫККА ТӘҖРИБӘ УРТАКЛАШЫРГА ДИП ИЛНЕҢ ТӨРЛЕ ПОЧМАКЛАРЫННАН КИЛӘЛӘР.









БӨРТЕГЕ ДӘ КАДЕРЛЕ



Мәдинә АВЗАЛОВА

Авылларда еш булабыз. Барган саен күргәннәребездән канәгать калып кайтабыз. Авыл кешесенең тырышлыгы, тормышларының көннән-көн алга баруы, авылларының күзгә күренеп үзгәрүе куандыра. Җирнең төмен белеп яши алар... Йөзләгән гектар биләмәләрдә алабута, чүп үлән үсеп яткан төбәкләрне дә күргәнебез бар безнең. Ульян өлкәсенә таба гына борыл, ерак китмичә, Киров якларына гына бер әйләнеп кара... Шөкер, бездә алай түгел. Чөнки аңлыйбыз: республика башлыгы әйткәнчә, «авылсыз халыкның киләчәге юк». Соңгы елларда бу тармак зур үзгәрешләр кичерә: авыл хуҗалыгы, агросәнәгать комплексы икътисадыбызны тотрыклы итү өчен кирәк дибез. Һәм монда күп нәрсә эшмәкәрләрдән тора. Аларның эш тәҗрибәсе башкаларга үрнәк була алырмы?!

Шул максатны күз алдында тотып үткәреләчәк семинарга чакырганда: «Башта басу-кырларны карап кайтырбыз», – дигән иде ул. Без түзмәдек, Кукмара җирләренә кереп, Вахит авылына таба

кузгалуга, машинабызны зур мәйдан биләп утырган корылмалар ягына бордык. Карап торуга – үзенә бер серле дөнья! «Чит кешегә машина белән керү тыела!» дип язылган зур капка янына килеп туктадык та, машинадан төшеп, ике яклап тезелешеп киткән бихисап мал ятаклары яныннан җәяүләп кенә узып, күптән күрәсебез килгән мегафермага барып чыктык.

Тирә-ягыбызга каранабыз: корылма каршында кечкенә генә фонтан бәреп тора. Кул сузымында гына мегаферманың икенче чираты эшләнеп ята. Ачык һавада силос-сенаж белән шыплап тутырылган базлар, янда гына – су башнясы...

Ишегенә кызыл тасма эленгән мегафермага аяк басуга, борынга хуш исле печән, катнаш азык исләре килеп бәрелә. 1200 баш савым сыерга дип исәпләнгән комплексның бер башыннан икенчесенә йөреп чыкканчы да күпме вакыт кирәк. Зур икән! Ә эшчеләре – өч-дүрт бөртек кенә. Кызларның кайберсе чүпрәк тотып, болай да чиста, ялтырап торган стеналарны сөрткәләп йөри. Себерке тотканы – ферма мөдире Рузалия Хәмидуллина булып чыкты. Сорауларыбызга җавап бирергә һич кенә дә вакытлары юк. Алар бүген кунак көтә. Алай дисәң, кунак биредә, үзләре әйтмешли, көн саен.

– Шуңа гел чисталык инде сездә...

– Юк, без үзебез чисталык яратабыз, малларыбыз да шуңа күнеккән, – ди кызларның берсе, бертуктаусыз әйләнеп торган массаж щеткасы янында аркаларын ышкытып торган маллар ягына таба ым кагып.

– Кызыл тасма да яратасызмы?

Кызлар көлеп җибәрә.

– Күз тимәсенгә элеп куйдык без аны, – ди алар. – Кешенең төрлесе бар: кайсы сокланып карый, кайсы көнләшеп... Ә бездә маллар!

– Малларны үзебез үрчетәбез, – дип сүзгә кушыла, сокланып карап торуыбызны күреп, хуҗалык зоотехнигы Илшат Мөхәрләмов.

Алар безнең «ученыйлар»

– Чит илдән кайтартмыйсыз, алайса?

– Акча әрәм итепме? – ди зоотехник, соравыма гаҗәпләнгәндәй булып. – Безнең азыкны ашый башлагач, барыбер үзебезнекенә әйләнә ич алар! Җиренә җиткереп карасаң, барыбер инде... шул ук сыерлар. Мөгезләре дә шундый ук, – дип шаяртырга керешә егет.

– Ишеткәнебез бар инде бу хакта. Мамадыштагы мегафермага баргач та, безгә шулай диделәр. Димәк, чит илдән миллионнарга төшереп мал кайтартканчы, вахитныкылар шикелле, үзеңә үрчетәсе!

– Дөрес ашатсаң, рационны гел үзгәртеп, кирәкле витаминны (ул Санкт-Петербургтан алына. – *авт.*) вакытында биреп барсаң, – дип санап китә хуҗалык җитәкчесенең терлекчелек буенча урынбасары. – Сөтенә карап инде. Әгәр шулай ашатып-тәрбияләп тә сөтен арттырмый икән, ашавын кысабыз. Симерә башлый аннары.

– Көненә 43 әр, 45 әр литр сөт бирүче сыерларыбыз бар. Уртача алганда, 23–25 литр килеп чыга, – дип мактап ала малларын ферма мөдире.



■ Хакимият башлыгы Сергей Димитриевны хуҗалык җитәкчесе Нәфыйк Хөсәенов алдагы эшләре белән таныштыра.

Мегаферманың бер ягында – савым сыерлар (әлегә алар 380 баш. – *авт.*), икенче ягында – бозаулатасы таналар. Малларга салынган азыкны тәүлегенә 24 әр мәртәбә мини-трактор белән кузгатып, әйләндереп торалар. Азык шуңа да сөрсеми, бозылмый. Ул көнне килгән кунаклар аны кулларына алып, үзең тотып ашарлык дип, иснәп-иснәп карадылар. Ферма эчендә гөрләтеп эшләп йөргән мини-тракторга да исләре китте. Гомумән, ис китәрлек яңалыклар күп биредә. Бая әйткәнебезчә, 380 баш сыерны бер сменада өч сыер савучы карый. Ничек өлгерәләр, дисезме?! Өлгерәләр! Чөнки монда бөтен эшләр автоматка көйләнгән. Берьюлы 56 баш сыер савыла. Калганнары янәшәдә генә үз чиратларын көтеп йөри. Мал өйрәтелгән, кая һәм кайчан барып басасын яхшы белә. «Алар безнең ученыйлар», – ди кызлар.

> *Авылның киләчәге – Хөсәенов шикелле булдыклылар кулында.*

Бер сүз белән әйткәндә, сыер савучылары да, сыерлары да тәртип ярата.

Елына бер баш сыердан 8123 килограмм сөт савып алына. Илшат Мөхәрләмов китергән саннарның хикмәтенә әкренләп төшенә барабыз: мондый җитешлекнең сере әллә нидә түгел, искереп беткән яңалыкта икән ләбаса... «Вахитов» исемендәге авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы икътисадчысы Марина Федорова безгә аны гади саннар белән, һәркемгә барып җитәрлек, күңеленә уй салырлык итеп аңлатты.

Акча санаганны ярата

– Тәүге мәртәбә ишетүегездер дип уйламыйм, – ди икътисадчы. – Акча санаганны ярата ул. Шуңа да без күбәү. Хуҗалыкта унбер бухгалтер. Күп дисезме? Йөкләнгән эшләренә, башкарган вазыйфаларына караганда, таманга гына туры килә. Бөтен исәп-хисап, әйтик, мөгезле эре терлек, дуңгыз сатабызмы, бәрәңге җибәрәбезме, йә булмаса, кирәкле материал кайтамы, техникамы,

Реклама хокукында



Ирешелгән уңышлар шушы белгечләрдән тора инде.

витамин киләме – барысы да безнең аша уза. Иртән бухгалтерыбыз бензовозга утырып чыгып китә. Мисал өчен, техникага бер көнгә 150 литр бензин тиеш, ди. Кичтән 10 литр тотылып бетмичә калган икән, аңа 140 литр гына салына, артыгы бирелми. Киресенчә, кемдер төнгә кадәр машина-тракторда эшләгән икән, аңа өстәп бирелә. Нык контрольдә тотабыз. Хуҗабыз шулай таләп итә. Аны берничек тә алдап булмый. Ул үзе агроном, үзе бухгалтер, үзе менеджер да. Шундый ул, алдынгы карашлы кеше. Аның өстәлендә һәрвакыт көндәлек сводка булыр. Кайсы фермада сөтнең күпмегә кимүен йә артуын көне-сәгате белән белеп тора.

Һәркем үземнеке дип эшли. Бердәм, дус коллективта кадрлар алышыну бик сирәк күренеш, гадәттән тыш хәл санала хәтта.

Һәркем – сыер савучымы ул, мал табибымы – үзенә тапшырылган эшкә зур җаваплылык белән карый. Бәләкәй генә бер хата, җибәрелгән кечкенә генә бер ялгыш та игътибарсыз калдырылмый. Моның өше җитешсезлекләр иң элек эшченең үзенең кесәсенә суга. Ай саен мал табибы белән бер бухгалтер фермадан фермага йөреп, сыерларда мастит авыруын тикшерә. Әгәр ун имчәктә була икән, хезмәт хакының 100 сумы тотып калына, унике имчәктән 200 сум тотыла. Моны чиргә каршы үтемле чара дип исәплибез. Билгеле, ул мал табибына да кагыла. Ул да карап җиткермәгән, димәк.

Аннары без электр энергиясеннән башлап һәрнәрсәгә, булган бөтен чыгымнарга лимит билгелибез. Хәтта җитлекмичә туган бозауга да лимит бар. Куелган шул күрсәткечләрдән артып китә икән, янә эш хакы киселә. Әнә ул гел шулай планшет белән йөри, шуны гына ачып карый да, – ди Марина Федорова, кунакларны озатып, безгә таба якынлашкан рәис белән исәнләшеп.

Кредитсыз эшлибез

«Алдынгы карашлы, продвинутый» җитәкчеләргә кризисы да, һава шартлары да нипочем. Максатың булса, замана авырлыклары пүчтәк кенә икән ул. Әнә бит нәрсә ди хуҗалык җитәкчесе! «Быел 340 миллион сум керем булыр», – ди. Менә сиңа кризис... Шуның 120 миллионын алар төрле төзелешләргә тотарга җыеналар. Мегаферманың икенче чираты, алты сенаж базы, ике ашлык склады, ике бозау абзары төзиселәре бар. Ул шулай ди. Аның планнары зурдан. Авылның социаль үсеше турында да онытмый. «Ел саен халыкка кирәк-яракка 5 миллион сум акча биреп барыла, – ди Нәфыйк Факилевич. – Ул мәчеткә, чиркәүгә, үлемкитеме булучыларга, санаторийга юлламага тотыла. Йорт-җир җиткерүчеләргә процентсыз 50 шәр, 100 әр мең сум акча биреп торабыз. Авыл кешесенең ун кубометр утынын бушлай ярдыру каралган.

– Каян акча җиткерәсез, кредит аласыздыр инде?

– Кредитыбыз юк, – ди һәм шундук безгә кредитсыз яшәү серләрен ача башлый.

«Эдельвейс» сөт комбинаты белән хезмәттәшлек итә башлауларына тиздән алты ел була икән. «Без аларга – сөт, алар безгә кирәгенчә процентсыз акча биреп тора, – ди ул. – Күп әле эшләребез: әнә мегаферманы тулысынча сафка бастырасы бар. Калган фермаларга да капиталь ремонт үткәрәбез: тәрәзәләрне пластикка алыштырабыз, түбәләрен яңартабыз. Иске фермаларда да шундый ук чисталык, тәртип безнең».

Хуҗалык элиталы орлыклар белән шөгыльләнә. Инде менә берничә ел алар бодай, солы, уҗым арышы, бәрәңге, нәселле терлек саталар. Әйтүләренә караганда, быел гына да 20 миллион сумлык бәрәңге җибәрелгән.

Җитәкче белән сөйләшү Бөек Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан мәдәният йорты каршына сугышта һәлак булган авылдашлары истәлегенә куелган һәйкәл янында дәвам итә. Шунда җәйге концерт залы да эшләп куйганнар. Үзенә күрә сәхнәсе дә, сәхнә каршына тезелеп киткән эскәмияләре дә бар. Республикага танылган биючеләре дә бар аларның. Мәдәният йортында эшләп килүче бию түгәрәгенә 100 дән артык бала йөри. Биючеләргә матур милли киемнәрне хуҗалык җитәкчесе үзе тектерде, диделәр безгә.

Исеме төрле чорда төрлегә үзгәргән әлеге «Вахитов» исемендәге авыл хуҗалыгы продуктлары җитештерү кооперативын Нәфыйк Хөсәенов җитәкли башлавына да чирек гасыр узып киткән. Хезмәт юлын армиядән кайтканнан соң туган авылында бригадирлыктан башлап, зур дәрәҗәләргә ирешкән, гомер буе «Күктән йолдыз чүпләмәскә, ә җир кешесе булырга – иген игәргә, икмәк үстерергә!» дигән сүзенә тугры калган, үзен республикада оста оештыручыларның берсе буларак таныткан кеше өчен бер адым алга китүнең дә никадәрле зур уңыш, никадәрле зур казаныш итеп аңлау кыен булмас, минемчә. Чөнки бер адым алга дигәнебез көн саен бит ул!

ҖӘМГЫЯТЬ

Татарстан Президенты вазыйфасына «Бердәм Россия» партиясеннән кандидатлар тәкъдим итү буенча праймериз үткәрелде. Әлеге чарада ТР Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов җиңү яулады. Праймериз иҗтимагый оешмалар тарафыннан беренче мәртәбә уздырылды. Татарстанда гына түгел, гомумән, Россиядә дә андый тәҗрибәнең булганы юк иде. Анда меңләгән кеше катнашты.

Мәскәүдә Кызыл мәйданда китап фестивале узды. Россия Президенты Владимир Путин «Россия китаплары» күргәзмәсен карап йөргәндә Татарстан китап нәшрияты стенды янында да тукталды. Дәүләт җитәкчесе Татарстанда нәшер ителгән китаплар, аларның кайсы телләрдә басылуы, китап укучылар булу-булмавы белән кызыксынды. Владимир Путинга китап нәшрияты директоры Илдар Сәгъдәтшин Габдулла Тукайның 15 телдә нәшер ителгән «Шүрәле» китабын бүләк итте. Бу китап — Россиянең иң яхшы 100 китабы арасында.

КОТЛЫЙБЫЗ



Балалар һәм яшьләр матбугатының «Алтын каләм» республика фестиваленә быел 20 яшь! Казаннан һәм республиканың 25 районыннан 120 дән артык бала «Волга» Яшьләр үзәгенә юбилей фестиваленә җыелды. Фестиваль кысаларында дәүләт эшлеклеләре, депутатлар белән очрашулар, атаклы журналистлардан мастер-класслар каралган иде. Чыгарылыш сыйныф укучылары Казаннан Данил Зәйнуллин һәм Актаныштан Илсинә Тимерова Гран-прига лаек булды.

МӘГАРИФ



Татарстанда яшь геологларның II кыр олимпиадасы булып үтте. Анда Татарстаннан 30 команда катнашты. Шулай ук Кырымның Бакчасарай районы һәм Казакъстан укучылары да килгән иде. Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов олимпиадада катнашучыларны сәламләп: «Геолог – илебездәге табигый байлыкларны барлый торган кеше. Бу һөнәр иясенә кирәкле күнекмәләр инде мәктәптә үк булырга тиеш», – дип белдерде. Балалар үзара ярышып кына калмады, геолог һөнәре серләренә дә төшенде.

СПОРТ

Казанда спортның су төрләре буенча Дөнья чемпионаты ачылу тантанасын миллиардка якын тамашачы күрәчәк. «Татнефть-Арена» стадионында «Пилигрим» тамашасының репетициясе узды. Аның премьерасы 24 июльдә чемпионат ачылу тантанасында күрсәтелачәк. Әлеге дөньякүләм вакыйга масштабы белән Универсиаданы да узачак: 190 илдән катнашучы көтелә.



«Казан» гаилә үзәге янында «Сәнгать һәм толерантлык» шигаре белән узучы халыкара күргәзмә ачылды: 114 илнең мини-аюлары һәркайсы бер илнең символы булып тора. Әлеге күргәзмә Нью-Йорк, Токио, Сидней, Буэнос-Айрес халкының мәхәббәтен яулады инде. Дөнья чемпионаты ачылган көндә анда Татарстан аюын да күреп булачак. Һәм ул да, башка аюлар белән бергә, алдагы Дөнья чемпионатларында үзенең лаеклы урынын алачак. Ә «Казан» халыкара аэропорты кырына зур итеп ясалган барслар – Дөнья чемпионаты талисманнары Итил белән Алсу – самолетта чемпионатка килүчеләрне каршылап торачак.

ЯШЬЛӘР



Казанда БРИКС Яшьләр саммиты узды. Биш илне — Бразилия, Россия, Һиндстан, Кытай һәм Көньяк Африканы берләштергән БРИКС халыкара оешмасының яшьләр җыены әле беренче тапкыр гына оештырыла. БРИКС илләре яшьләр саммиты делегациясе вәкилләре үзара хезмәттәшлек турында меморандумга кул куйды. Ул Татарстан лидеры белән очрашу кысаларында үтте. Рөстәм Миңнеханов, саммит вәкилләрен сәламләп, Татарстанның талантларны үзенә тарта торган төбәк булачагына ышаныч белдерде.











Фото: Роза Иалетдинова

ИСЕМЕМ БУЛСЫН САТУЧЫ...

– «МОСКОВСКИЙ» ИҢ АЛДАН КЫЗАРА. «ВОЛГОГРАДСКИЙ» – АНЫҢ АРТЫННАН. «РАКЕТА» ТОЗЛАРГА ӘЙБӘТ...



Гөлнур САФИУЛЛИНА

Әле үсентеләр күтәрелеп кенә килгәндә, читтән караган кешегә түтәлләрнең барысы да бертөрле булып күренүе гаҗәп түгел. Ә Илгизә апа бакчадагы помидорларның бер сортын икенчесе белән берничек бутамый. Һәркайсының үзенә генә хас бер сыйфаты, башкалардан өстен ягы, үзенчәлеге турында сөйләп китә... Помидор, дөресрәге помидор үсентеләре үстерүнең серләрен ишетергә теләп килдек без Аксарга. Зәйдә генә түгел, тирә-юньдә – Түбән Камада, Әлмәттә, Сарманда, Кама Аланында аксарлыларның «помидор үстерүчеләр» дигән даны бар. Илгизә апа белән Раиф абый ШӘЙХИЕВләр исә Аксарның иң оста помидор үстерүчеләре. «Утыз сатучы тезелеп торса да, базарга Раиф абый килеп төшсә: «Бабай килде!» – дип, халык аңа чиратка баса», – диләр.

Уңыш серләре белән бик теләп бүлешteләр алар. Тик әңгәмәбез помидор үстерүдән бик еш читкә дә киткәләде. Ирне зурлау, олылау, хатынны хөрмәтләү, бала тәрбияләү... Гаилә бәхетенең серләрен дә ачып кайттык бугай без.

Илгизә апа: Мин килен булып төшкәндә Аксарда суган да үстермиләр иде әле. 1959 елны килдем. Димәк, помидорга алтмышынчы елларда тотынганбыз... Мин әтине белмим, ул минем тууым турындагы хәбәрне алырга өлгермәгән. Фин сугышында югалган. Әни белән ике генә ел торып калганнар. Әби-бабай, әни янында бик кадерле бала булып үстем. Раиф килеп сораганда унтугызым тулмаган иде. Бабай: «Кыз кешенең вакытында урнашуы хәерле», – диде. Ә әби: «Үзебез дә күреп туймадык бит әле», – дип елап калды... Үзем ялгыз үскәч, гомерем туганлы кешеләргә кызыгып үтте. Шуңа балаларымның да күп булуын теләдем. Ике ул, өч кыз таптым...

Раиф абый: Илгизә утыз ел сыер сауды. Ә мин бригадир да булдым, ферма мөдире дә. Йортка кергән кеше кебек кенә яшәдем өйдә – дүрттә торып чыгып китеп, фермаларны әйләнә идем. Ул вакыт бездә сөт комплексы ачтылар. Халык тырыш Аксарда, берсе икенчесеннән уздырырга теләп, көнләшеп эшли. Бөтенесенең алдынгы буласы килә. Җиңүчеләргә бүләккә телевизор, суыткыч бирәләр иде. Шуңа күрә һәрберсенә буаз тана кирәк. Тиз кирәк! Чәчләрем шул вакыт ук агарды... Аннан кырчылыкка күчтем.

Илгизә апа: Мөнир, Барый абыйлар башлады помидор үсентесе үстерүне. Без дә кешедән алдарак тотындык. Кызган тирес өстенә утырта идек башта. Мал күп асрый идек, тирес күп була иде. Помидорның файдасын күрә башлагач, җиргә дә утырта башладык. Җирдә дә үсә икән! Шулай елдан-ел арттырдык. Ничә төп икәнен кем белгән? Без аны гел парник саны буенча гына санадык. Шуның янына унар стакан орлык суган утыртабыз – аны сатабыз. Кул юарга да вакыт булмаган чаклар иде: салкын чәй эчәбез дә фермага йөгерәбез.

Раиф абый: Ул чакта помидор бик үтә иде. Машина яллап Түбән Камага бара идем дә, ике тапкырда сатып та бетереп кайта идем.

Илгизә апа: Безнең бабай помидорга бик иртә – март ахырында ук тотына. Ә башкалар көн җылыткач кына утырталар да, кояш җылысы белән үсентеләр тиз күтәрелә, яше исә яшь була – помидоры тиз төшми. Быел гына өйдә үстердек әле, мал тотканда, тирес булганда – гел парникта булды. Помидор өчен ат тиресе бик файдалы. Тиресне бабай кыш буе күчкә өеп килә, иртә яздан бозын, карын түгә, кызсын өчен өстен каплап куя. Аннан парниклар ясый башлый. Рамнарын ремонтлый, пленкаларын рәтли. Безнең парниклар үзебез ясаган гына. Быел помидорны утыздан артык тәрәзә астында утырттык. Йөзәр тәрәзә асты булган чаклар бар иде. Парникларны ачкач, көн җылыткач, тәрәзәләрне җыябыз. Кышка түбәгә менгезеп, өеп куябыз.

Язын тирес кыза, аннан пар чыгып утыра: шул тиресне таратабыз да, орлыкны парникка гына чәчәбез. Өч көндә тишеләләр. Җылы булгач, тәрәзәсе парланып, җылы су тамып тора.

Раиф абый: Әйе, халык хәзер яшелчәне ай календарена карап кына утырта. Минем дә хәзрәтләргә бу хакта сорау биргәнем булды. «Ислам динендә андый нәрсә юк, дәлилли алмыйбыз», – диделәр. Ләкин барыбер колакка керә шул. Аллаһы Тәгаләдән сорап, догаңны кылып, бисмилланы әйтеп утыртсаң, үсәр, уңар, иншалла. Барысы да Ходайның көне.

Илгизә апагыз әйтте инде, помидорлар өч көннән тишелә. Суны үсентеләргә җылытып сибәргә кирәк. Мин ике көнгә бер сибәм. Мал өендә махсус җылытам.

Балалар үстергәндә файдасын бик күрдек помидорның. Иллешәр, җитмешәр меңлек саткан еллар булды. Биш балабызга да югары белем бирдек. Өчесе Казанда, икесе Чаллыда укыды. Балалар үз тормышларын корганда – йортлар салганда, машиналар алганда да булышырга тырыштык. Һаман шул помидор аркасында... Өчесендә – икешәр бала, икесендә – өчешәр. Оныкларга бай без!

Август аенда Раиф абый сигезенче дистәсен тутыра.

Илгизә апа: Кайбер кеше үсентеләрне саклый алмый, өшетә. Безнең бабай саклый! Утырткан һәр төп помидоры үсә аның. Һава торышын тыңлап кына торабыз: кырау дисәләр, хәзер чыгып китә, каплый. Хәер, бер елны шулай утырткач, кырау төшкән иде. Алай булса да йолкымадык – бераздан яңа ботаклар чыгарып үсеп китте.

Раиф абый: Бөтен гаиләгә җитә торган эш ул помидор. Аерганда быел гына үзем аердым менә. Анысы гел кызлар эше иде моңарчы. Җыелып кайталар да, икәү-өчәү эшләп, ике көндә бетереп китәләр иде. Дөрес, көннең уңай туры килүе, җылы булуы да кирәк. Быел Гүзәлиябезнең яшь баласы бар, апасы исә авырып торды. Әниләренең аягы авырта, ул да бакчага чыгып баса алмады. Шуңа күрә үсентеләрне аеру, күчереп утырту үземә калды. Бик ансат эшләдем мин аны. Парник эченә фанера куйдым, шуңа тезләнеп утырдым... Таяк белән юл сызып, утыртып бардым. Үрелеп азапланасы да булмады. Ике көн эчендә бетердем. Араларын 15 см тирәсе калдырам. Куерак та утыртырга мөмкин, әмма алай нәзек булып үсә.

Илгизә апа: Орлыкны без гел үзебез ясыйбыз дисәм дә була. Сортларны үзгәртү өчен кибеттән дә алгалыйбыз. «Менә бу сортны бик мактадылар», – дип кай ара балалар да алып кайта. Ошаса, алдагы елга орлыкны бабай үзе ясый инде аннары. «Ракета», «Колхозница», «Волгоград», «Московский», «Сибирская корона»... Үзебез үстергән бөтен сортларны санадым шикелле. «Колхозница»ны гомер-гомергә утырттык. Аның помидоры күп була, тәмле, салатка да әйбәт.

Әйбәт үсенте үстерү өчен орлыгың әйбәт булу кирәк. Орлык өчен исә куакта иң беренче пешкән помидорларны алабыз. Өзгән килеш ул тәмам өлгереп җитә. Аннары гына сытасың. Шуннан соң, банкаларга салып, ике-өч

көн әчетергә кирәк. Үз суында әчеп, орлыклар өскә чыга. Чиста су белән юып, сөзәбез дә, гәҗитләргә җәеп киптерәбез. Тәмам кипкәч кенә, кәгазьгә төреп, сортларын язып, тартмаларга салып куябыз. Чәчер алдыннан, чыныктыру өчен, 10-15 минут кына марганцовкалы суда тотып алабыз. Аннан тагын чиста су белән юып киптерәбез. Инде орлыклар чәчәргә әзер.... Помидорга дигән туфракны бабай урманнан да алып кайта, фермадан алып, шуңа черемә дә өсти. Имәнле басуында җиңел торф бар – быел тагын шуңа да барды әле.

Раиф абый: Утыртып 15 көн үткәч, су сибеп, төбен бәрәңге өйгән кебек өябез. Өстә өч-дүрт тармак калдырып, астагы ботакларын бутыйм. Саргайган яфракларын алып торам. Помидорлангач, пешә башлагач, һаман өскә үсмәсен дип, өсләрен дә өзгәлибез.

Помидор шактый әрсез ул. Сынганын утыртып куйсаң да, тамыр җибәрә.

Илгизә апа: Сатырга күбрәк Сарманга йөри. Ел да Гүзәлия дә ялын шушы вакытка туры китереп ала иде – әтисенә базарда ул булыша. Сатып алучы, гадәттә, килә дә: «Шул сорт кирәк иде, сездә бармы?» – дип сорый бит. Күп сатучылар: «Әйе, нәкъ шушы сорт», – дип, сораган сорт урынына башканы да биреп җибәрәләр. Ә безнең бабай андый түгел. Гомергә дөрес кеше булды. Биш вакыт намазын калдырмый ул, хаҗга да барды. Сата дип... Безнең дөньябыз җиткән хәзер. Балаларыбызның да тормышлары, Аллага шөкер. Бабай күбрәк мәчетләргә булыша. Мин аннан: «Бүген күпмелек саттың, күпме бирдең?» – дип сораганым юк. «Уң кулың биргәнне сул кулың белмәсен», – ди ул үзе дә.

Раиф абый: Сәдака биргәннән синең малың кимемәс, дигән. Шул очракта гына керәсе малыңа юл ачылып, сәбәбе килеп чыгып тора – минем аны сынап караганым бар инде.

Илгизә апа: Өйлә намазына кайтып та җитә ул сатып бетереп. Тиеннәр санап утырмый: акчасы җитмәгәннәрне дә кире бормый. Карт-карчыкларга очсызракка да бирә, хәер булсын дип – бушлай да. Кайчак кызлар белән: «Исемем булсын сатучы...» – дип көләбез.

Раиф абый: Сату авыр хәзер, ләкин минекен алалар әле. Кайчак бүтән сатучылар килеп: «Бабай, синеке бетәме әле?» – дип сорыйлар. Сатып алучыны җәлеп итү өчен махсус бернәрсә дә эшләмим, кеше миңа рәнҗеп калмасын дип кенә тырышам. Шуңа көтәләрдер үземне. Үткән базарда бер ир хатынын орыша: «Бабай килми», дип, ашыгып алдың, менә бит, килгән», – ди... Теплицада үскән белән минеке кебек ачык грунтта чыныккан помидор бер-берсеннән аерыла шул. Теплицаныкылар, базарда озак басып торсаң, шиңә башлый. Ә без өстенә дә капламыйбыз. Моның серен белмәгән кеше: «Озын булып үскәннәр, димәк, әйбәт», – дип теплицаныкын ала. Белгәннәр – миңа килә: безнең үсентеләр шиңеп тормый, җиргә утыртуга тернәкләнеп, күтәрелеп китә.

Илгизә апа: Безнең бабай бер эшсез тормый! Бакчасын җайга салуга, урманга чыгып китә ул. Себеркегә сап әзерли, себерке бәйли. Аларын ашлык әзерләү пунктыннан килеп алалар. Әле былтыр әзерләгән себеркеләре хәзер дә бар. Сапны үлчәп, кисеп алып кайта, кайткач, каезлый... Беркайчан үсеп утырган каенны екмый ул! Егылган каеннарны яки аскы ботакларны гына ала. «И-и, кемдер каен еккан!» – дип кай көнне бик җәлләп кайта. Яшьләр белми шул... Җиләк җыярга оста безнең әтиебез – кеше берне җыйганда ике чиләк җыя. Туктагач та ничә бара икән яңадан? Алмага кадәр урманнан табып кайта ул.

Бер көнне эше беткән бабайның. Аптырый! «Син миңа берәр эш белмисеңме?» – ди. Балалар: «Йөрмә, әти, җитәр, сиңа нигә кирәк?» – диләр. Ат белән сыерны бетергәнебезгә дә ике генә ел әле безнең. Утыз тавык алды менә, шулар белән мәш килә. Күкәйне кая куярга белмибез. «Балаларны чакыр, алып китсеннәр», – ди. Көзгә симертергә мал ала әле ул.

Раиф абый: Ничә пар себерке бәйләгәнемне кем санаган? Иртәнге намаздан өйләнекенә кадәр вакыт бар минем – рәхәтләнеп урманда йөреп кайтам. Бер җайга салынгач, эшлисең. Илгизә: «Эшләмә, акча сиңа нигә кирәк?» – ди. Мин акча өчен эшләмим, эшләп җаныма канәгатьлек табам бит... Тик ятып көнне ничек үткәрәсең? Намазга да бармасаң... «Сәламәтлек булганда йөрим әле, бакчаны да утыртам, тавыкны да карыйм, эшләмә, чәй куеп торсаң шул җитә», – дим карчыкка.

Илгизә апа: Тишелеп чыкканнарын бик көтә ул помидорларның. Хозурланып карап йөри... Пешә башлаган вакытлары да бик рәхәт. Безнекеләр июль азагында өлгерә. Кемнеңдер әле помидорлана гына, ә синеке инде өстәлдә... Элек ике йөзәр төп утырта идек. Балаларның хәзер бөтенесенең дә үз бакчасы бар, шуңа киметтек.

Шөкер, балалар үзара бик тату, киленнәр белән дә бертуганнар кебек. Кияүләребез дә әйбәт. Авылда: «Балаларыңның бәхетен Ходайдан ничек сорадың, нинди теләкләр теләдең?» – диләр. «Олыларның хәер-фатихасын, догасын алып калдык», – дим. Мин килгәндә йортта сукыр әби – кайнанамның кайнанасы бар иде. Җиде елдан аны озаттык. Каенсеңлем белән дүрт ел тордык. Кырык ел кайнанама килен хезмәте күрсәттем. Әнкәй ирен сугышка озатып, бик яшьли тол калган, тормыш авырлыклары күңелен кырысландырган хатын иде. Сабыр иттем. Бер эш рәте белмичә килен булып төштем мин – дөнья барысына да өйрәтте... Аннан үземнең әнкәй чирләп китте, ике ел аны карадык, озаттык...

Балалар бездән күреп эшләп үсteләр. Кечерәк чакта: «Нигә шуны эшләп куймадың?» – дигәч, «Кушмадың бит», – дияләр иде. «Кушкач, күрше кызлары да кереп эшли, үзегез белеп эшләргә кирәк», – дия идем. Хәзер кайта башласалар куркып торам әнә – эш җиткереп булмый. Киленнәр дә шулай.

...«Аксарлар йокламый да бит алар!» Тирә-күрше авыллар, бераз арттырыбрак, алар хакында шулай диләр. Хәер, нигә «арттырып» дим, бу сүзләрдә хаклык шактый бит!



АНА — БАЛАНЫҢ җирдәге ФӘРЕШТӘСЕ

Ана шәфкате – галәм кебек чиксез, ул безне гомер буе озата бара. Ялгышлардан саклый, алга әйди, яшәр өчен көч бирә... Без, балалар, ананың бу шәфкате, мәрхәмәтенә каршы мәрхәмәт, ярату, хөрмәт белән җавап бирә алсак иде. «Сөембикә» журналы редакциясе һәм «Диалог Ауразия» платформасы берлектә уздырган фоторәсемнәр бәйгесе дә «Ана шәфкате» дип аталды. Өч ел элек журнал битләрендә башланып киткән бу конкурс «Сөембикә»нең сайтында дәвам итте һәм менә аңа йомгак ясалды. Журнал укучылар һәм сайтны карап баручылар арасында иң күп тавыш җыйган җиңүче – Ләйлә Хәйруллина. Аның дүрт һәм алты яшьлек уллары белән төшкән фоторәсеме өчен 800 дән артык кеше тавыш бирде!

Әлфия Сәлахова конкурска килене Ләйсән белән оныгы Булатның фотосурәтен җибәргән иде. Яшь ананың эчке матурлыгы, күңел халәте, баласын яратуы, наз, җылылык чагыла дип таптык без ул рәсемдә. Бүләкне алырга «Сөембикә» редакциясенә аның ире килде – Ләйсән яңа гына икенче мәртәбә әни булган икән!

Ә менә гомер юлыннан инвалид коляскасында гына тәгәри алган Лилия Сәлахетдинова (Буа районы) бәйгене оештыручылар кулыннан бүләкне алырга үзе килде. Бүләк аның биш кыз тәрбияләп үстергән әнисенә бирелде. Кызларының төпчеге – шагыйрә Лилия Сәлахетдинова исеме күпләргә таныш. Лилия бу көннәрдә Казанның «Ярдәм» мәчетендә дин дәресләре алып йөри икән. Менә бит, редакциягә килергә дә җай чыккан! Язмыш сынауларын җиңеп, тормышта үз урынын таба алган көр күңелле кызны тәрбияләүдә әнисенең өлеше бәһаләп бетергесез. «Ана шәфкате» дип аталган бәйгедә исеме зурлап телгә алынырга хакы булган әни кеше ул.


Җиңүчеләргә бүләкләрне язучы һәм шагыйрь, күренекле җәмәгать эшлеклесе, Татарстанның халык шагыйре, республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, халык депутаты, Татарстан Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев тапшырды. Разил Исмәгыйль улы – «Диалог Ауразия» платформасының Татарстандагы оешмасы җитәкчесе дә. «Дөньяның күп төбәкләрендә гаилә институты хәзер югалып бара. Конкурста җиңүчеләрне сайлаганда бала бишеге янында торган анага да күз юкка төшмәгәндер. Түренә бала бишеге элгән татар гаиләләре күбрәк булсын иде. Мин үзем дә сигез балалы зур гаиләдә, шушындый тал чыбык бишекләрдә үскән кеше. Бәйгедә катнашучыларның даирәсе киң булуы сөендерде. Өч бала әнисе Римма Мохитованың рәсемнәре Канададан килгән әнә», – диде ул.

Рәсемдә бишектәге улы Мөхәммәд янында басып торучы әни – Римма Кадыймова. Римма – яшь галимә, тарихчы, Казанның 4 нче гимназиясендә балаларга тарих фәнен укыта. Ул да җиңүчеләребезнең берсе.



РУХИ ДӨНЬЯ – ҖАННЫҢ САДӘ ҺӘМ ИЛАҺИ БЕР КОДРӘТЕ. КҮҢЕЛ САФЛЫГЫ, ХИСЛӘР БАЙЛЫГЫ, ТАЛАНТ КЕБЕК МАТУР СЫЙФАТЛАРНЫ КОЛАЧЛЫЙ УЛ.

Бай рухлы кешенең яшәеше дә, үзен башкалар белән ничек итеп тотуыннан башлап, тормышын ничек итеп алып баруына кадәр, бүтәннәрдә бары тик олы хөрмәт кенә уята.



КИЛЕН СӘЛАМЕ

Ташкентта яшәүче төрле халыкларның гореф-гадәтләре, йолалары, мәдәни мирасы бер-берсенеке белән үтә дә тыгыз үрелгән. Бөек Ватан сугышы елларында Урта Азия дошман кул астында калган җирләрдән качып килгән меңнәрчә халыкның сыеныр йортына әйләнде. Кырыгынчы еллар уртасыннан Советлар Союзында яшәүче төрле милләт вәкилләренең Үзбәкстанга күченә башлавы аларның яшәү рәвешләренә дә үзгәрешләр кертми калмады. 1966 елгы көчле җир тетрәүдән соң, Ташкентка агылучылар саны артты гына. Алар – Үзбәкстанның башкаласын өр-яңадан төзергә килүчеләр иде. СССР заманында барыбыз да дус-тату идек. Дәүләт бәйрәмнәрен дә, дини бәйрәмнәрне дә уртак бәйрәм иттек. Ул чорларда дингә мөнәсәбәт үзгә булса да, бер-беребезгә карата мәрхәмәтле идек, бер-беребезне аңлап яшәдек.

Мәдәни мирасыбызга гарәпләрнең дә йогынтысы бик зур. Алар – Идел буе, Урал, Себер, Кавказ, Урта Азия, Казакъстан җирләрендә ислам динен таратучылар. Ислам дине йолалары – мәҗүсилек чорыннан ук ияреп килгән гадәтләр, шунда яшәүче халыкларның мәдәнияте белән үрелеп, көндәлек тормышыбызга үтеп кергән, төрки телле кабиләләрнең аңында ныклап урнашкан.

Урта Азиядә дини бәйрәмнәр (Корбан, Ураза гаетләре) – бик тә күңелле, мул табыннар артында уза. Аңа шактый алдан әзерләнә башлыйлар. Юу-җыю, пешеренү-төшеренү... Бәйрәм хөрмәтенә өр-яңа киемнәр алына, бигрәк тә балаларны кайгыртталар.

Гарәфә көн – тантаналы көн. Халыкта ул мунча көне булып йөри. Бөтен кеше мунчага агыла. Бөек бәйрәм алдыннан җан гына түгел, тән дә чиста булу шарт.

Бу көнне Ташкентның һәр йортында пылау пешә. Пылаудан тыш, бәлешләр, төрле тәм-томнар чыга табынга. Пылауны күрше-күләнгә дә өләшеп чыгалар. Мохтаҗлар, фәкыйрьләр дә бәйрәм сыеннан мәхрүм калмый. Без үскәндә бу көнне әти-әнием дә күрше-тирәгә пылау таратырлар иде. Пылаудан авыз итүчеләр арасында руслар да, әрмәннәр дә, яһүдләр дә, греклар да, үзебезнең мөселман агай-эне дә булыр иде. Сабый чакта Гарәфә көн безнең күңелләргә тәм-томнан авыз итү көне булып сеңеп калган. Күз алдына гына китерегез, зур касәгә өеп, күршеләр безгә пылау кертә. Пылау өстенә кош теле, бавырсак, печенье, конфетлар да өелгән әле.

Бу гадәт бары тик Ташкентта гына бар, Үзбәкстанның башка өлкәләрендә андыйны күргәнем булмады. Ул, мөгаен, сугыш чорыннан ук кереп калган бер матур гадәт-

тер. Үзбәкстанга эвакуация белән никадәр халык килгән бит! Җирле халык аларга үзләренең аш-суыннан өлеш чыгара. Тирә-күршең белән ризык бүлешү гадәте менә шулай килеп китә.

Әнием күчтәнәч пылауларны аерым-аерым зур яссы тәлинкәләргә бушата. Аны ләгән дип йөртәләр иде. Без исә һәркемнекеннән берәм-берәм авыз итеп, һәркайсына үз бәябезне биреп чыгабыз. Карап торышка төрлесе төрлечә күренсә дә, алар искиткеч тәмле була торган иде.

Урта Азиядә кечкенәләр берсүзсез өлкәннәргә буйсына. Энем кечкенә булганда мин дә йорт саен кереп, пылау өләшеп чыга торган идем. Энем үскәч, бу вазыйфа аңа күчте. Гарәфә көнендә күчтәнәч өләшү шактый авыр хезмәт ул. Җилдәй җитез булып, пылау суынганчы һәркемгә үз өлешен таратып чыгарга кирәк. Урта Азиядә, татар авылларындагыча, күрше төшенчәсе бик киң мәгънәле. Үз подъездыңдагы күршеләрдән тыш, күрше подъездда яшәүчеләр дә бар... Бер мәхәлләдә күп катлы өч-дүрт йорт – һәркайсына кереп чыгарга кирәк.

Ә менә камыр ашларын татарлар кебек оста пешергән бер генә халык та юктыр, мөгаен. Безнең мактанычыбыз ул камыр ризыклары. Иң тәмле бәлешләр, кош телләре, бавырсаклар, чәкчәк, урамалар... Күрше-күлән әниемне еш кына табын әзерләшергә чакыра торган иде. Камыр ризыкларына осталык безнең каныбыздадыр.

Корбан һәм Ураза гаетеише дини бәйрәмнәрдә без, күрше йортларда көн күрүче бөтен бала-чага, бергә җыелып, йорттан йортка «Рамазан» җырлап йөри торган идек. Моның өчен безгә тәм-том, бүләк-мазар бирәләр. Баераклар 10, 20 тиен акча да биргәли. Ул чор өчен шактый зур акча иде ул! «Рамазан» җырларга күбесенчә ир балалар йөри, гәрчә без, кызлар, аерым бер төркем булып йөрсәк тә, малайлар күбрәк була торган иде. Гадәттә, кызлар кыенсына, шуңа күрә төркемебез дә сыек булгандыр инде.

«Рамазан»

Тагын бер кызыклы һәм матур йоланы әйтим әле. Ул «Килен сәламе» яки «Килен гает» дип атала. Бу йола инде берничә гасыр буе дәвам итә. Яшь киленнәр кияүгә чыкканнан соңгы беренче гаетләрендә ирләре йортында бик мул итеп бәйрәм табыны кора. Бу көнне ул йортка һәркем, хәтта бер дә таныш булмаганнар да кереп, «Килен сәламе» бәйрәмендә катнаша, рәхәтләнеп сыйлана һәм яшь килен белән таныша ала. Табынны килен ягы әзерли. Теләсә, кияү ягы да булышырга мөмкин. Шактый чыгымлы йола бу. Ул көнне кыз туып-үскән өйдә тәм-том пешерелә. Бәйрәм алдыннан бөтен туган-тумача җыелышып, табын әзерли. Табын Гарәфә көнгә әзер булырга тиеш. Бәйрәмгә яшь килен өр-яңа киемнәрен кия, башына зур матур яулык яки бөркәнчек яба һәм бу көнне йортына аяк баскан һәркемне өч тапкыр баш иеп сәламли. Менә шуңа күрә бу «Килен сәламе» дип атала да инде. Өстәлләр тәм-томнан сыгылып тора. Табынга, гадәттә, пәхләвә, парварда, нават, тортлар, үзләре пешергән печенье, кош теле, урама, самса, юпка һәм башка баллы тәгамнәр куела. Болардан тыш, күп итеп чикләвек, җәй айлары туры килсә, җиләк-җимеш тә була. Кайнар ашлар чыгарыла. Беренчегә – шурпа яки маш хурда (маштан пешкән аш) бирелә. Икенчегә – манты яки пылау. Тагын әле кайнар һәм салкын кабымлыклар – норин, хасип... Бу көнне кызның туганнары төшке аш вакытына турылап килә. Дөрес, озаклап утырмыйлар, чөнки бәйрәм көнне алардан башка да кунаклар бик күп киләсе әле.

Балалар «Килен сәламе»нә өерләре белән йөри. Без дә шулай бер төркемгә берләшеп, тирә-юньдәге яшь киленнәрнең һәркайсына керәбез, сыйланабыз. Аннан соң инде кайсы киленнең чибәррәк булуын, кемнең табыны мулрак әзерләнүен рәхәтләнеп тикшерәбез. Әлбәттә, без бала-чаганы кадерле кунакны каршылаган кебек, баш иеп каршы алмыйлар. Хәер, безнең өчен анысы әллә ни мөһим түгел, иң кызыгы – яшь киленне күрү, тәм-том белән сыйлану бит!

Киленне сәламләргә кергәч, «күп яшаң», ягъни озын-озак яшә дип әйтү мәслихәт.

Үсеп, җиткү кыз булгач, «Килен сәламе»нә мин инде үземнең дус кызларымны сәламләү өчен йөри башладым. Мине инде бу йортларда кадерле кунак урынына каршылыйлар, ир йортында ничек яшәүләрен сөйлиләр, серләре белән уртаклашалар иде. Бу бәйрәмне үземнең дә әзерләшкәнем булды. Тегүчегә күлмәк тектерергә дә биргәләп баргаладык. Гаеткә яшь килен бәйрәм бирнәсе – гает сәрпә әзерләргә тиеш.

Башкалар үз гадәтләрен күпме генә тагарга тырышмасын, төрки халыкларның йолалары гасырлар дәвамында үзгәрмичә сакланып калган.

Беренче гаетнең матәм, күңелсез вакыйгалар белән бер көнгә туры килгән очраклары да булгалый. Мондый чакта да йортка кешеләр килә, Коръән укыйлар, табын коралар. Бер дә таныш булмаган кешеләр килеп тә дога кылып чыгарга, мәрхүмнең җаны җәннәткә керүен теләп китәргә мөмкиннәр. Мәетне искә алу мәҗлесләре өчен пылауны фәкать ирләр генә пешерә. Хатын-кызлар табын хәстәрли, соңыннан җыештыра. Кайчак табынны да ир-атлар үзләре кора.

Руханилык дингә генә кайтып калмасын. Динилек руханилыкның бер билгесе булса да, идеалда кешеләрне һәм җәмгыятьне рухи үстерү өчен хезмәт тә итәргә тиеш ул.

Гает – Шәрыктагы үзгә бер матур бәйрәм. Аны олысы-кечесе зурлап, тантаналы итеп билгеләп үтә. Гает көнне кешеләр дә ягымлырак, игътибарлырак, шәфкатьлерәк, сабыррак... Барлык ачу-үпкәләр дә гафу ителә. Күңелләр ихлас булгангадыр бу, мөгаен.

Рәмзия КАШАПОВА

...Илленче еллар ахыры. Өремче шəһəре, Шəркый Төркестан. Алар – Синьцзян медицина институтының берничə студенты илдə барган гаделсезлеклəр белəн килешмичə, көрəш юлына басалар. «Шəркый Төркестан хезмəттəш халык партиясе» оешмасы шулай төзелə. Оешманың төп максаты – Шəркый Төркестанны Кытай басымыннан азат итү, бəйсезлеккə ирешү дип саный яшьлəр. Шəркый Төркестанның үз хөкүмəте булырга тиеш! Тик алар яшерен оешмаларына исем табарга, байрагын, программасын булдырырга гына өлгерəлəр. Арада хыянəтче барлыгы ачыклана. Кулга алулар башлана...
Ять-яшь Сөенгөлне дə төрмə көтə. Туры сүзле, кыю, тəвəккəл, башбирмəс татар кызы анда бик күплəрнең таянычына, терəгенə əйлəнə. «Күз яшьлəре белəн сугарылган җир» дигəн китап миллəттəшебезнең төрмəдə күргəн газаплары, анда очраткан язмышлар турында. Бүген без сезгə аннан бер өзек тəкъдим итəбез.
Сөенгөл ханым ЧАНЫШЕВА бүгенге көндə Австралиянең Аделаида шəһəрендə гомер итə.



КҮЗ ЯШЬЛƏРЕ БЕЛƏН...

Гөнаһсыз Фатигөлнең фаҗигасе

Бүген без йокыдан соңрак уяндык. Иртəнге аштан соң Гөлниса одеялсыз, матрассыз кешелəргə одеял, матрас таратты. Саламда гына йоклап йөргəн хатыннар шатланышып урыннарын рəтли башлады. Мин Саҗидə белəн бергə одеялымны ямарга утырдым. Шул чагында Айшəмнең акрын гына җырлаганы ишетелде:

Атасы үлмəгəн кем бар?
Анасы үлмəгəн кем бар?
Чит кеше йортына барып,
Мосафир булмаган кем бар?

Саҗидə «Афəрин!» дип кул чапты. Айшəм урта буйлы,ябык кына бер хатын иде, битендə чəчəк чиреннəн калган шадралары да бар. Ул үткер телле, шуның өстенə бик матур итеп милли җырларны җырлый иде. Без аны бирелеп тыңлый идек. Безнең өчен Айшəм шушы җансыз чүлгə яшəү көче алып килгəн бер былбыл кебек булды. Айшəм безгə карап:

– Мин сезне бик кызганам, кызлар, – диде. – Сез бит табиблар, ə үзегез менə монда, сезгə монда нəрсə бар?

– Алай димəгез, Айшəм. Башкаларга ничек булса, безгə дə шул инде, – дип җавап бирдем мин.

Айшəм безнең янга килеп утырды да:

– 1959 елда сезнең институттан бер бик чибəр кызны алып килгəннəр иде. Фатигөл исемле, Чөгүчəкле, бəлки белəсездер дə, – диде.

Айшəмнең шушы сүзлəре 1959 елда институтта үткəрелгəн кампанияне исемə төшерде. Зур залда студентлар белəн укытучыларны, хезмəткəрлəрне, табибларны, шəфкать туташларын җыйдылар. Монда партиягə, хөкүмəткə, социализмга каршы дип табылган «уңъякка авышучыларны», «уңъякка баручыларны», «миллəтчелəрне» тəнкыйть итү чарасы үткəрелде.

Исемдə, бер көнне, докладны туктатып, кулга алына торган студентларның исемнəрен игълан иттелəр. Шундый тəнкыйтьтəн соң берничə кешене богаулап алып

киттеләр. Аның берсе – Имам исемле 18-19 яшьлек студент – «уңъякка авышуда» гаепләнгән иде, аның башына калпак кидереп, кулга алдылар. Игътибарымны җәлеп иткән икенче кеше – чибәр Фатигөл булды, аны караклыкта гаепләделәр, «җинаятьче карак» дип атадылар. Кунакка барыр өчен иптәшенең кофтасын алып торган икән. Шул чакта мин: «Берәр иптәшем минем кофтамны яратса, үзем кимәсәм дә, аңа бирер идем», – дип уйладым...

Айшәм сүзен дәвам итте:

– Мондагы шартларны Фатигөл күтәрә алмады. Бер елдан соң баш авыруыннан үлде ул. Аның кабере монда. Туры килсә, мин сезгә күрсәтермен.

Имһанәмнең башыннан үткәннәре

1963 елның 28 декабрь көне, шимбә. Салкыннар бик көчәйгәч һәм Яңа ел якынлашу уңаеннан, безгә бер атналык ял бирделәр. Төштән соң кием-салымны ямарга утырдым. Яныма Имһанәм килде дә, сөйләшеп киттек. Имһанәм бу лагерьда байтак утырган икән. Башта аны өч елга утыртканнар. Төрмәдән чыгып, бер ел үткәч, тагын кулга алып, ике елга утыртканнар. Шул елларда ул күп мәртәбә качып караган. Имһанәм миңа үзенең ачынышлы язмышы хакында түбәндәгеләрне сөйләп бирде.

...Әниемнең миннән соң ун ел буе баласы булмаган. Ун елдан соң гына әнием бер угыл тапкан.

Мин гаиләдә ата-анамның җаннарыннан да газиз күргән иркә баласы булдым. Безнең тирәдә мәктәп тә юк иде, мин урамда балалар белән уйнап үстем. Ундүрт яшемә кадәр мин өй эшләрен дә өйрәнмичә, бернәрсә дә белмичә, иркәләнеп яшәдем. Әти-әнием, үзләре ашамыйэчми, үзләре кими, бар тапканнарын миңа тоталар иде. Алар бик тату тордылар, мин аларның бер вакытта да кычкырышканын, талашканын күрмәдем. Бер-берсенә «әтисе», «әнисе» дип кенә дәшәләр иде.

Миңа унбиш яшь тулды, шул чакта әтием һәм әниемнең үзара үпкәләшеп, сөйләшми йөргән чаклары да була башлады. Бигрәк тә өйгә кунаклар килгәндә ачуланышып китәләр иде. Мин аларның ни өчен үпкәләшкәннәрен аңламый идем.

Бер көнне урамнан йөгереп керсәм, алар тагын сүз көрәштерәләр. «Имһанәм әле бәләкәй, аны теге йортка бирергә мин килешмим, – ди әтием. – Үзебез белгән, үзебезгә ошаган йортка бирсәк, димен. Әнә Кадыйр ахунның угылы Абдулла Кәрим ятим егет, шуңа бирик». Әнием аңа каршы килә: «Куй әле шуны. Апамның угылы Гафурҗанга бирик. Кызыбыз зур шәһәрдә рәхәт тормышта яшәсен, димен. Әй, әтисе, сез нигә шуны уйламыйсыз?» Әни ачулана иде.

Әниемнең апасын бөтенләй күргәнем юк минем. Аларның тормышы безнекеннән хәллерәк булгач, алар әниемне эзләп тә карамадылар. Әни үзе аларга, Кучар дигән җиргә, бер-ике мәртәбә барып кайткан иде.

Унҗиде яшемә чаклы әнием мине беркемгә дә бирдертмәде, апасының угылына саклап ятты. Шул арада ул миңа такыя, жилет, кызыл ефәктән күлмәк-ыштан текте. Әнием әтиемне ризалаштырган, ахрысы. Әтием үзебезнең хуҗалыктагы бер үгезне сатып, миңа тагын кием-салым алып бирде.

Бер көнне кичен алар йокламыйча мине әзерләделәр. Иртә белән әтием ишәкне җигеп алып килде. Арба өстенә матур ефәк юрган салды, ишәкнең муенына матур гөлләр тагып куйды. Әнием чәчләремне вак-вак итеп үрде, киемнәремне кидерде: кызыл ефәк күлмәк, яшел чәчкәле өске кием, озын ыштан. Яшел такыя белән яңа алынган кара ботинканы кидем, барысы да миңа бик килеште. Көзгегә карасам, бүген бигрәк матур булып киткәнмен.

Әтием мине ишәккә атландырды, эне-сеңелләремнән берсен алдыма, икенчесен артыма утыртты да, ишәкне җитәкләп юлга чыкты. Әнием дә безнең белән бара иде.

Кучарга килеп җиттек. Олы апам ишектән: «Килен кызым килгән», – дип каршы алганда гына үземнең туема килгәнемне аңладым. Ике көн үткәч, Өремчедән олы апамның улы кайтты. Ул миннән байтак кына өлкән булса да, апамның: «Гафур хезмәткәр кеше, зур шәһәрдә яши», – дигән сүзләре аның бөтен кимчелеген дә каплый иде.

> *Туй үтте, ике көннән соң без Өремчегә китәргә җыендык. Монда килгәннән бирле әтиемнең күз яшьләре кипмәде.*

Сакалларыннан тамган күз яшьләрен күргәндә йөрәгем сыкрый иде. Аның елаганы исемә төшсә, хәзер дә күңелем бозыла. Без почмактан борылып киткәнче әтием елаган көе калды. Әнием, киресенчә, бик куанган иде, мине җәннәт ишегеннән кертеп куйган диярсең.

Өремчедә без бер биек өйдә тора башладык. Өремче миңа бик күңелле һәм матур булып күренде, үземне бәхетле дип хис иттем. Гафур мине кадерләп кенә торды, аш пешерергә, өй җыештырырга өйрәтте. Иң кызыгы шул булды: безнең өйгә Гафурның иптәшләре кунакка килгәч, Гафур лагман әзерләмәкче булды. Ул миңа: «Син яшелчәләрне тура, камыр әзерлә, мин сәй куырам», – диде. Гомеремдә камыр җәйгәнем юк бит минем. Дустым Айшәмнең өендә Хәлче апаның ипигә камыр әзерләгәнен генә күргәнем бар иде. Бөтен чүпрәне салып, камыр әзерләдем. Гафур сәйләрне куырып, суларын кайнатып куйды. Ә минем камырым бер дә сузылмый, суда пешергәндә симереп, юанаеп чыга. Гафур моңа аптырады, нигә шулай булганын миннән сорады. Мин бөтен чүпрәне дә салып җибәргәнемне әйтеп бирдем. Гафур үзен-үзе туктата алмыйча озак көлеп утырды. Мин бик оялдым, ике битем уттай янды. Башкача камыр әзерләп, лагман пешердек, кунакларны сыйлап озаттык. Шуннан соң Гафур еш кына: «Лагманга чүпрә салган ап-ак ханым», – дип көлә иде.

Без матур һəм күңелле яшəдек. Бер ел буе өйне үзем карап, аш һəм ипи пешерергə өйрəндем, бөтен нəрсəне үзем эшли башладым. Гафур миңа базардан матур киемнəр алып кайта иде, менə шул чакта һичкем дə кимəгəн асыл йоннан күлмəк кидем. Мин инде теге озын ыштан киеп, чəчлəрен вак кына итеп үреп йөргəн авыл кызы Имһанəм түгел идем, ə чибəр Өремче ханымы булып калдым. Матур киемнəр мине тагын да чибəррəк итə иде. Кайчагында көзгегə карап, үземə үзем ышанасым килми иде.

Имһанəм чынлап та чибəр иде: килешкəн гəүдəле, озын күе кара чəчле, күе кара кашлы, зур кара күзле. Аның гүзəллеген бер генə нəрсə каплап тора: ул назлылыгы, сөйкемлелеге булмаган, укымаган надан кеше иде.

Бер көнне Гафур эштəн күтəренке күңел белəн кайтып керде. Ишектəн керер-кермəс үк ул:

– Имһанəм, бүген кызык кино бар икəн, Сезгə билет алып кайттым, – диде.

– Сез бармыйсызмыни? – дип гаҗəплəнеп сорадым мин.

– Бүген идарəдə азрак эшем бар, Сез күрше кызы Хөршидə белəн барыгыз. Бик кызык кино булгач, Сез күрсен дип, билетлар алдым, – диде ул. – Əллə бу эш Сезгə ярамадымы?

– Юк, ярады, барам, – дип көлдем мин.

Барып кино карадык. Кино беткəч тə, Хөршидə белəн икəү башкалардан алдарак чыгып киттек. Өйгə кайтсам, ишек бикле, ə эчтəн Гафурның тавышы ишетелə.

– Гафур, ач ишекне, – димен.

Ə ул ачмый:

– Бар, тагын бер əйлəнеп кил əле, – ди.

Шул чакта эчтəн бер хатын тавышы ишетелде. Мин аптырап калдым.

– Ач ишекне, – дип кычкырып, ишеккə суктым, типтем. Ишекне көч белəн этəргəн идем, ул урыныннан кузгалып, авып та төште.

Үземə шулкадəр көч кайдан килгəндер, белмим, юлбарыстай өйгə атылып кердем. Караватта бер ялангач хатын утыра икəн. Караваттан сөйрəп төшереп, башына, күзенə карамастан, кыйнап, тибеп ташладым. Ашыга-ашыга киенеп өлгергəн Гафур бу хатынны минем кулдан тартып алмакчы булды. Минем аркама, җилкəлəремə суккач, башым əйлəнеп китте, егылдым. Теге хатын, җанын саклап, ялангач көе урамга чыгып йөгерде. Кинодан чыккан халык аптырап ялангач хатынның йөгергəнен карап торган. Гафур аның киемнəрен чыгарып биргəн. Өйгə кереп, ул миңа:

– Нишлисең син, юньсез! – дип төртеп җибəрде.

Үземне үзем тотып тора алмадым. Өстəл өстендə яткан бер нəрсəне алдым да Гафурга таба атып бəрдем. Гафур егылып төште, битеннəн кып-кызыл кан ага башлады. Куркуымнан урамга йөгереп чыктым:

– Кеше үлде! Кеше үлде! – дип кычкырам үзем.

Өйгə кешелəр тулды. Гафур үлек кебек ята, кан туктамый ага, башында унбиш сантиметр озынлыкта яра бар икəн. Гафурны җəллəп, туктаусыз елыйм. Минем кулыма элəккəн, атып бəргəн нəрсə бер зур пычак булып чыкты. Сакчылар, докторлар килде, Гафурны күтəреп алып чыктылар. Миңа: «Ярый əле, бəхетеңə каршы, ирең үлмəгəн, – диделəр. – Үлсə, синең үзеңə дə үлем җəзасы бирелер иде».

Мине дə алып киттелəр. Төрмəнең тимер ишеклəрен дыңгырдатып ябып, мине шунда биклəп куйдылар. Үземнең нишлəгəнемне, кайда икəнлегемне дə аңламыйча, тирəн уйга калдым. Шəм яктысында камера эченə күз йөгерттем, унлап хатын-кыз рəт-рəт булып ятканнар, йоклыйлар. Миңа утырыр урын да юк. Ишек тавышына уянган берничə хатын башларын күтəреп карады да тагын йоклап китте. Кайберəүлəр акрын гына сөйлəшə, башкалары берни дə сизмичə йоклый. Ишек катындарак яткан олы яшьтəге бер хатын: «Кил, кызым, монда ят», – дип, үз янынннан кысылып, урын бирде, нəкъ анам кебек өстемə ябып куйды. Лəкин күзгə йокы кермəде: əти-əниемнең, минем бəхетемне уйлап, зур шəһəрдə рəхəт яшəр, дип өмет-лəнгəннəре уема килде. Үземне үзем тыялмыйча сулкылдап еладым. Гафурның канга баткан чырае күз алдымнан китми. Ни булды миңа, шайтан котыртты микəнни?

Таңга таба йоклап киткəнмен дə, төш күрдем. Безнең өй алдындагы елгада дус кызлар белəн дүрт яфраклы тукранбаш эзлибез, имеш. Кинəт ташкын су килеп, безне агызып китте. Бер бата, бер калка агып барам, əти-əни мине коткармакчы булып, бар көчлəренə йөгерəлəр. Мин аларга кулымны сузам, əмма агым көчле, аларны узып барам. Бар көчемə бер кычкырган идем, үз тавышыма үзем куркып уянып киттем. Күңелем нинди авыр хəлдə икəнен əйтеп бетергесез, ихтыярсыз, тагын елап җибəрдем. Янымдагы теге хатын мине кочаклап юата башлады:

– Елама, балам, адəм баласының башына төрле хəллəр төшə. Менə безгə кара, без дə синең кебек адəмбез, нинди җинаять кылганбыздыр, белмибез. Гөнаһсыз килеш яла ягып монда китерделəр. Менə бу яшь кызларның нинди гөнаһы бар? Барысы да синең кебек берəүнең газиз балалары. Елап эш рəтлəнми, сабыр итəргə кирəк.

– Сезнең кебек без дə башта куркып елый идек, – дип кушылды кызлар. – Бəхетебезгə, Патəм апа булды, үз əниебез кебек.

Алар минем исемемне, ничек монда килеп элəккəнемне сорадылар. Мин барысын да сөйлəп бирдем. Патəм апа, мине тыңлагач:

– Сез кылган гаебегез белəн кергəнсез, кызым, ə без бернəрсə дə эшлəмичə элəктек. Миңа алтмыш өч яшь, ирем үлгəнгə ике ел булды. Эшлəгəн урында унбиш сум

акча бирәләр, ул ашарга да җитми. Бик җәфалангач, өч бүлмәле өемнең ике бүлмәсенә Асихан исемле кешене фатирга керттем; берсендә үзем яшәдем. Асихан өч айга гына акча түләде дә, аннары түләми башлады. Мин аңа өйне бушатырга кирәклеген, башка квартирант табарга теләгәнемне әйттем. Ике көннән соң кичен Асихан ике сакчы ияртеп кайтты да, мине гаепләделәр: мин капитализм юлына басканмын икән, фатир өчен югары бәһа таләп итеп, фатирчыларга залимлек кылам икән. Шулай итеп, мин – монда, ә минем өйдә Асихан яши.

Патәмхан ананың сүзләре бетәр-бетмәс, дырылдап ишек ачылды: иртәнге ризыкны алып килгәннәр. Төрмә ашын үзегез күрдегез, мин аны ашый алмадым. Күп тә үтмәстән, ишек тагын дырылдады: бер кытай одеялга төрелгән урын кирәк-яракларын кертеп, идәнгә ташлап китте. Аның артыннан икенче бер ир кереп: «Имһанәм дигәннәре кайсыгыз? – дип кычкырды. – Бу сиңа урын-җир белән кием-салым». Мин бер сүз дә әйтә алмыйча утырып калдым. Кызлар да тынып калды. Якын арада өйгә кайта алмаслыгымны шунда аңладым.

Шул көнне кичкә Шийгобига китереп ташладылар.

Ике айдан соң мине конторага чакырып алдылар. Анда судтан килгән бер кеше мине көтеп тора икән. Салкын караш белән ул букчасыннан бер кәгазь чыгарып, миңа:

– Бу – никахтан аерылу кәгазе, кул куегыз, – диде.

Башым әйләнеп, аягым тетрәнеп китте, бу авыр хәбәр иде. Сүземне әйтә алмыйча, тотлыгып калдым. Гафур җилкәмә сукканнан соң мин шундый булып калган идем.

– Мин яза белмим, – дидем.

Бу кеше кызыл буяулы бер йомшак нәрсә бирде:

– Бармагыңны чылатып, менә шушында бас, – дип күрсәтте.

Мин чыгып киттем. Көткән өметләрем бушка булды.

Бу ләгънәт төшкән Шийгобида өч ел үткәрү кыен иде. Эшеннән дә кыенрагы ачлык булды. Көненә өч мәртәбә кечкенә касә умачтан башка бернәрсә дә юк бит. Килгәнемә ике ай үтте, бер мәртәбә дә итле яки майлы ризык булмады. Көннәр суык, эш авыр, шул каты суыкта бозлы җирне чокыйбыз.

Гафурның килеп, мине алып китүенә өметләнгән идем...

Без аның белән матур яшәдек бит. Шул көндәге эш аның хатасыннан килеп чыкты. Аның җилкәсе бераз тартышып торса, мин гомергә тотлыга торган булып калдым бит. Нәрсә булса да, без бер карында яткан апа-сеңел балалары. «Шуны уйлап булса да, мине коткарыр», – дигән идем. Бу уем да юкка чыкты. Күңелемдә: «Ирем бар, таянычым бар», – дигән уйлар миңа көч бирә иде. Хәзер мин шул көчтән аерылдым. Бу тормышта күп елларны үткәрүне уйласам, югалып калам, беркемне дә ишетмим, беркемне дә күрәсем килми иде. Ике көн авырып, эшкә чыга алмый яттым. «Качып китмәсәм, бу тормыштан котыла алмам», – дигән уйга килдем. Шул уйдан бераз җиңеләйтте, өмет туды...

Җәлилнең дөньяга килүе

Төрмәгә авырлы килеш эләккән Җәмилә беркемгә дә үз хәлен сиздермәде, башкалар белән бергә эшләп йөрде. Бер атна элек ул хастаханәгә киткән иде. 28 февраль көнне эштән кайтсак, кулына сабыен тотып Җәмилә утыра. Барыбыз да аның белән күрешкәч, баланы кулдан-кулга йөрттек. Турниса:

– Малаймы, кызмы? – дип сорады.

– Малай, – дип шатланып җавап бирде Җәмилә.

– Баланың атасына хәбәр итәргә кирәк. Бәлки ул монда килер, ярдәм итәр. Берүзеңә кыен булыр бит, – диде Сажидә.

– Әтисе белә, ул да монда, ирләр төрмәсендә, исеме Исмаил. Балага дип сабын белән тастымал җибәргән.

– Бөтен тапкан нәрсәсе шулдыр инде, – дип кызганып куйды Зөләйха.

– Балага исем бирдегезме? – дип кызыксындым мин.

– Юк әле.

– Әйдәгез, Төрмә дип исем куйыйк, – диде Әминә.

– Баланың ни гаебе бар? – дип каршы килде Сажидә. – Төрмәдә туып, гомер буе шул исем белән йөрсенмени!

– Бәлки Тарим дип атарбыз? Ул бит безнең илебездә агып яткан елга исеме! – диде Хәлчәм.

– Әтисе Исмаил булгач, малайның исеме дә охшаш булсын, Исрафил дип куйыйк, – диде Зорәм.

Һәркем үз фикерен алга сөрде. Мин баланың исеме Җәмиләгә якынрак булуын теләдем. Шуңа күрә Абдуҗәлил яки Җәлил дигән исемнәрне тәкъдим иттем. Моңа Җәмилә үзе дә кушылды.

Бу матур сынлы хатын күп сөйләшми, үзен-үзе тота белә торган кеше иде. Аны «Стиль төзәтү» кампаниясе чорында кулга алганнар икән.

Шулай итеп, бернинди азансыз-нисез генә балага «Җәлил» дип исем куштык. Бу бик матур малай иде, кара күзле, озын керфекле, авызы уймактай, җилкәсенә төшеп торган куе кара чәчләре аны матур һәм сөйкемле күрсәтә иде. Барыбыз да чын күңелдән яраттык бу баланы. Үзебездә булган нәрсәләрдән малайга кием тектек. Маһинур күлмәк белән ыштан тегеп бирде, Патәм дә текте. Үземдәге җепләрдән мин башлык белән жилетка бәйләдем. Шулай итеп, Җәлилебезне киендереп тә куйдык.

Иң начары – Җәмиләнең сөте юк иде, ач тамак белән авыр эштә йөргән хатында каян сөт булсын? Шуңа күрә Җәлил бик еш елый иде. Ул авызын ачып, күзенә күренгән бөтен нәрсәне дә ашарга тора иде. Уйлый торгач, монда да юлы табылды. Кукуруз ипиен чәйнәп бирергә киңәш иттек. Җәмилә шулай итте дә, ә без бала чирләп калуыннан куркып тордык. Тамагы туйган бичара бала шундук йоклап китте.

Уйгурчадан Гриф ХӘЙРУЛЛИН тәрҗемәсе.

КӨТКӘННӘР ДӘШМИ НИГӘ?



Нәҗибә САФИНА

Ут белән язу

М-кә

Мин шигырь язмакчы булам,
Ут камый кәгазь битен, –
Җаныңда уттан да гайре
Берни булмавы читен.

Мин сиңа хат язмак булам,
Каләм сыгылып китә.
Язу түгел, синең хакта
Хәтта уйлау да җитә...

Сиңа багышланган җырым
Җилләр болытка салды.
Авырайган болытларны
Җир ничек тартып алды.

Хис туфаны авырдыр шул,
Җир ыңгыраша, елый.
Туфан хисне кабул итәр
Җаннар бар диеп уйлый.

Миллиард еллар әйләнә җир.
Әйләндерә шул өмет.
Минем йөрәкне яшәткән
Зәррә мәхәббәт кебек.

Бу сүз

Бу сүз болай гадәти ул,
Тик әйтелми гадәти.
Аны әйтү-ишетүнең
Бар үзенең сәгате.

Бу сүз – үзе шундый кирәк,
Үзе шундый куркыта,
Күккә күтәрепләр чөя,
Кабат җиргә ыргыта.

Бу сүз, сүз генә түгелдер, –
Хыял, тылсым, әкият...
Ул сүзне күтеп гомер ит,
Йә булмаса үзең әйт!

Бу сүз шулкадәрле олы,
Бу сүз шундый кечкенә, –
Гомер буе тел очында, –
Әйтеп булмый һич кенә.

Бу сүз – зур да, кечкенә дә,
Бу сүз су да, ут та ул.
Чынлап яшәмәгәннәргә
Җир йөзендә юк та ул.

Бу сүз – тыңдәшсез наз да ул,
Бу сүз – сүнмәс ут та ул.
Йөрәккә иң тирән яра
Сала торган ук та ул.

Бу сүз... канатлар үстерә,
Әйе, бу сүз – «Я-ра-там!»
Минем җандагысы аның –
Бары сиңа ка-ра-та!

Бикли алмыйсың

Көн саен эндәшмисең син,
Атна, хәтта ай саен.
Әллә ялгыз калу өчен
Тапмыйсың инде җаен...

Көн саен эндәшә миңа,
Эндәшә әлләкемнәр, –
Телиләр хәерле иртә,
Иҗади матур көннәр.

Рәхмәт әйтеп кабул итәм
Аларның теләкләрен.
Теләкләрен кабул итәм,
Тик тоймыйм йөрәкләрен.

Сәер халәт: җанда сорау –
Көткәннәр дәшми нигә?
Дәшмәгәннәрнең тавышын
Көтеп җан газап чигә.

Бу минем хәл, әллә синдә
Бөтенләй башка халәт?
Һәр иртәдә эндәш диеп,
Мин бит итмимен таләп.

Эндәш атна-айга тик бер,
Кар да яумый көн саен.
Тик җирне туендырырга
Барыбер таба җаен.

Әллә нигә бер яуган кар,
Кыска вакытлы яңгыр
Булырдай гына җаннарга
Тәүлектә мизгел бардыр...

Шул мизгелне тоя җаным,
Бәргәләнә бит җаның.
Җаныңны биктә тотсаң да,
Бикли алмыйсың чаңын...

Син эндәшкәч

Син эндәшкәч,
Әллә нәрсә булды, –
Юкса ара шул ук, син ерак.
Гомерлек читлеген ташлап чыгып,
Әллә кая очтымы йөрәк...

Кар кызлары
Һаман ул чактагы, –
Синең белән бергә бииләр...
Ләкин миңа: «Син дә ул чактагы, –
Ул чактагы – ять-яшь», – димиләр.

Син эндәшкәч,
Борылдымы вакыт,
Борылдымы гомер атлары?
Борылмады атлар, вакыты да
Искә төшерделәр антларны...

Антлар дигәч,
Әллә нәрсә булды, –
Антлар бирешмәгән икән без.

Язгы сулар кебек ташканбыз да,
Ярларга да кабат кайтканбыз.

Син эндәшкәч,
Хәтер катламнарын
Язгы ташкын чыкты актарып...
Антлар бирмәгәнне белә ташкын,
Ярларына алды кайтарып.

Син эндәшкәч,
Юкса ара шул ук,
Йөрәге дә... шул ук күкрәктә.
Әллә нәрсә түгел, дөрләп китте, –
Очкын... тере булган йөрәктә.

Битәрләү

Бары җандагысы җылы
Сүзләрнең, хисләреңнең.
Көнемә кояш, ае һәм
Йолдызы кичләремнең

Буласың киләме синең? –
Каршы килмим – бул гына!
Әле йөрәк әйтеп тора:
«Миндә – бары ул гына!»

Ышанасы килә генә
Шул йөрәк ярсуына.
Акыл һаман әйтеп тора:
«Элгәре барсын уйла!»

Шул икенең тартышуы
Гомерләрне кимерә.
Төзелгән бәхет сараен,
Тәхетләрне җимерә.

Ә икесе бергә алар
Бер аяктан атламый.
Акылны – йөрәк, йөрәкне
Акыл бер дә якламый...

«Акыллым», – дисең дә миңа,
Мин тыңлыйм йөрәгемне.
Акыл – каршы, йөрәк кенә
Сиздерә кирәгенне...

Сөйгәннәр айга карый шул,
Йолдыз илендә йөри.
Исәр икәнне белсәң дә,
«Акыллым», – дисең юри.

Йә акылга, йә йөрәккә
Һаман да алдалыйсың.
Син дә белмисең дөресен,
Шуңа да ялганлыйсың.

Ә мине... аңламыйсың.



ЯЛКЫН-КАЛӘМ – КУЛЫМДА...

Флёра ГАТИНА

* * *

Мин яраткан гөлләр, дисәм,
син үзең – җәйге болын,
Чәчләреңнең бөдрәсендә
җил җырлый урман җырын.
Идел дулкыннары, дисәм,
чайпала ефәк толым,
Ялгыз аймы бүләк иткән
ялгыз көйләгән моңын.
Сагыш күлләреме, дисәм,
ерак йолдызның нурын,
Сөю-сәгадәтне көтә
җиләкле җәйге болын.

* * *

Хәтердә – далада калган кайнар учак,
Пар йолдызлар булып атылган
ул яшь чак.
Йолдыз-күзләреңнән кабынган ул учак,
Пар аккошлар булып талпынган
ул яшь чак.
Язгы ташкын-сулар агызган ул учак,
Карлы-боз суларга агылган ул яшь чак.

* * *

Ярларымнан тулып-ташып,
агылам дулкын сыман,
Ал син мине үз ярыңа –
язларымда юксынам.
Юк, килмисең, йөгермисең,
син – ерак калган томан,
Мин – далада сине җуйган,
җил өзгән ялгыз кылган.

* * *

Йөгердем, кердем суларга –
йөзә алмадым,
Ялкын дөрли учагымда –
нигә калмадың?!
Такыялар үргән идем –
нигә алмадың?
Гөлләремә ләйсән булып
нигә таммадың?!

Җырларым

Җырлар мине әйди-әйди
ашкындыра,
Менәлмәгән биеклеккә
табындыра.
Өзелеп калган эзләремне
сагындыра,
Сүзләремне җырлар итеп
кабындыра.
Җырым минем ташкын булып
бөргәләнә,
Кыяларга ургылышып
телгәләнә.
Үтәлмәслек упкыннарга
элгә дә,
Хәлдән таеп, тынсыз ята
күләгәдә.
Җырым белән диңгезләрне
кичәмен дә,
Хәл җыямын ак болытның
түшәгендә.
Ай нурларын бишек итәм
төшләремдә,
Зәңгәр күкнең чыбылдыклы
эчләрендә

Рәхмәтем

Бәллүр Җиһан, бирдең илһам:
Ялкын-каләм кулымда.
Рәхмәтемне сиңа җырлыйм:
Көмеш чыңы җырымда.

Бәллүр Җиһан, бирдең илһам:
Ак йолдызлар юлымда.
Сафлык иңгән ак нурлары
Чыңлый йөрәк кылымда.

Бәллүр Җиһан, бирдең илһам:
Рәхмәт юллыйм җырымда.
Хак Тәгаләм, бирдең иман:
Илаһи моң нурында.
Ялкын-каләм – кулымда...



Алсу ХӘСӘНОВА

Алсу, Алсу! Син булмагач ямансу. Мин аны япь-яшь килеш хәтерлим әле. Алар «Ватаным Татарстан»га өч кыз – Алсу, Гөлгенә, Гөлнара бергә килгәннәр иде. Гөлгенә хәзер Америкада, Гөлнара «Шәһри Казан»да, Алсу менә дөньяларның иң яхшысында. Шулай дип ышанасы килә. Арада иң нечкә күңеллесе, сизгер йөрәклесе дә Алсу иде. Минем җырларымны бик матур итеп җырлый иде ул... Бик тиз күзләренә яшь тыгыла иде аның. Сәбәпләре дә булып торгандыр. Аннары Алсу ныгыды. «Асия апа миңа еламаска куша», – ди торган иде. Әйе, куша идем, чөнки бу дөньяның елатырга гына торганын үз мисалымда белә идем. Үз тиңен тапкач, ул бәхетне татып карады. Хәзер инде ул иҗат бәхете хакында хыяллана иде. Аның «Нокта» дигән хикәясе «Казан утлары» журналында басылып чыккач, уйлана калган идем. Шул нокта Алсуның гомеренә дә нокта куясын кем белгән...

Асия ЮНЫСОВА

ЙОЛА

(хикәя)

Гөлнар чишмәдән чиләкләрен тутырып су алганда кинәт баш очында кычкырган козгын тавышына сискәнеп китте. Йөрәге, дерт итеп, сулкылдап куйды: «Әй Ходаем, яман юрап йөри тагын бу хәерсез», – дип, баш очында әйләнгән кошка ачу белән карап алды. Әбисе козгын кычкыруын бер дә яхшыга юрамый иде бит.

Чишмәдән кайтканда ук көянтәле иңбашы арыган, куллары талган шикелле тоелды. Юк, юк, һич тә сулы чиләкләр күтәргәннән түгел иде бу. Бүген аның нигәдер күңеле тыныч түгел, ул язгы ташу сыман бәргәләнә, йөрәге, күкрәк читлегеннән чыгарга теләгәндәй, еш-еш кага. Җитмәсә, эчне пошырып, иләс-миләс яуган елак яңгыр битләрен чәбәли, җиле тагын – озын толымнарын тузгыта. Башка вакытта җилнең толымнары белән шаяруы рәхәтлек бирә торган иде, ә бүген исә, нишләптер, ачуын гына китерә...

Гөлнар көянтә-чиләк белән өй бусагасын атлап кергәндә, ниндидер төенчеккә абынып, егылып китә язды. Караса, аның бирнә мендәрләре бусагада аунап ята иде. Төенчекне төргән җәймәнең бүселгән читеннән өйдә киеп йөри торган күлмәгенең җиңе күренеп тора...

Гөлнар чиләкләрен идәнгә куеп та өлгермәде, җилләнеп, кайнанасы килеп чыкты:

– Әнә, чүпрәк-чапракларыңны төйнәп куйдым, әллүр өеңә! – дип чәпчеде ул, кулларын болгый-болгый.

– Ничек инде, әни-и-и?! – дип аптырап калды Гөлнар. – Ә Ильяс? Ул ничек?..

– Әнисе ни уйласа, ул да шулай уйлый! Син безгә чит кеше, безгә сыена алмыйсың, – дип төкерек чәчте кайнана. – Әнә, өеңә кайтып җитәр өчен бер сынык ипи ал да, шуны ашый-ашый кайтырсың.

Нишләсен, Гөлнар кайнанасына каршы төшә алмады. Шулай итеп, иренең әнисе аны этеп-төртеп диярлек өеннән куып чыгарды. Урам буенча елап баруын сизмәде дә, чишмәгә суга килгән хатыннарның сүзләрен дә ишетмәде. Тирә-юньдә аның бернинди гаме юк, ул бу мизгелдә берни дә күрми, берни дә ишетми иде. Бүген аның хәлен җырларда җырланган, шагыйрьләр теленнән төшмәгән, гасырлар буе челтер-челтер килеп ага биргән чишмә дә аңлый алмас кебек иде...

Гөлнар, өйләренә кайтып җиткәч, капкалары яңагына сөялеп, тагын үксеп-үксеп елап алды. Бу вакытта әбисе, ниндидер күңелсезлек барын сизгәндәй, ишегалдына чыккан иде. Оныгының елаган тавышын ишеттеме, капка янына килде. Шунда оныгын күреп, сүзсез генә барысын да аңлады бугай:

– Аллаһ язмаган эш булмас, кызым! – дип сөйләнә-сөйләнә, Гөлнарны өйгә әйдәкләде. – Тынычлан, кызым, сабыр бул!

Тирә-якка дистәләгән чишмәләре белән танылган Чишмәле – зур авыл.

Казан янында булганга күрәдер, халык биредә шәһәр тарафына китәргә бик атлыгып тормый, шушында төпләнеп кала. Аны яшьләр дә үз итә, яңа өйләнешкән парларның да күбесе Чишмәледә калуны хуп күрә. Яңа өйләнүчеләр яңа йортлар сала-сала бер урам барлыкка килде инде! Хәер, тирә-ягын урман уратып алган, гүзәл табигать кочагына сыенып утырган авылдан кемнең китәсе килсен?!

Чишмәледә халык гореф-гадәтләргә тугры. Чишмәле егетләре кыз урлау белән данлы. Элегрәк ат чанасына яисә арбасына салып урласалар, хәзер заманча кыланалар – машинага утыртып алып китәләр.

Гөлнарны да урладылар. Әтисе, бу кыз югары уку йортына керер, икътисадчы булыр, безнең шикелле тирес арасында йөрмәс, дип өмет иткән иде дә... Юк шул, багалмасы унберенче сыйныфны да тәмамлап өлгерә алмады – урлап алып киттеләр. Гөлнары кебек зифа буйлы, озын толымлы, шомырттай кара күзле кызларны авыл егетләре, төнге ябалак сыман, сагалап кына торалар!

Алар Ильяс белән күп булса ике ай гына очрашып йөрделәр. Гөлнар артык тыйнак, оялчан кыз, егетләрнең күзләренә туры карарга да ояла, хәтта курка да иде бугай. Хәер, күңелен фәкать укуга биргәнгә, җилбәзәкләнеп йөрергә аның вакыты да булмады.

Ильяс белән алар очраклы гына сөйләшеп киттеләр: аның бию түгәрәгеннән кайтып килеше, ә егетнең туган апаларына барышы иде. Сөйләшеп бара торгач, сүз кызның мәктәптән соң икътисад вузына керү теләгенә кадәр барып җитте.

– Белмим, бу кызлар нигә шулкадәр Казанга ашкына икән?! – дип гаҗәпләнде Ильяс.

– Нигә аларның шәһәргә китүенә каршы әле син? – диде Гөлнар, бераз кызара төшеп. Егетләр белән сөйләшкәндә нигәдер аның йөзе алмадай кызарып чыга, һәм шулчак бит очында матур гына чокыр барлыкка килә.

– Чишмәленең чибәр кызларын югалтудан куркам, – диде егет.

Аның тел төбендә ни ятканын аңлавы авыр түгел иде. Авылдан киткән кызларның барысы да шәһәрнең иркен тормышына чумалар да, йөгәннән ычкыналар, дип уйлый иде ул. – Чишмәле егетләре бик дөрес уйлый: кызларның асыллары калага китеп тайганчы, аларны чыннан да урлап калырга кирәк! – дип, Ильяс мыек астыннан елмаеп куйды.

– Урламыйча гына яучылап алсагыз ярамый, алайса?

– Ничек ярасын, ди?! Бабайлардан калган йола бит бу! Буыннан-буынга күчеп килгән йоланы бозарга ярамый.

– Беләсең килсә, кыргый йола бу. Тирә-яктагы авылларда мондый йолаларның берсе дә калмаган, – диде Гөлнар ярсый төшеп. – Кызлар мәче баласы түгел, кемнәрнеңдер кадерлеләре, бәгырь җимешләре!

– Карале, нигә ярсып киттең әле син?! Әллә авылга яңа йола кертергәме исәбең? Ярар, алайса, сине сорап кына алырлар. Яңалыкны беренче булып син кертерсең...

Гөлнар, Ильяс белән шулай сөйләшә-сөйләшә, өенә кайтып җиткәнен сизми дә калды.

– Капка төбенә тикле барма! Әти яратмый, сызгырган егетләрне дә өнәп бетерми ул.

– Ярар, алайса, икенче тапкыр килгәндә кош булып сайрармын, – дип елмайды егет.

Кыз аның бу сүзенә әллә ни игътибар бирмичә, өйләренә кереп китте.

Алар яңадан 8 Март бәйрәме көнне очраштылар. Ильяс укучылар оештырган «Ягез әле, кызлар!» бәйгесен карарга килгән иде. Гөлнарның җырлавын җаны-тәне белән бирелеп тыңлап утырды. Аның хисләнгәнен күргән ахирләре:

– Әллә урлыйбызмы, ә? Инде сиңа өйләнергә дә вакыт җиткәндер! Кыз Казанга китеп барса, соң булачак бит! – дип коткы салып куйдылар.

– Шаяртмагыз әле, зинһар! Әтисе усал аның! Оныттыгызмы әллә, авылда аны Тимер Закир дип йөртәләр. Сукса, җиргә сеңдерәчәк! – диде Ильяс.

– Кайгырма юкка! – диде кыз урлап остарган Марат дусты. – Тимер Закир ишене генә күп күргән! Урлап, күрше авылга алып китсәк, шайтаным да таба алмый!

...Алар клубта кино буласы шимбә көнне көттеләр. Бераз батыраеп китсен дип, Ильяска бераз гына аракы да эчерттеләр. Бу эшкә Марат үзе алынды. Күрше авылда килен өе әзер иде инде. Машинаны клубка якын гына, әрәмә буена куйдылар...

Кино беткәннән соң, халык өйләренә таралыша башлады. Гөлнар белән дус кызы Сүрия дә кайтырга чыктылар. Кыз урларга җыенган егетләр Сүриянең өенә кереп калуын көттеләр – аларга шаһитлар кирәк түгел иде. Алайса, Тимер Закир, дулап, бөтен эшне бозып куюы ихтимал.

Гөлнар ни булганын аңышмый да калды. Аның авызын капладылар да, машинага кертеп утырттылар.

– Нишләвегез бу?! Җибәрегез, минем әле укыйсым бар бит! Әти үтерәчәк сезне!.. – дип тыпырчынды ул.

Закир абзый ул көнне, чыннан да, үтерерлек халәттә иде, валлаһи. Кызын эзләп авылны айкап чыкты, тик аны авылда таба алмады. Аннан эзне тапты ул. Закирның тимер беләге барыбер Маратның авызын ачарга мәҗбүр итте. Кызын эзләп күрше авылга барып җиткәндә таң беленеп килә иде инде.

Ильяс исә әле егет исе кереп өлгермәгән Гөлнарны юмалап, җылы кочагында эретеп йоклаткан, алай гына да түгел, хәтта укыйсым бар бит, дип өзгәләнгән кызны үз ягына авыштырып та куйган иде.

– Мин сине кулларымда гына йөртермен, Гөлнар! Мин сине беркемгә дә бирмим! – диде ул аңа тәмле теллеләнеп һәм, әлбәттә, үзенекен итте...

Тимер Закир, яшьләрне ниһаять эзләп тапкач, кызуланып, бик җикеренгән иде дә, тик аны кызы туктатты:

– Мин калам инде, әти... – дип сыгып чыгарды ул авызыннан сүзен. Чөнки урланганнан соң кире кайтса, кеше ни әйтер, ни сөйләр, авылда гайбәтен таратырлар дип курыкты.

Их, шул вакытта әтисенә ияреп кайтып киткән булсачы!.. Юк, китмәде шул... Язмыштыр, күрәсең. Кеше карбыз түгел, эчен ярып карап булмый. Ул чакта Ильясының холкын кем белгән...

Алар икәүләп Ильясларга кайтканда, кайнанасы Сабира уфылдый-уфылдый идән юып йөри иде.

– Тапкансың, улым, вакытын! Миңа да әйтмәдең, ичмасам... – дип каршы алды ул яшьләрне. Аннары өстәп куйды: – Киленкәй бигрәк тә кечтеки икән...

Ильяс аны-моны дәшмәде. Түр якка уздылар.

– Карале, Ильяс, ниткән бабайлар йоласы соң бу?! – диде Гөлнар гаҗәпләнеп. – Өйләнәсеңне ни әниеңә әйтмәгәнсең, ни мин белмәдем...

– Аның кызыгы да шунда бит! Кыз урлаганны беркем дә белмәскә тиеш. Мәсәлән, минем бабай әбине чишмәгә суга төшкән җиреннән урлап киткән! Әбигә әле унҗиде дә тулмаган булган...

Алар шулай сөйләшеп утырганда кайнананың:

– Әйдәгез, чәй эчәбез! – дигән тавышы ишетелде.

Икәүләп өстәл янына килеп утырдылар. Анда ипидән гайре башка бер әйбер дә юк иде.

– Ризык пешерергә вакытым юк. Аннан соң алырга мөмкинлегебез дә булмады, – дип акланды кайнана.

Бергә яши башлагач, Гөлнар бу йортта моңарчы беркайда күрергә дә, ишетергә дә, хәтта күз алдына китерергә дә мөмкин дә булмаган хәлгә тап булды: кайнана шикәр комын, азык-төлекне келәттә бикләп тота икән!

– Бездән сорамыйча бер әйбергә дә кагылма! – дип, Гөлнарны ул беренче көннән үк кисәтеп куйды.

Әлбәттә, мондый хәл киленгә бик сәер тоелды. Нишләптер, ул мондагы йозак-бикләргә һич тә ияләшә алмады. Сабира кайнананың һәр нәрсәсе санаулы, һәр нәрсәсе исәптә иде. Хәтта ул киленгә ашарга пешерергә дә рөхсәт итмәде.

Башта кайнананың саранлыгын күрмәскә, сүзенә каршы килмәскә тырышса да, тора-бара Гөлнар, келәткә кереп, ярмасын, макаронын, тозын үзе алып чыга башлады. Кайнана кешегә кабынып китәргә, агуын чәчәргә шул җитте. Ул Ильяска түкми-чәчми зарланган булып чыкты.

– Син, Гөлнар, әнине елатма! – дип, Ильяс бер көнне эштән ачулы йөз белән кайтып керде. – Келәттән әйберләрне урлый башлагансың бит син!..

Гөлнар ни әйтергә белмичә, баскан җирендә ташташтай катып калды. Менә ничек икән... Димәк, әнисе малаена зарланган! Карале, бу кайнананы берничек тә аңлап булмый бит әле... Бер көнне, келәткә аннан сораусыз кереп, кирәкле нәрсәләрне алган өчен ачулангач, Гөлнар, аптырап, аңа:

– Ярар, әни, алайса моннан соң ашарга мин пешермәм, – диде.

Дөрес, моңа каршы тегесе берни дә әйтмәде, үзе малаена:

– Хатының бернәрсә дә эшләми, миңа булышмый, – дип зарланган.

Шуңа күрә бугай, бер көнне Ильяс хатынына болай диде:

– Белеп тор, әни белән уртак тел таба алмасаң, монда яшәмисең...

Яшь хатын иреннән моны ук көтмәгән иде. Чөнки әле бергә яши башлауларына өч ай да тулмаган ич. Ә инде беренче төндә, кулларымда күтәреп кенә йөртермен, дип сайраган иреннән бүген менә нинди сүз ишетте ул!..

Әлбәттә, Гөлнарның бик ачуы килде:

– Син бабайлардан калган, борынгыдан килгән йола, дисең дә диюен, алар бит әниләрен дә, хатыннарын да тигез күргән! Ә син...

Шунда Ильяс, сүзен әйтеп бетергәнен дә көтмичә, аның кулыннан эләктереп алды да, этеп җибәрде.

– Кызны урлаганда гына йола ул! Яшәү йолага керми, – диде дә ире, ишекне каты итеп ябып чыгып китте. Кунарга да кайтмады.

Әлеге хәлләрдән соң, икенче көнне үк Гөлнарның әйберләрен бер төенчеккә төйнәделәр дә өенә кайтарып җибәрделәр. Мин сине кулларымда гына йөртермен, дип ант эчкән ир кочагында яшисе урында, аерылган исеме күтәреп, әти-әниең йортына кайтып кер әле син!..

Кызларын болай хур итүгә түзә алмаган Тимер Закир чормада эленеп торган мылтыгын алып төште. Хатыны гына тыеп калды:

– Кызыбызны кайнана йортына кайтарып кына бәхетле итә алмассың, – дип, мылтыгын кулыннан алды, Сабираларга җибәрмәде.

...Йөрәк әрнүе басыла төшкәч, Гөлнар Чишмәледән китәргә булды. Эшкә керермен, укуымны кичке мәктәптә укып, аттестат алырмын да вузга керермен, дип уйлады. Шөкер, Казанда Кадрия апасы яши, аның фатиры ике бүлмәле. Ул аны үз кызыдай якын итә, ярата. Әтисе Закир, шалтыратып, сеңлесенең ризалыгын алгач, Гөлнар шәһәргә китеп тә барды.

Ул Казан читендә урнашкан кечкенә генә бер ресторанга официант булып урнашты. Хезмәт хакы әллә ни түгел иде түгелен, аның каруы, апасы Гөлнардан фатир өчен бер тиен дә алмады. Иң мөһиме – Кадрия апасы аны авыл ыгы-зыгыларыннан, күңел ярасыннан тизрәк арынуын тели иде.

Йөрәк ярасына килгәндә, төзәлми икән ул! Ничекләр теләсәң дә төзәлми! Гөлнар да, менә-менә Ильяс килеп чыгар да аны кайтырга кыстар, дип өметләнде. Өметләнде һәм көтте. Хәтта уен үзеннән дә яшерергә тырышып көтте! Уйланыр, килер, гафу үтенер! «Бабайлардан калган йола хатын ташларга кушмый торгандыр бит инде!» – дип кабатлады ул еш кына эченнән. Дөрес, ул аны-моны апасына сиздермәскә тырышты.

Тик Гөлнарның өметләре акланмады, Ильясы күренмәде – кияү егете нигәдер бабайлар йоласына тугры калмаган иде...

Көн артыннан – көннәр, ай артыннан айлар үтә торды. Гөлнар кичке мәктәпкә укырга керде. Әйе, авыр булса да, эшли-эшли укыды. Шөкер, ресторан директоры да итагатьле, эш сөючән кызны үз итте. Хәтта, аның осталыгын белеп, көндәлек ризыкка әйләнгән татар ашының да токмачын еш кына аннан кистерә иде. Чыннан да, Гөлнар токмачны бик тә оста, бик тә нечкә итеп кисә иде шул – әнисе шулай өйрәтте.

Ресторанда шимбә, якшәмбе көннәрендә кеше бик күп була. Хәтта халык шаукымыннан, ыгы-зыгыдан баш авырта башлый. Монда ризыклар пешерү өчен кирәк-яракны, яшелчәсен, җиләк-җимешен машиналар белән китереп кенә торалар! «Азык-төлекне беркем дә келәттә бикләп тотмый икән шул!» – дип куя Гөлнар, кайнанасы өендәге хәлләрне исенә төшереп. Монда ипине күпме телисең, шулкадәр ашыйсың...

Чираттагы бер шимбәдә ресторанга бер егет килеп керде. Ул көнне залда кеше күп, официантлар җитешә алмый иде. Үзе янына официант килүен ун минут чамасы тыныч кына көтеп утырган каратут йөзле бу егет янына килеп, Гөлнар, ягымлы гына итеп:

– Исәнмесез! Ни телисез? – диде.

– Исәнмесез, исәнмесез! Урамда ишеп яңгыр ява, шуңа күрә ул туктаганчы бераз утырып чыгыйм, дигән идем, – диде егет, бик мөлаем гына елмаеп. – Бирегә кереп чәй эчмичә китеп булмас. Бигрәк тә шундый чибәр кыз кулыннан...

– Гафу итегез, бүген бездә кеше бик күп. Шуңа күрә җитешә алмыйбыз, – диде Гөлнар.

– Капкалап алырга берәр нәрсә китерсәгез дә ярар иде, туташ... – дип калды егет аның артыннан, тик кыз аны ишетмәде шикелле.

Чәй килгәнне шактый көтәргә туры килде. Алай да Гөлнарның өстәлгә чәй чынаягы куйганын егет бик дикъкать белән күзәтте.

– Туташ, минем карыным бик ачты, аш-мазар булмасмы икән?

– Әлбәттә, бар. Нинди аш китерим?

– Токмачлы аш юктыр инде сездә?..

– Нишләп булмасын? Бар. Хәзер китерәм!

– Аш күтәреп килгән Гөлнарның кинәт куллары дерелди башлады, чөнки Каратут (ул аны күрүгә үк нигәдер аңа шундый «исем» бирде) аннан күзен дә алмыйча карап тора иде. Моны сизеп, аның бит очлары кызарып чыкты.



Рәсем: Наталья Васильева

– Исемең ничек синең, оялчан кыз? – дип сорады егет.

– Гөлнар мин...

– Ә мин – Алмаз.

Гөлнар ашлы тәлинкәсен егет алдына куйды да тиз генә китеп барды. Ул Алмаз турында эченнән генә: «Әйбәт егеткә охшаган», – дип уйлап куйса да, Кадрия апасының: «Беркатлылыгың бар. Һәркемгә ышана күрмә!» – дигән сүзе исенә төште дә, ресторанда килгән-киткән андый кешеләр күп булыр ул, дип, эшенә тотынды.

Ике көннән соң Каратут кабат ресторанга килеп керде. Официант кыз Юля колагына нидер әйтте. Тегесе исә Гөлнар янына килеп, әкрен генә:

– Сине сорыйлар анда, – диде.

– Исәнмесез, Гөлнар! Менә тагын килдем әле мин... – диде ул аңа.

– Бүген яңгыр яумый бугай ич, – дип елмайды кыз, батыраеп.

– Яумаса да кердем бүген, чөнки сезнең токмач тәме тел төбендә калды...

Гөлнар сүзне артык озайтмаска булды: егетнең заказын алды да китеп барды.

– Карале, оялчан кыз, бу токмачны менә шушылай нәзек итеп кем кисә?

– Мин...

– Шулаймыни-и-и? Алайса, син авыл кызы! Чөнки алар гына шулай оста кисә белә.

– Гафу итегез, сөйләшергә вакытым юк.

Сменаны тапшырып, Юля белән өйгә кайтырга дип урамга чыксалар, Гөлнарның исе китте: Алмаз басып тора!

– Әйдәгез, өегезгә илтеп куям, туташлар! – диде ул.

Гөлнар никадәр генә карышып маташса да, Юля аны барыбер күндерде:

– Көпә-көндез тотып ашамас ул сине – утыр!

Юлда әллә ни сөйләшмәделәр. Бары тик Алмазның: «Мин Казанны белмим, таныштырып барыгыз!» дигән сүзләренә Юля гына кулы белән күрсәтә-күрсәтә сөйләп барды.

Юляны өйләре янында калдырырга туктагач, Гөлнар да машинадан атылып чыкты.

– Рәхмәт. Инде ерак түгел, мин җәяү генә кайтам, – диде ул.

Алмаз аны кабат машинасына утырырга никадәр генә кыстамасын, барыбер күндерә алмады. Шуңа күрә икәүләп урам буйлап җәяү генә атладылар.

– Ә машина?! – диде Гөлнар, бераз җир киткәч. – Машинаң шунда каламы?

– Калып торсын. Шәт, урлап китмәсләр...

Беравык сөйләшмичә генә бардылар.

– Син миңа беренче күрүдә үк ошадың... – дип сүз башлады Алмаз-Каратут. – Бер күрүдә ошату киноларда гына була ул... – диде Гөлнар, оялып.

– Безнең тормыш кино бит инде ул! Тоташ сериаллардан тора...

– Синең кызык эзләп йөрүең инде.

– Ник алай дисең? Юк, мин кызык эзләүчеләрдән түгел. Чыннан да, сиңа гашыйк булдым мин. Синең авыл кызы икәнең йөзеңә язылган...

– Син авыл кызларын рестораннарда шулай еш эзләп йөрисеңме? – Бу сүзләрне әйткәндә Гөлнарның йөзен кызыллык басты.

– Рәнҗетәсең, Гөлнар. Мине синең авыл кызларына хас тыйнаклыгың, мөлаемлыгың тартты... Шәһәр кызларында боларның тамчысы да калмады бугай хәзер...

– Син үзең дә шәһәр егете түгелме соң?

– Юк, авылдан мин. Дөрес, балачагым Казанда үтте. Аннары әти белән әни фаҗигагә тарыдылар... Шуннан соң авылга, әбием янына кайтып киттем, тора-бара шунда өй салдым. Шәһәрдән нибары алтмыш чакрымдагы Каен авылында яшим мин. – Алмаз җанланып китте һәм, үзе дә сизмәстән, хәтта кызның беләгеннән тотты. – Карале, Гөлнар, әйдә мин сиңа искиткеч табигатьле авылыбызны күрсәтәм! Бүген ял көнең бит!

– Юк, юк, син нәрсә?! Апам сәгатенә карый-карый көтеп тора мине!

Болай да соңардым бугай...

– Алайса, апагызны да алып кайтабыз! Бергә-бергә күңелле дә булыр.

Каршы килүенә карамастан, Алмаз кызны фатир ишегенә тикле озатты.

Ишекне ачкан Кадрия апасы, аларны күреп, ни әйтергә дә белмичә, аптырап сүзсез калды. Шуннан файдаланып, чак кына да югалып калмыйча, егет бер сулышта:

– Исәнмесез, апа! Мин – Гөлнарның дусты Алмаз булам. Сезнең икегезне дә безгә, авылга кунакка чакырам! – дип ярып салды.

Бу сүзләреннән соң аңа тагын да ниндидер шик белән карап алган Кадрия апасы, әлбәттә, аяк терәп каршы төште. Хәтта эченнән: «Аферисттыр бу!» – дип уйлап алды. Соң, гомерендә беренче генә күргән кешене кем авылга кайтырга чакыра инде?! Аның сүзенә кем ышаныр да, кем аңа ияреп чыгып китәр дип уйлый икән ул?! Гомердә булмаганны!.. Әле йөрәк ярасы төзәлеп тә җитмәгән балага берәр этлек ясап куймасын тагын бу шома егет!

– Юк, юк, беркая кайтмыйбыз да, беркая бармыйбыз да! – диде Кадрия апалары, кистереп. – Беренче мәртәбә генә күргән кешегә ияреп юлга чыгабызмы соң?!

Тик егеттә үҗәтлек дигән нәрсә бик көчле иде: ул алай итте, болай итте, аларны күндерергә тырышты. Аның уенча: икесе дә кайтса, аның өчен көткәннән дә яхшы булачак: әбисе Гөлнар белән генә түгел, ә Кадрия апалары белән дә танышыр иде.

Ләкин Кадрия дә сүзендә нык торды. Алай да бирешергә мәҗбүр булды. Анда да үзенчә шактый хәйләле юлны сайлады һәм:

– Ярар алайса, Гөлнар белән дуслыгыгызны истә тотып, болай эшлибез... Сезгә... – Ул, уйланып, туктап калды. – Сезгә киләсе атнада Гөлнарның ял иткән көнендә кайтабыз, – диде, ә үзе эченнән: «Менә шунда күрербез сүзеңдә ничек торганыңны! Болай яхшы сайрыйсың», – дип уйлап алды. Аның килеренә шикләнә иде ул.

– Рәхмәт. Килешәм, – диде егет. – Димәк, киләсе атнада, Алла боерса!

Алмаз, чыннан да, сүзендә торды һәм килешенгән вакытта аларны үз авылларына алып китте. Каенлыклар кочагына сыенып утырган Каен авылының табигате искиткеч матур икән шул! Алмазның сап-сары нарат бүрәнәләреннән салынган зур йорты әллә кайдан игътибарны җәлеп итеп тора.

– Монысы минем фермерлык хуҗалыгым инде, – диде егет, өйләре янына килеп туктагач. – Мал-туар, кош-корт асрыйм.

– Син фермермени, Алмаз? – диде Кадрия, гаҗәпләнгән сыман.

Тавышы йомшак иде. Аның эш кешесе булуына хөрмәт сизелә иде анда.

– Әйе. Колхозлар юкка чыгып, авылыбыз тарала баруын күрдем дә, фермер булырга исәпләдем. Рәхмәт, җитәкчеләр дә булышты. Тормышымны тагын да җанландырып җибәрү өчен хатын-кыз җитми... Ул да булса, тормышым тагын да түгәрәкләнер иде! Әбием дә һаман өйләнмисең, дип ачулана...

Кадрия белән Гөлнар бер-берсенә карашып алдылар. Шунда капка төбенә ап-ак яулыклы әби килеп чыкты да мөлаем елмаеп:

– Бәрәч, улым, әллә миңа килен алып кайттыңмы? – диде. – Исәннәрмесез!

Исәнләштеләр, күрештеләр.

– Кунакларга чәй эчерик инде, әби! – диде аңа Алмаз. – Сыерлар, тавыклар турында сөйләп, мин аларны алҗытып бетердем бугай...

Алмаз әбисе белән бергә аларны чәй янына дәште. Әбисе ул кайтышка оныгы яраткан бәрәңге пәрәмәчен пешереп куйган иде.

Сөйләшә-сөйләшә чәй эчеп алганнан соң, Алмаз кунакларга авылны, аның бик матур чишмә буйларын күрсәтеп кайтты.

– Монда да безнең Чишмәледәге кебек тәмле, мул сулы чишмәләр бар икән, – дип куйды Гөлнар, бер чишмә янында туктап, суын эчеп карагач.

* * *

Алмаз, ресторанга көн аралаш диярлек килеп, токмачлы аш ашарга тәмам күнегеп китте. Гөлнар ял иткән көннәрдә алар, бергәләп, Казан урамнары буйлап җәяү генә йөрергә яраталар иде. Кыздан сигез яшькә олырак егет тормышында булган шатлык-кайгыларын сөйләде.

Тора-бара Гөлнар аңа шулкадәр ияләште, ул ике-өч көн күренмәсә, үзенә урын таба алмый башлады. Бу егет аңа бик ошый иде. Аның белән сөйләшүе рәхәт, аның сүзләре күңелгә ятышлы, бу минутларда Гөлнарның җаны ял итә сыман. Алмаз белән сөйләшкәндә сүзләр дә тиз ялганып китә, гәпләшерлек уртак темалар да табыла, үзен иркен сизә. Баксаң, авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган, аннары фермер булып киткән бу егет, җитмәсә, өздереп баянда да уйный, моңлы итеп җырлый да икән! Гөлнар да бит кечкенәдән авыл сәхнәсендә җырлап үскән кыз. Бигрәк тә халык җырларын җырларга ярата.

Алмаз шулай өч ай буе килеп-китеп йөрде. Гөлнар да Чишмәлесен онытмады. Бу вакыт эчендә Алмаз аны машинасы белән берничә тапкыр авылына алып кайтып куйды, алып килде. Егетне Гөлнарның әтисе Закир да, әнисе Гөлҗамал да бик ошаттылар, үз иттеләр.

Шулай авылда ял иткән көннәрнең берсендә иртән, нindидер түземсезлек белән дигәндәй, ишекләренең кыңгыравы чылтырады.

– Иртә таңнан кем булыр икән?! – диде ашыга-ашыга ишекне ачарга барган әнисе Гөлҗамал.

Ишекне ачып җибәрсә, анда әбисе белән Алмаз басып тора!

– Берәр нәрсә булдымы әллә?! – дип гаҗәпләнде Гөлнар, иртәнге сәгатьтә аларны күреп.

– Юк, балам, хафалана күрмә. Сине алырга килдек без, кызым! – диде Алмазның әбисе, аннан-моннан әйләнеп тормыйча, турыдан ярып.

– Без әти-әниеңнән синең кулыңны сорарга килдек, Гөлнар! – дип, Алмаз аның сүзен җөпләп куйды.

Гөлнар аптырап калды. Хәтта әтисе белән әнисе дә, ни әйтергә белмичә, авызларына су капкандай, гаҗәпләнеп, бер мәлгә сүзсез генә тораташтай басып тора бирделәр.

– Киләсегезне нигә алдан әйтмәдегез соң? – диде аннары әтисе, аңына килеп.

– Бездә алдан әйтеп йөрмиләр, Закир абый: йоласы шундый, – дип җавап бирде аңа Алмаз.

– Бездә дә бар бер йола: әйтмичә генә кызны урлап китәләр. Бабайлар йоласы... – диде Закир.

– Әйе, бу турыда Гөлнар сөйләде миңа. Бигрәк кыргый йола икән. Ә бездә – кызны сорап алу йоласы, Закир абый. – Менә безнең шул йоланы үтәп йөреш. Әбием белән сезнең сүзне көтәбез...

– Уйлашыйк... Йә, ни әйтерсең, әнисе? – дип, Закир хатынына карап алды.

– Болай күркәм йола икән үзе, – диде Гөлҗамал апа. – Уйлашыйк дисең бит, атасы. Шулай булгач, уйлашыйк соң...

Гөлнар исә нәкъ менә шундый йола турында хыялланган иде бит!

Авылларындагы йола аның өчен йола түгел, ә нindидер уен гына. Әле тормышка беренче адымнарын гына атлаучы кызлар язмышы белән уйнау уены.

– Чыннан да, күркәм йола яши икән сезнең якта, – диде Закир. Ата кеше шат иде.

Күзләреңнән күзем алмыйм

Тамчы булып, чәчләреңә
Уйнап тамасым килә.
Күңелеңдә ләйсән булып
Урын аласым килә.
Күзләреңнән күзем алмый
Карап торасым килә.
Үзем яраткан кадәрле
Яраттырасым килә.

Коштай очып, кочагыңа
Бер атыласым килә.
Иркәләнеп, бер мизгелгә
Онытыласым килә.
Күзләреңнән күзем алмый
Карап торасым килә.
Үзем яраткан кадәрле
Яраттырасым килә.



Күзләреңнән күзем алмыйм

Тамчы булып, чәчләреңә
Уйнап тамасым килә.
Күңелеңдә ләйсән булып
Урын аласым килә.
Күзләреңнән күзем алмый
Карап торасым килә.
Үзем яраткан кадәрле
Яраттырасым килә.

Коштай очып, кочагыңа
Бер атыласым килә.
Иркәләнеп, бер мизгелгә
Онытыласым килә.
Күзләреңнән күзем алмый
Карап торасым килә.
Үзем яраткан кадәрле
Яраттырасым килә.

ЯРАТТЫРАСЫМ КИЛӘ

Бу шигырь язылганга инде байтак еллар үткән. Дөньяга алсу күзлектән генә карап яшәгән хыялый, романтик студент еллары иде ул. Уйга килгән беренче фикерләр, күңелдәге туар-тумас беренче хисләр әнә шулай тиз генә, җиңел генә ак кәгазь битләренә шигырь юллары булып тезелгән. Университетның татар теле-әдәбияты, журналистика бүлеге студентлары «Әллүки» әдәби берләшмәсенә йөри, үзләренең иҗади табышларын «Әдәби сүз» стена газетасында «бастырып чыгара». Чыннан да, ул газета басма матбугатка тиң: редколлегия члennары анда чыгачак язмаларны «җиз иләк» аша үткәреп сайлый, аннары берәүләр аны машинкада баса, икенчеләр бер-берсенә ялгап озынайтылган ватман кәгазенә келәйләп ябыштыра, рәссамыбыз газетаны профессионаллар дәрәҗәсендә бизи.

«Әллүки» берләшмәсенең җитәкчесе – Фәннур Сафин, газетаның шеф-мөхәррире – укытучыбыз Марсель абый Бакиров. Берләшмәгә йөрүчеләр – Мөдәррис Вәлиев, Нияз Акмалов, Хәйдәр Гайнетдинов, Шәмсия Гарипова (Җиһангирова), Асия Минһаҗева, Камәрия Кәримова, Рәйханә Мирсәяпова, Шәүкәт Сибгатуллин һәм башкалар... Утырышларда бер-беребезнең язмаларын энәсеннән-җебенәчә сүтәбез, тәнкыйтьләшәбез. Студентлар янына Сибгат Хәким, Роберт Әхмәтҗан, Рәдиф Гаташ, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләм кебек шагыйрьләр килеп йөрүен дә искә алсаң... Каләм очыннан өзелеп кенә төшкән шигырьләреңнең «Татарстан яшьләре» газетасы, «Идел» альманахы сәхифәләрендә басылып чыгуы – аерата зур уңыш. Менә бу – «Яраттырасым килә» дигән кыска гына шигырем әнә шул бәхетле шигырьләремнең берсе булгандыр, мөгаен.

Сүземне «Әллүки»дән башласам да, үзебезнең дус-тату 425 нче төркемебезне, бер-беребезгә булган туганнарча мөнәсәбәтләрне искә алмасам, хатирәләрем тулы булмас. Ул чакта журналистика бүлеге – тарих-филология факультетында санала, бер курста 25 кенә кеше укый: унбишебез – рус төркемендә, унныбыз – татарда. Хәер, теге унбишәү арасында да татарлар бар. Татарларыбыз, нигездә, авыллардан җыелган, холыкларыбыз, рухларыбыз тәңгәл. Серләребез уртак, имтиханнарга бергә әзерләнәбез, еласак та, җырласак та – гел бергә. Егетләребез җырларга бигрәк тә ярата. Берсендә шулай Наил белән Эльмарт, хисләнеп китеп, Ленин урамыннан «Исмәле, җил, туктале җил, әзмә гөлнең чәчәген...» – дип җыр сузып барганда, үзләрен милиционер туктатып, бер сум штраф түләтеп киткән! (Комплексы төшке ашның 50 тиен торган чагы.) Кирәк бит, фарсы теле укытучыбыз Мостафа Ногман да безнең кебек үк җыр җанлы булып чыкты. Композитор Рөстәм Яхин белән бергәләп «Унсигез яшем», «Киек казлар китә» җырларын махсус безнең өчен иҗат итте ул. Кайчакларда фарсы теле дәресе җыр дәресенә әйләнә иде. Укытучыбыз сорап бик тинтерәтмәсен өчен кызларыбыз хәйләгә күчә: «Мостафа абый, кичә тулай торакта гел сезнең җырны җырладылар!..» – дип сөенче ала. Мостафа Ногманның күзләре очкынлана: «Кайсын, кайсын?» Наилә белән Гөлсәрия җырлап та җибәрә: «Алларын алсаң икән, гөлләрен бирсәң икән...» Җыр яраткан кеше шигырьгә дә битараф түгел, әлбәттә. Минем яшьлек блокнотыма, мәсәлән, Гөлсәрия Исмәгыйлева (Басыйрова), Фоат Гайсин үз шигырьләрен теркәп куйган. Минем шигырьләрне дә укып, үз фикерләрен дә белдереп торалар иде. Кайберләрен укыгач: «Бу кемгә багышланган соң? Мөгаен, шуңадыр?» – дип үртәп тә алгалыйлар. Әү үзләре беләләр инде, беләләр кемгә багышланганын. Ул да үзебезнең арабызда бит. Анысы да бик чиста, саф мөнәсәбәтләр иде. Тик тәкъдирдә бергә булу язмаган булып чыкты.

Төркемдәшләребез белән әле дә бер гаилә кебек аралашып яшибез. Төрле кызыклы вакыйгаларны кат-кат искә төшереп көлешәбез. Әнә шул чакларда язылган «Яраттырасым килә» дигән шигырем «Күзләреңнән күзем алмыйм» дигән исемдә җыр булып соңрак яңгырады. Композитор Луиза Батыр-Болгариның текстны каян табып алганын, ничек көй язарга уйлаганын белмим. Ә җыр үзе күренекле җырчылар Зилә Сөнгатуллина, Венера Ганиева репертуарына керде...

Шигырьнең эчтәлегенә килгәндә, хәзер болай дип уйлыйм: гадәттә, кызлар һәм малайларның холкы, кызыксынулары нык аерылып тора. Әйтик, мин балачакта кызлар белән курчаклы, «өйле» уйнарга яратсам, күршедәге яшьтәшем Назиф машина-тракторлар белән «җенләнде». Аннары кызларның матур буласы, иркәләнәсе дә килеп тора бит әле. Шагыйрә Фирая Зыятдинованың да «Матур буласым килә» дигән шигырен, шул исемдәге китабын яхшы хәтерлим. Димәк, матур булу, яраттырасы килү теләге бер миңа гына хас булмаган. Дөньяда күпме кеше яшәсә, мәхәббәткә шуның кадәр аңлатма да бардыр дип беләм. Минемчә, ул – яратудан бигрәк, нәкъ менә шул яраттырасы килү теләгедер.

Иркәләнү дигәннән, миңа балачакта анысы әллә ни эләкмәде. Әткәй иртә вафат булды. Әнкәй балаларга кырыс тәрбия бирү яклы иде. Рәхмәт, ул мине кыен чакта да авырлыкларга бирешмичә, үз көчемә ышанып яшәргә өйрәтеп калдырды.

«Күзләреңнән күзем алмыйм» – яшьлегем җыры. Хәзер, Тукай әйтмешли, «күз карашымда үзгәрде әшьялар төсе»:

Алкаларым сыңар-сыңар –
Йә югала, йә сына.
Сыңар-сыңар алкаларым
Үз парларын юксына...

Илфат Дәүләтшин көй язган «Сыңар алка» җыры бу. Җырның монысын да Зилә Сөнгатуллина җырлый.

Фәйрүзә МӨСЛИМОВА



Фото интернеттан алынды

ТЕЛИ БЕЛСӘҢ, ТЕЛӘК...

Мәдинә КАШАПОВА

Эштән кайтып барыш. Тукталышка килеп җиттем дә автобусымны көтәм. Арлы-бирле чапкан машиналарны, светофорны да санга сукмыйча, юл аркылы йөгерәатлый чыккан ике ханым, зур-зур сумкаларын лап иттереп җиргә ташладылар да, яныма ук килеп басып, ни хакындадыр кызып-кызып бәхәсләшә башладылар. «Миңа мондый черегән алма кирәк түгел дип әйтә алмадыңмы?» – диде өлкәнрәге.

– Шуның өчен тавыш күтәрәм, ди, хәзер менә... Юлдашының исе китмичә торуына өлкән ханым, тагын да ярсып: – Әйдә, кулы чересен шул черек алмасы өчен, – дип тезеп китте.

– Өстемә салкын су койгандай булды. Читкәрәк китеп бастым.

– Теләп торма әле теләсә нәрсә, үзеңә әйләнеп кайтмасын...

Сүзләр шулай тәэсир иттеме, аңа карап торган кешеләрдән уңайсызландымы, хатын кинәт туктап калды. Автобуска кереп утыргач та авызыннан сүз чыкмады.

«Тели белсәң – теләк, тели белмәсәң – имгәк, – ди торган иде дәү әнием. – Җаның-тәнең белән телә-гәндә, уйларың чиста булганда гына теләк кабул була», – дип тә кисәтә иде ул безне.

Колак төбендә һаман теге ханымның сүзләре. Аның теләгәне кабул булмас, уйлары начар аның. Ә бәлкем, кызу баштан гына әйткәндер дим, аның каргышына тап булган сатучыны кызгана башлап. Шулай дим дә, уйларым белән моннан күп еллар элек булган вакыйгага әйләнеп кайтам. Хәер, вакыйга дип тә әйтмәс идем мин аны. Гыйбрәтле бер мисал...

Хат буенча шәһәр яны бистәләренең берсенә җыенам. Барыргамы, бармаскамы? «Теләп кенә харап иттем», – дип язган авторыбызга без барудан ни фай-

да булыр икән?! Дөньяда булмаганны яза шикелле. Барып керүгә, бездән ни кирәген шундук аңлап алдык. Күңелен чистартасы, җанын телгәләп торган кичерешләреннән арынасы килгән аның...

– Унсигез яшьлек улым суга батып үлгәч, иремә: «Ул үлгәнче син үлгән булсаң...» – дип еладым. Сүземне ишеттеләр, ахрысы. Ай да үтмәде, тиктомалдан, бер җире авыртмаган килеш, ирем урын өстенә ятты да атна дигәндә улым артыннан китеп тә барды. Моңарчы беркемгә сөйләгәнем юк иде, гаепләсәләр гаепләрләр, хәзер сөйлим.

Ул шулай диде. Сүзне бик нык уйлап әйтү, теләкне белеп теләү темасына гомеремә җитәрлек сабак алып кайттым мин ул чагында. Ә менә: «Сүземне ишеттеләр, ахрысы», дигәнен ничек фаразларга кирәклеген әле төшендем. Уйлаган һәр уебыз – матурлыктымы ул, мәкерле-начармы – шундук барып ирешә. Ничек юрасаң, шулай була, дип тикмәгә генә әйтмиләр ләбаса. Күңел күгең нинди – Аллаһы Тәгалә сиңа шуны бирә. Коръәндә: «Күкләрнең вә Җирнең (хәзинә вә сер) ачкычлары аның карамагында. Теләгәненә ризыкны мул бирер, теләмәгәненең ризыгын кисәр. Ул һәрнәрсәне белеп тора» (Шура сүрәсе) диелгән.

Фәлсәфә докторы, экстрасенс, медиум, психотерапевт Адриана Калабрезеның «Ничек тормыштан барын да алырга?» дип исемләнгән гамәли кулланмасын кулыма алуга күңелемә килгән беренче уй: теләгәненнең барын да җиңел генә тормышка ашыра башласаң, тормышның нинди яме-рәхәте кала?! Аннары, моны эшләү мөмкин дә түгел. Ә менә кулланма авторы: «Мөмкин булмаган бернәрсә дә юк, бары шуңа үзеңне ышандырырга гына кирәк», – дип аңлата. Хыялланып йөрергә түгел, ә бәлки, шул хыялыңны тормышка ашыру юлларын эзләргә кирәк. Кызганычка каршы, адәм баласы максатына, морадына ирешкәч тә үзен бәхетле хис итми. Бер генә мисал китерәм: танышымның кызы кияүгә чыкты. Яраткан кешесенә, теләгәненә... Бер-ике ел үтте микән, әнисе әйтә: «Кызым аерылышырга йөри, бер дә килешмиләр, ызгыш-талаш, шау-шу, инде үзем дә туйдым», – ди. Димәк, кавыштык та теләгебезгә ирештек кенә түгел икән әле. Ирешкәнне саклый белергә кирәк! Никах таркала башлаган икән, димәк, баштан ук кияү белән кәләшнең бу кавышуын кайсысыдыр теләп бетермәгән. Югыйсә аларның барысы да ал да гөл булыр иде.

Уңышка нәрсә юлдаш соң, дисезме?! Эчке сиземләү, сәләт һәм тырышлык. Әйткәнемчә, үзеңне аңлый һәм ишетә белергә кирәк. Моннан күп еллар элек булган хәл искә төшә. Утырасы автобусыма утырмыйча, икенчесен көтеп калдым. Тиктомалдан. Утырмаска сәбәбе дә юк иде шикелле. Аның артыннан килүче автобуска кереп урнаштым да барам. «Аккош күле» тукталышы тирәсендә халык кайнаша. «Ашыгыч ярдәм» машинасы да килгән. Күрәм: бер читтәрәк теге автобус капланган. Үлүчеләр дә, имгәнүчеләр дә бар. Менә нигә аягым тартмаган икән! Без мондый вакытта бәхетем бар икән, дибез. Ә бит, чынлап уйласаң, бу очраклы түгел, интуициям тотып калды мине. Тормышны теләгәнчә корыр өчен үзебездәге яхшы сыйфатларны, сәләтне ача белү кирәк.

Тормышта күп нәрсәгә ирешү өчен ни кирәк соң? Китап авторы раславынча, вакыйгаларны үзеңә кирәкле юнәлешкә бора алу өчен үзеңдәге сыйфатларны оста файдаланырга кирәк. Бу ни дигән сүз? Ни телисең шуны булдырасың килә икән, иң элек үзеңне өйрән. Шушы мәлдә син ничек яшисең: бәхетлеме син, мул-бай тормышлымы, анда үз-үзеңне шәхес буларак ачу-раслауга, мәхәббәткә урын бармы? Тормышыңнан канәгать түгел икәнсең, ул чагында сүлпән яшәү рәвешеңне онытырга һәм барын да яңабаштан башларга кирәк.

Интуиция, экстрасенсорика турында еш сөйлибез. Мондый сәләт һәркемдә бар. Эчке сиземләү безне күп кенә күңелсезлекләрдән саклап калырга мөмкин.

Шәхсән мин үзем теләгәнемне тормышка ашыра алачагыма һәрвакыт ышандым һәм ышанам. Әмма бер ышаныч кына җитәме бу очракта? Ышаныч ул теләгәнеңне гамәлгә ашыруда төп төшенчә-этәргеч дип әйтер идем. Уйлый башлауга ук (гел сәер яңгырасын) Күкләр ни теләгәнебезне, уй-ниятебезне шундук ишетеп-аңлап ала. Бездән бары теләгебезнең ихлас теләк булуына ышаныч кына таләп ителә. Хикмәт бары шунда. Яшәгән дөньяңны үзгәртү өчен кечкенә генә бер өмет чаткысы да җитәргә мөмкин.

Тормышны үзгәртү, дибез. Булдыра алырбызмы без моны? Җанга сеңгән куркудан арыну җиңел эш түгел. Әмма мөмкин булган эш. Әгәр дә без куркуга бирешәбез икән, аның хакимлегенә, аның кармагына эләгәбез. Һәм инде башка берни турында да уйлый алмыйбыз. Курку ул өметне сүндерә, ышанычны югалта. Димәк, теләккә ирешүдә беренче киртә курку икән. Дөрес, кайбер кеше ни теләгәнен дә анык кына белми. Монысы – үзе бер проблема.

Игътибарыңны нәрсәгә дә булса юнәлтү, нәрсә теләгәнеңне белү – ул иң җаваплы гамәлләрнең берсе. Үз-үзегезгә: «Тормышымдагы вакыйгалар мин теләгәнчә булыр», – дип әйтеп карагыз әле. Әгәр дә бу сүзләрне ышанып әйтәсез икән, үзегезне бәхетле санагыз. Димәк, киләчәктә ни буласын күз алдына яхшы китерәсез. Үткәнегезгә әйләнеп кайтыгыз да, сезнең уйлавыгызча, барып чыкмаган тормышыгызга читтән генә күз төшереп алыгыз. Бәләкәй чагында әниләр безне тәкәббер булмаска, үз-үзеңнән гел канәгать булып йөрмәскә, масаймаска өйрәтә. Үзеңдә иң яхшы сыйфатлар тәрбияләү-үстерү – бер хәл, ә менә

Аллаһы Тәгаләдән бирелгән уникаль сыйфатларыңны үстермичә калдыру-югалту – икенче эш. Адәм баласы – бөек көчнең һәм энергиянең бер каррәсе. Бу хакта азга гына да онытырга ярамый. Бездә таулар күчерердәй көч бар. Баймы без, фәкыйрьме, яшьме без, өлкән яшьтәме – Аллаһы каршында һәммәбез тигез! Ул безнең белән очсыз-кырыйсыз кодрәт иясе, индивидуаль көч чыганагы буларак аралаша. Әмма шул ягы да бар: үзен уңышлы дип санаган кешеләр генә бу тормышта морадына ирешә.

Без күптән булган күңелсез хәлләр, тормыштагы тискәре күренешләр турында кайта-кайта уйлыйбыз. Яхшысын сирәк искә төшерәбез.

Әйтелгәннәрдән нәтиҗә ясыйк. Үз-үзен түбән бәяләгән, берни эшләргә сәләтле түгел, дип, үзен эчтән кимергән кешеләр дә аз түгел. Битәрләмәгез әле үзегезне, түбәнсетмәгез. Югыйсә күңелсез киләчәкне юрап китерерсез. Әгәр үзегезне гел түбәнсетәсез икән, башкалар да шуңа ышаныр, сезгә карата шундый мөнәсәбәттә булыр. Кырыс хакыйкать шундый. Җыеп әйткәндә, ни юрасаң шул булыр.

Нинди генә теләк теләсәң дә, ул бары чын күңелдән, бөтен җаның-тәнең белән булганда гына чынга аша. Моңа ихластан ышанырга, шуңа омтылырга кирәк. Кайчак үзеңә бер кирәкмәгәнне дә теләп куясың. Вакыт үтүгә, нәрсәгә кирәк иде инде ул миңа, дип үкенә башлыйсың. Сүзеңне генә түгел, уйларыңны да мең кат үлчәргә кирәк шул. Без: «Их-х, күп итеп акча отсаң иде», – дибез. Миллионнар отып, акчаларын җилгә очырган кешеләр бар. Бәлкем, акча отсаң иде дигәнче, бай-мул тормышлар, күңел тынычлыклары, сәламәтлек, бәрәкәтле озын гомерләр теләргәдер безгә?!

Теләкләрне ничек телибез соң без? Мисал өчен, әйтик, конкрет бер чирне алыйк: «Астмадан дәваланырга телим», – дибез. Ә теләкнең асылында ни ята?! Әйе, ныклы сәламәтлек... Шулай булгач, сәламәтлек бир, Ходаем, дип сораганда дөресрәк булмасмы?! Йә булмаса, хыялымдагы кешене очратасым, аңа кияүгә чыгасым килә, диләр. Моның асылы, нияте исә гомер буе яратып һәм яратылып яшәү. Сизәсезме аермасын?! Ни теләгәнеңне белергә, дөрес итеп теләргә кирәк дигән сүз бу. Ә менә икеләнеп торулар беркайчан тиешле нәтиҗәне бирми.

Доктор Адриана Калабрезе исә, мәсәлән, «Мин бәхетле, мин үз тормышымнан канәгать, мин ни телим шуңа ирешәм...» дияргә куша. Бу гади сүзләр түгел, алар кешегә ышаныч бирә, өмет уята. Яңа эшкә урнашырга яки яңа һөнәр үзләштерергә теләгәндә дә үзеңне инде шунда эшлисең һәм уңышлы эшлисең итеп күзалларга, шуңа шөкер итәргә кирәк.

Безнең теләкләр укыган догаларыбыз аша тизрәк барып җитә. Рамазан ае бара. Бу ай – гөнаһлар кичерелә, күп саваплар языла, теләкләр, ялварулар кабул була торган ай. Аллаһы Тәгалә: «Мөхәммәд өммәтләре ураза тотып, иреннәре агарып, ифтар вакытында кулларын догага күтәргәндә күк белән җир арасындагы пәрдә күтәрелә. Аларның догаларын кабул итәм, чөнки алар бу мизгелдә минем белән пәрдәсез сөйләшәләр», – дигән. Бер-беребезгә матур теләкләр телик, бер-беребезгә яратып карыйк, җылы мөнәсәбәттә булыйк. Бар нәрсә дә күңелеңнең чисталыгына, рухи үсешеңә карап бирелә, дигән бит. Бер сүз белән әйткәндә, теләгәнеңә ирешү ул бары үзеңнән тора.

киңәш...

Уңышсызлыктан, бертуктаусыз чыгып торган проблемалардан арыну өчен, мәсәлән, түбәндәгеләр киңәш ителә:

! Моңарчы чынга ашмаган теләкләр өчен иң элек үзегезне, аннары әйләнә-тирәгездәгеләрне гафу итегез. Сезнең карашка, күңелсезлекләр килеп чыгуга сәбәпче булган дусларыгызны, аннары әти-әниегезне, якын туганнарыгызны... Аларның берсе дә тормышыгызда тикмәгә генә урын алмаган.

! Тормышка карашны үзгәртү җиңел түгел. Тик биредә ике төрле уйларга урын калмый. Йә сез яшәү рәвешен үзгәртеп алга китәсез, йә юк.

! Эшнең нәтиҗәсе хакында артык уйламагыз. Әҗер гамәлегезгә бәрабәр булыр. Дөньяга карашыгызны үзгәртегез.

! Сәләтегезне һәм мөмкинлекләрегезне аек бәяләгез. Нәрсәне яхшырак эшли аласыз? Сездә нәрсә канәгатьлек хисе тудыра?

! Кояш кебек булыгыз! Күбрәк елмаегыз, кешеләргә матур сүзләрне күбрәк әйтегез. Үзегезгә әйбәт мөнәсәбәттә булган кешеләрнең кадерен белегез! Рәхмәтле булыгыз!

! Оптимист булыгыз! Барып чыкмаган эшләрегез турында борчылып йөргәнче, аннан сабак алсагыз, нәтиҗә ясасагыз файдалырак булыр.

! Йомшак якларыгыздан көч алыгыз! Әйтик, кирелекнең максатка, эзлеклелеккә омтылу сыйфаты булуын аңласагыз, ул сезгә көчле ягы белән әйләнер.

! Көчегезне үзегезгә буйсындырыгыз! Иң кыены – дәрәҗәңне белү һәм шуны кабул итү.

! Теләгәнегезне инде тормышка ашкан дип күз алдына китерегез һәм шуны сүз белән әйтегез.



ХӘЙРУЛЛИН Рөстәм

Россия Ислам университеты

Өйләнгән. Бер кыз һәм өч малай атасы.

Карьера:
Татарстан Республикасы мөфтие урынбасары, «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы.

Тормыш шигаре: «Әгәр кемдер кешеләргә рәхимле, мәрхәмәтле булмаса, Аллаһы Тәгалә аңа да рәхимле, мәрхәмәтле булмас».

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Күңелләргә сукмак салу кирәк


Мәчеткә йөри башлаган, намазга баскан кызларның күбесе белән әти-әниләре арасында аңлашылмаучылык туа. «Хәзрәт, әнием яулык ябынмаска куша, яшь гомереңне әрәм итмә дип әйтә», – дип елап киләләр. Андый чакта әти-әниләр белән очрашырга тырышабыз. Аңлаткач: «Балам дөрес юлда икән дип», – сөенеп калалар... Урта Азия якларыннан килүче яшьләрнең монда юлдан язган очраклар бар. Бер үзбәк егете минә өлкәннәрне тыңламый, зина кыла, эчә башлады. Аны гөнаһ юлдан тартып алу өчен әти-әниләре белән бергә тырыштык.


Сынау ае кичтек


Ураза – мисалы, ише, тиңе, охшашы булмаган бер гыйбадәт, җәһәннәм утыннан калкан. Быелгы уразаны, дөресен әйтәм, куркып көттек. Елның иң озын көннәренә туры килде бит. «Мәчеткә тәравих намазларына килүче булырмы икән?» – дип борчылдык. Шөкер, Татарстанда гына түгел, Россиядә дә мәчетләр шыгрым тулы булды! Казанда 5 мең кеше бер җиргә ифтар ашына җыелды. Россиядә беренче тапкыр! Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов үзе дә килде. Бик зур вакыйга булды ул. Халкыбызның дингә мәхәббәте уянган, ул диндә икән, татар милләте алга таба бара – аның киләчәге бар дигән сүз дә бу.

Динебез – чиста, хак дин

Европага барып чыксаң, Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә эләккән кебек буласың, диләр. Шәһәр тулы манара, кайда да азан тавышы... Лондонга аяк бассаң да шулай, Парижга килсәң дә шул ук хәл. Татарстаныбызда да барысы да Аллага шөкер бит. Бөтен җәмһүриятебезгә 13 мәчет калган чаклар бар иде... Соңгы егерме ел эчендә аларның саны мең ярымнан артты. Безнең «Гаилә» мәчете ишекләрен ачканга да ике генә ел әле. Инде менә янәшәдә мәдрәсә төзү турында хыялланабыз.

сөендерде   көендерде 

сөендерде   көендерде 

сөендерде   көендерде 

Гыйлем җитми, гыйлем...

Кырымда, Урта Азия якларында булганда безнең әби-бабайларга рәхмәт әйтүләрен бик еш ишетәсең. «Татарлар язган китаплардан укыйбыз», – диләр. Төркиядә Коръәнне дөрес укырга бүген дә бөтен мөселман дөньясына мәгълүм «Карабаш тәҗвиде» китабы буенча өйрәнәләр. Аның авторы Абдрахман-әл-Карабаш дигән дин әһеле – Карабаш бистәсеннән. Дин тыелган 70 ел эчендә безне менә шушы тамырларыбыздан өзделәр... Барысын да нольдән башлыйбыз хәзер. Җиңел түгел! Кайда бушлык – шунда яман гадәтләр, тәрбиясезлек. Кайда буш куыш – шунда секталар.

Динебезгә зур тап...

Мәскәү университеты студенткасы Варвара Карауловаңы Төркия һәм Сүрия дәүләтләре чигендә тотып, кире Россиягә, гаиләсенә кайтардылар. Ул террорчылар лагерена барырга, сугышырга теләгән. «Ислам дәүләт»енә көн саен бер меңгә (!) якын кеше килеп кушыла, диләр. Аларны бөтен дөнья буйлап эзләп, табып, аулап, тартып китерәләр. Егет-кызлар, динне өйрәнмичә, аның асылын аңламыйча, сугышка барып керә. Күрәләтә торып алданалар! Безнең яшьләрне шулай бозалар – читтән куркыныч афәт килеп ята. «Мөселманнар менә нинди» дигән ялган фикер тудыру да бит әле бу.

Дөньяда гаделлек булсын иде!

Украина мөфтие Сәид хәзрәт Исмәгыйлев белән очрашканда, ул миңа бер рәсем күрсәтте: мәчеткә манарадан ракета кергән. Ярый Ходай саклаган, шартламаган. Әле менә яңа хәбәр: Донецк җәмигъ мәчетен утка тотканнар. Шактый зур зыян күргән. Мондый вакытта беренче чиратта үзеңнекеләрне – Донбасс шахталарына эшкә киткән Казан татарларын уйлыйсың... Анда күпме мөселманнарыбыз үлә! Европада кечкенә генә бер хәл булса да, бөтен галәмгә шаулаталар. Ә монда...

СОҢГЫ ХЫЯНӘТ

Фото интернеттан алынды



Эльмира
ЗАКИРОВА

СӨЙЛӘСӘҢ, КЕШЕ ЫШАНМАСЛЫК БУ ХӘЛЛӘР, БУ ВАКЫЙГАЛАР ШОМЛЫ ДЕТЕКТИВТАН ҺИЧ КИМ ТҮГЕЛ ИДЕ.

Юбилей белән котлаудан башланган гамәл әллә нинди чоңгылларга төшерде: билгесезлек, телдән яздырырлык хәбәрләр, чарасызлык, ахыр килеп, югалту ачысы...

Сәер килен

Илгизә өчен Линар абыйсы якын, бик якын туган, әлбәттә: әтисенең яраткан төпчек энесе бит. Мәктәптә «биш»кә генә укыган, оста шахматчы, чаңгычы булган, сугыштан соңгы 50 нче елларда, очучы булам дип, хәрби училищега китеп барган... Шул ук вакытта ерак та ул, әллә кайда томан артларында сыман: гомере буе Ерак Көнчыгышта отставкага чыкканчы офицер булып хезмәт итте. Сирәк-мирәк хатлары килеп торды. Фотоларын да сала иде. Штирлицка охшаган кыяфәтле, йолдызлы погонлы матур бер хәрби. Үзе генә дә, хатыны һәм кызы белән дә ике-өч елга бер туган якларга кайткалап китүләрен әле дә хәтерли Илгизә. Кунаклар кайту авылда гел бәйрәм кебек була инде ул! Хисләрен бик тирәнгә бикләп, артыгын сөйләшми, зарланмый, сагынуын сиздерми торган абыйлары Сабан туена туры китереп кайта иде. Күрше авылда җирләнгән әти-әни каберен зиярәт кылырга барулары... Кармак белән балыкка төшүләре... Токмачлы ашлар пешереп, бәлешләр салып, кунакларны сыйлаулар... Хатыны Раиса гына бу затлы ризыкларны санга сукмаган кебек кылана. «Без ресторанга йөрибез», – дип кенә җибәрә. Билләре нечкә, аяклары төз, гәүдәләре зифа, көттә киенгән бу хатын башка төрлерәк иде шул. Илгизәнең әти-әнисе дә, туган-тумача белән күрше-күлән дә аны ятсына торганнар иде. Исеме үзебезнең Рәйсәгә бик якын булса да. Чәчләрен безнең хатыннар кебек турыдан ачып артка төйнәп йөрсә дә... Йөзенең кайсыдыр чалымнары күптән гүр иясе булган кайнанасы Хәлимәне хәтерләтсә дә... Әллә кыланмышын, әллә үзен көйләтүләрен кабул итмәделәр шунда. Тик белгертмәделәр, йөзләренә чыгармадылар. Ачык йөз белән каршы алдылар, булдыра алганча кунак иттеләр. Алай да туганнары: «Ленизага гына өйләнгән булса соң», – диеп чыш-пыш килде. Кемдер ул Лениза, анысын Илгизә белми иде әле.

Юмаларга, хәйләләргә, һай, оста бу Раиса! Кирәк икән, сатып җибәрәчәк үзеңне. Теләсә кемне авызына карата. Гид булып, чит ил кешеләренә шәһәр күрсәтеп йөрим ди бит әнә. Көязләнеп, үзенә-үзе сокланып йөрү бик ошый иде аңа! Башкалар әйткән комплиментлардан

башы әйләнеп, үзен дөньяның бер гүзәле итеп тоя иде кебек ул. Каян килгән сылукай! Илгизәгә дә, сеңлесе Суфияга да яңа исемнәр тапты: «Элечка, менә сиңа бүләккә кашмилон кофта, Япониянең үзеннән», – имеш. «Ә сиңа, Софа, чын кытай ефәгеннән шарфик...» Порт шәһәрендә яшәгәч, ерак диңгезләргә йөзүче моряклар япон товарларын алып кайтып кына тора, дип, нәфис кечкенә сумкасы, ялтыравык чәч кыстыргычлары, перламутрлы иннекләре, япон чүәкләре белән күрше кызларын да шаккаттырырга өлгерде инде. Телендә кимоно да кашмилон ише сүзләр генә. Кызларны ничек киенергә, ничек йөрергә өйрәтә. Гөлсинә белән Әлфиягә чәчләрен кисәргә киңәш итте дә, сүз тыңлап кыркымышка әйләнгән кызларны модницалар дип мактый-мактый, чәч толымнарын... чемоданына тыкты! Мин киткәнче, бәлки, башка кызлар да чәчләрен кисәр ди.

Кунакларны озаттылар, өйдәге акчалардан да җилләр искән иде. «У нас беда срочно вышлите 100 рублей» дигән телеграммасы да килеп төште Раиса җиңгинең. Кирәк булгач кирәк инде – Илгизәнең әти-әнисе акчаларын кырып-себереп ярдәм итү ягын карады. Нәрсә булган, нинди бәла-каза – ләм-мим: тегеләр аңлатып язып торуны кирәксенмәде бугай. Берничә елдан соң үзе генә кайтып киткән Линар абыйсы исә телеграмма турында да, акча хакында да берни белми булып чыкты... Акылы бала-чаганыкы инде, берәр нәрсәгә туздыргандыр, дип кенә көлде. Сәер килен кайткан саен сәер гадәтләре белән шаккаттыруын дәвам итте. Ун елдан соң да, егерме, утыз ел узгач та...

Кайту-китүләр

Линар абыйның күчеп кайтырга талпына башлавына бер унбиш ел гына бардыр. Хәер, бәлки, ул гомере буе шул турыда хыялланып яшәгәндер? Бакыйлыкка кендек каны тамган җирдән күчәсе килгәндер? Яшьлек белән игътибар да ителмәгән ата-баба йоласы дигән нәрсә күңеленең кайсыдыр бер почмагында ялтырап кабынмыймы соң! Әти-әнисен җирләргә кайта алмау үкенече торып-торып җанын газапламагандырмы әллә?! Шактый таушалган, олыгайган шул инде. Илгизәләр гадәт буенча һаман абый дип йөргәч тә... Сиксәнен тутыручы бабай бит ул. Берничә тапкыр инсульт кичергән. Җирсү дигән әйбер тынгы бирмидер, күрәмсең. Ә Илгизә, үзәккәен өзим әле дигәндәй, абыйларын каршы алганда, озатып калганда машинада махсус татарча җырлар әйләндерә: «Кайтам инде, кайтам туган ягыма...», «Туган авылым урамын кабат-кабат урадым...». Һай, бигрәк моңсу күренде лә абыйсы. Бер дә китәсе килми иде бугай аның. Теле белән әйтмәсә дә, карашлары шуны сөйләп тора. Илгизә теге серле Ленизаның да кем икәнен белә инде хәзер: Линарның бик яраткан сыйныфташ кызы булган ул. Егет лейтенант акчасына кул сәгате алып кайтып бүләк иткән. Тик кыз, нишләптер, хәрби егеткә ияреп җир читенә китәргә теләмәгән. Линар абыйсы ялынып тормаган: көннәрдән бер көнне океан буенда үскән шул Раисаны Татарстанга очыртып алып кайтып күрсәткән: менә сезгә килен, янәсе...

Башта «Татарстан» поезды абыйларын Мәскәүгә алып китәчәк. Икенче көнне ул самолетта Владивостокка очачак. Очу вакыты җитәр алдыннан, абыйсы траптан күтәрелә башлаганчы, Илгизә һаман хәл-әхвәлен сораша. Хәйләсе бар: әткәй-әнкәй теле күкләргә күтәрелсен, юл буе озата барсын әле...

Раисасы да җитмешнең теге ягында бит инде югыйсә. Табибә булып эшләүче кызлары да урта яшьтәгеләр рәтеннән чыгып бара. Гаиләсе юк. Кияүгә чыгып, атна да тормыйча иреннән аерылган, бала-чагасы да юк. Һәм менә шулар, кубарылып кайтып, йә Казанга, йә Чаллыга урнашмакчы булып йөриләр! Гомер иткән шәһәрләрен ташлап! Олыгайгач, бөтенләй башка мохиткә яраклашып! Владивостоктагы фатирыбызны саттык, диделәр. Раисаның төрле «сюрпризлар» ясарга әвәслеген белгән Илгизә дә, башка туганнар да сагаеп калды. Ник шулкадәр ашкыналардыр. Владивостоктан Мәскәүгәчә – атна буе, Чаллыга тәүлек буе поездда кайта-кайта... Иң беренче эш итеп яшәр урын табарга кирәк иде. Евроремонт ясалган фатир уңайлы да, арзан да, югарыда яшәүчеләрнең шакылдавы ишетелмәсенгә иң соңгы катта да булсын, метрога һәм базарга да якын урнашсын, мәчеттән азан тавышлары яңгырап, йокыларын да бүлмәсен... Тагын әллә нинди шартлар, таләпләр. Тегеләй дә, болай да ярап булмый. Йә монда океан юк, йә халык кычкырып сөйләшә... Көннәрдән бер көнне, беркемгә берни әйтми җыенып, Владивостокларына ук очып киткәннәре мәгълүм булды. Соңыннан хәбәрләре килеп ирешә тагын: «Безнең хәлгә керердәй туганнарыбыз юк икән...»

...Бер елдан соң – янә шалтыратулар, кабат кайтырга талпынулар, контейнер җибәрүләр, Чаллыдан да шәп шәһәр юк дип танулар, туганнарга мактау сүзләре.

Чит-ят җирдә үзен ятим тоеп гомер кичермәде микән әле ул?

Вакытлы яшәү урыны

Август–декабрь. Бер дуамалланып китеп баргач, ничек шулай берни булмагандай янәдән кайтып була икән? Илгизә белән Суфия янә вокзалда, Мәскәү – Чаллы поездын каршылыйлар. Линар абыйлары Казанда калып торачак, ул арада ана белән кыз Чаллыда гаиләгә фатир, Дианага эш эзләячәк, вакытлы пропискага керәчәкләр – алар шулай хәл иткән. Раиса ире янында сырпалана, бер сөеп куя, бер үбеп ала. Соңгы күрсәтмәләрен бирә: «Элечка, абыегызны саклагыз! Бер атнадан автобуска утыртып безнең янга озатырсыз. Урнашыйк кына, кунакка да чакырырбыз сезне!» Аннары Линар белән саубуллаша: «Көн саен кич 7 дә хәбәрләшербез. Үзеңне саклый күр берүк, кадерлем!» Искиткеч пар дип карап тормалы, билләһи! Атна дигәндә тегеләр вакытлы фатир тапты, Линар абыйлары да Чаллыга китеп барды.

Тик аналы-кызлы Казан белән ике арада киләп сарып, кунакханәләр сайлый-сайлый, кафеларда сыйлана-сыйлана, башкалада фатир эзләп тә, хастаханә-шифаханә-

ләрдән табиб урыны белешеп тә шактый болгандылар әле. Ахыр килеп, Чаллыдагы шартларга күнеп, акчаларын яңа төзелә торган йортка керттеләр бугай. Вакытлы яшәү урыны итеп туганнарга – Гөлүзәләр адресына теркәлгәннәр. Димәк, үз почмаклары булачак тиздән! Җай чыккан саен һәркайсына аерым шалтыратып, хәлләрен белешеп торды Илгизә. Әнә, Гөлүзә, күпме чакырып карадык, килмиләр ди. Ә көннәрдән бер көнне Әмәктән Линар абыйның туганнан туган сеңлесе Фәридә, абыйны исән чагында күреп каласым килә, дип, Чаллыга килгән. Әмма Раиса, авырыйм, дип, бусагадан да уздырмаган. Тәлинкәләр дә, кашык-чәнечкеләр дә өйдәге кеше санынча гына икән. Урындыклар да...

Үзенең кирәксез әйбер сыман ташлап калдырылуын аңлап алгач, ничек йөрәге ярылмаган?

Мәхшәр

Февраль. Илгизә, Линар абыйсын юбилее белән котларга дип, номерын җыйды. Никтер элемтә юк иде. «Линар абыйга кабат инсульт булган. Хәлләре шәптән түгел бугай...» Гөлүзә шундый хәбәр җиткерде.

Сөйләүләренә караганда, кызы әтисен поездда Мәскәү янындагы хәрбиләр шифаханәсенә озата киткән, юлда инсульт булган, «Ашыгыч ярдәм» машинасы тиз арада Стромынкадагы неврология бүлегенә китереп җиткергән...

Элемтә урнашуга, Илгизә, ашыгып, кабат номерны җыйды. Һични аңламаслык зәгыйфь тавыш... «Без сине бик яратабыз, Линар абый! Тизрәк савыгып кайт кына берүк!» – дип тезде Илгизә. Абыйсының әллә елау, әллә сыкрау авазы гына килеп ирешә аңа.

Шуннан соңгы көннәр-төннәр, бергә тоташып, озын газаплы юл, кичеп чыгалмаслык сират күпере булып, сискәндереп искә төшә. Линар абый Чаллыдагыларга: «Мине алырга килегез, хәлем начар», – дип, чак телен әйләндереп шалтыраткан башта. Хастаханәдә табиблар күзәтүендә яткан кешене, йә, ник кузгатырга?! Их, нәрсә әйтергә теләгәнен шул чакта ук белгән булсаларчы! Ул бит авыру халәтеннән битәр башка нәрсәне сиздерергә теләгән!.. Янында саклап утырырга тиешле хатыны белән кызы, күз-колак булырга кушып, санитарkаларга акча биреп калдырган да Чаллыга кайтып киткән. Һәм шулар ук: «Хәлләре әйбәт абыегызның, дәвалаучы табибы белән гел сөйләшеп торабыз, җомга чыгаралар инде, алырга барабыз», – дип тынычландырдылар. Хатыны белән кызы шулай дип торгач соң! Шимбә кайтып төшәчәкләр, димәк...



Тик шимбә дә, якшәмбе дә бер хәбәр юк – телефоннары «сүнгән». Беренче генә сүндерүләре түгел инде, әнә, оператор элемтә юклыгын инглизчә әйтә башлады. Ярар, соңрак тагын җыеп карарлар.

– Тегеләр Линар абыйны отказ язып калдырган!!

Гөлүзәнең ярсып, ашыга-кабалана әйткән шул сүзләре һушсыз калдырды. Ничек? Гомер буе бергә яшәгән хатыны язганмы? Әллә Гиппократ анты биргән кызымы? Телефоннары һаман «вне зоны действия» дип кабатлады. Линар абыйга килгән шалтыратуга табиб җавап биргән, бу хәлне ул аңлаткан. Иртән шәфкать туташларының смена алмашкан ыгы-зыгысына туры китереп, эшен тапшырып китеп бара торганына урталай бөкләнгән кәгазь тоттырганнар да күз ачып йомганчы юкка да чыкканнар. Эз югалган. Кызының инде айдан артык эшен ташлап, Чаллыдан китү мәрәкәләре белән йөрүе дә, фатирларын хуҗасына тапшырып, контейнерларын янәдән Владивостокка озатулары да соңрак билгеле булачак анысы. Ә хәзергә мәхшәрнең башы гына әле. Телефоннары җавап бирми, кайдан, ничек эзләргә белгән юк.

Илгизә Линар абыйсын күз алдына китерергә тырышты. Ниләр кичерде икән ул? Башына нинди уйлар килде икән? Нәфрәт, рәнҗеш тулы күзләре белән артларыннан карап калганмы? Юк, күзләрен яшь каплагандыр, мөгаен... Башка авырулар каршында әллә нинди мәсхәрәле хәлдә калуына хурланып, гарьлегеннән илереп елар чиккә җиткәндер дә, офицер ныклыгы белән тешен кысып, телсез-өнсез калгандыр... Ташландык ир, ташландык ата... Ни җаннары белән чыгып киткән ул хатын-кыз затлары? Соңгы тапкыр нинди сүзләр әйтеп? Башка беркайчан да күрешмәячәкләрен сизепме, сизмичә дәме? Мәңгегә хушлашу шулай рәхимсез һәм үзәк өзгеч була микәнни? Тилмереп карап калган күзләрдән качар өчен адымнарын кызулатканнармы? Юк, алар иң элек телефондагы бөтен номерларны «сөрткәннәр»: китеп өлгергәнче эләктерә күрмәсеннәр диптер инде. Аннары инде туп-туры Домодедово аэропортына юл алганнар: Мәскәүдән Владивостокка рейслар дистәләп! Линар абыйның документлары гына үзендә калган булсачы! Пенсияләрен алуны да баш-аягы белән хатынына ышанып тапшырган иде бит инде ул. Нишләргә? Эшне каян башларга? Ничек тә шалтыратып тынычландырырга кирәк. Тик... номеры шулай ук «сүнгән». Юллап табып, табибына чыкты Илгизә. Аның сүзләре әле һаман өзек-төтек кенә хәтерендә кабатланып тора. «Паспорты үзе белән...» «Аңа яхшы тәрбия кирәк...» «Бүген менә ашаудан да ваз кичкән...» Их, очыплар гына барып алып кайтырга! Кичегергә ярамый!

Шулай килештеләр: Илгизә белән Гөлүзә бүген-иртәгә реамобильдә Мәскәүдән алып кайтачак. Алмашлап карарлар. Кирәк булса, янында утырып торучыны табарлар. «Андыйларны соңгы көннәренә чаклы махсус хастаханәдә ачтан үлмәслек кенә тукландырып тоталар да билгесезләр каберлегенә җирлиләр икән», – дип, берәү җан өшеткеч сүзләр сөйләгән иде. Тизрәк, тизрәк йолып калырга кирәк! Теге көнне коткарыгыз дип шалтыратуы тикмәгә булмаган шул! Иртәгә юлга чыгарлар. Тик... язмаса – язмый икән! Мәскәүдән хәбәр килде: «Линар Моратовны терапиягә күчердек. Ул комада...» Илгизә үксеп елап, бу мәхшәрдән арып йоклап китте. Әллә кайчан бакыйлыкка күчкән Хәлимә әбисе төшенә керде: «Зинһар, балам, ташламагыз улымны», – дип ялвара икән. Соңрак Суфия бәйрәмчә киенгән бабасын аермачык күрүен искә төшерәчәк: «Бүген бәйрәм. Зур кунак

көтәбез: Линар улым кайтырга тиеш, шуңа әзерләнәбез диде», – дип сөйләячәк.

Иртүк Гөлүзә шомлы хәбәр җиткерде: «Таңда Линар абый өзелгән!..» Җанда әллә ничә кыл берьюлы өзелде.

Соңгы юл

Тоташ берничә көнгә сузылган киеренкелекне башка төрдәге сынаулар алыштырды. Тиз арада Линар абыйны алып кайтып җирләргә кирәк иде. Аны Мәскәүдән юллап алып соңгы юлга әзерләү мәшәкатьләренә Илгизә белән Суфиянның уллары алынды. Азат белән Ильяс бөркәүле зур машина белешеп, гәүдәне салып кайту өчен табут хәстәрләп, эштән соң ерак юлга кузгалды. Арыган егетләр таңда Мәскәү бөкеләрендә утырганда, монда мәетне кемнән юдыру, кайда күмү кебек четерекле мәсьәләләрне хәл итәләр иде. Кайчан, ничәдә кайтып керү шулай ук бик мөһим. Мөселман тәртипләре буенча мәетне кояш баеганчы гүргә иңдерү шарт. Чаллының Тәүбә мәчетендә үлгән кешене соңгы юлга әзерләү хезмәте бар икән. Иң кулае – әти-әнисе янына, туган авылы Әмәк зиратына җирләү дигән уртак фикергә килделәр. Бик күрәсе килеп тә, кышын аларның өенә керәлми киткән Фәридә апа Әмәктә шул мәшәкатьләр артыннан чаба, кабер казыту эшләрен оештыра башлады: менә нинди күрешү язган.

Егетләр Мәскәүнең Сокольники метросы янындагы хастаханәне тиз таптылар анысы. Тик моргта көтелмәгән каршылыклар – мәетне бирмиләр: паспорты юк! Санитарлар, табиблар: «Мәетне бернинди документсыз китерделәр», – ди. Әллә нинди озын исемлектән фамилиясен табып, әллә ничәнче Моратовка туктала-туктала, кабат шәхси әйберләрен барлап чыгалар да белдекләләнеп: «Юк, туганнары алып киткән», – диләр. Азат кайдадыр биредә яткан Линар абый турында борчылып уйлап куя. Никтер аның җаны, үзенә урын табалмыйча, каядыр ашыга, шулай мәңге билгесез булып биредә калуыннан курыккандай, бәргәләнәдер кебек тоела. (Казанда да, Чаллыда да ут йотып көтәләр. Килешкән кебек, шул ук сүзләрне кабатлыйлар: «Калдырып кына китмәсәләр ярар иде, дип, җаны урын табалмыйдыр инде!») Адашканда кабынган шәм яктысы сыман, кылт итеп әнисе сүзләрен искә төшерә Азат: «Дәвалаучы врач паспорты үзе белән диде»! Җанын сыендырган соңгы газаплы төненең шаһиты булган терапия бүлегендә белмиләр, күрмәгәннәр. Һәм китә, китә егетләрне анда-монда футбол тубы урынына типкәләп йөртүләр. Анда барыгыз, монда керегез, аны күрегез, моннан сорагыз... Теге корпус, бу корпус... Бу нинди башбаштаклык! Баш табибка керергәме? Кизү кыз әйтүенчә, анысы урынында юк... Иртән сигездә башланган юллауларның очы-кырые күренми, инде төш вакыты җитеп килә. Җитмәсә, бу хастаханә, үзе бер шәһәрчек булып, чакрымнарга җәелгән. Тукта, тукта, иң элек бит аны неврология бүлегенә салганнар! Тагын бормалы баскычлар, фәләненче катлар, тамгаланган корпуслар... Морг сәгать өчтә ябылачак. Тагын бер көнгә тоткарланасы булыр микәнни? Менә ул неврология! Кизү торучы шәфкать туташы дәвалаучы табиб кабинетына озата. Егетләрнең Казаннан ук килүен аңлап алган табибә, хәленнән килсә, бөтенесен эшләргә әзер! Һәм эшли дә! Ул бөтен медицина персоналын чаптыра! Бер санитарка Линар абыйның җыйнак рюкзагын күтәреп керә. Шушы! Барсетка эченнән паспорт, хәрби билет, ветеран кенәгәсе килеп чыга! Авыру исеменә ачылган папкага хатыны белән кызының «отказ» хаты да теркәлгән. Кәкре-бөкре хәрефләр белән ашык-пошык язылган: «Без Татарстанда яшәүче ярлы кешеләр. Үзебез авыру, яшебез дә бар. Хаста карарлык мөмкинлегебез юк. Больницада калдырабыз...» Үлү турындагы таныклыкны алыр өчен, үлүен раслаган белешмә кәгазе белән паспортын башкаланың хастаханәгә якын район ЗАГСына илтеп тапшыру зарур икән. Шунсыз мәетне бирмәячәкләр! Алып кайтып та, җирләп тә булмый.

> *Җәсәде туган якка кайтасын фәрештәләр ирештергәндер – йөзе тыныч иде.*

...Аяктан егылыр чиккә җиткәнче чаба торгач, ниһаять, таныклыкны да кулга төшерәләр. Моргта соңгы эшләр. Мәетне туганнарына күрсәтәләр башта. Әйе, ул! Пакьләндереп, сакал-мыекларын кырдыртып, ак җәймәгә төрдертеп, көн кичкә авышканда кайтыр юлга кузгалалар. Мәет көткән ыгы-зыгылы бер мәлдә кызыннан шаккаткыч смс хәбәр килеп төшә: «Әтине югалттык. Сез белмисезме, каян эзләргә?» Димәк, хастаханәдә аларның шымчылары калган? Берникадәр акчага ризалашып, соңгы хәбәрләрне аларга җиткереп торган?.. Яшереп калу ярамас дип: «Бүген җирлибез», – дигән җавап китә. Рәхмәтләргә күмеп, тагын бер хәбәр килә. Ахырдан: «Үлү турындагы таныклыгын җибәрсәгез, әтинең соңгы истәлеге булыр иде», – дип куярга да онытмаганнар. Ни өчен икәнен чамалау кыен түгел... Берничә көннән Илгизәгә хатыны ялынып язачак: «Эля, бөтен өмет синдә, Линарның үлгән көнен хәбәр ит, зинһар!» Юк инде! Мондый хыянәт кичерелми! Алар бит үзләре өчен бердәнбер кадерле кешенең кайда җирләнгәнен дә белми! Чаллыда дип гоманлыйлардыр, бәлки. Ә менә авыл зираты турында башларына да китермиләр.

Мәчеттә – кабыкка салып юып, йоласын үтәп, ак кәфенгә төреп, мулла җеназа намазын укыганнан соң, көндезге уникедә мәетне кабат юлга алып чыгып киттеләр. Әнә шулай, урау юллар аша ул туган авылына кайтып китте. Анда әзер булып көтеп торалар иде инде.

Бәхетлеме ул, бәхетсезме? Ундүрт-унбиш яшеннән әти-әни куенынннан чыгып киткән үсмер малай, дөнья гизеп, җир читенә җитеп, озын бер гомер юлы үтеп, бабай булып бакыйлыкка күчкәч, кендек каны тамган җиргә, әти-әнисе яткан туфракка кайтарып җирләнсен әле! Монысы да очраклы гына түгелдер. Шулай язган булгандыр. Бәхете гел юк түгел икән әле. Башка җирдә, чит туфракта аны шулай кадерләп соңгы юлга озатырлар идеме икән – анысы билгесез.



Фото интернеттан алынды

МӘХӘББӘТ ХАТЛАРЫ

Асия
СӘГЫЙТОВА

ЭЛЕК ЗАМАНДА ХАЛЫКТА ХАТ ЯЗЫШУ, ХАТ АЛЫШУ КУЛЬТУРАСЫ БАР ИДЕ. УЛ ХАТЛАР КАДЕРЛЕ БЕР ЯДКАРЬ БУЛЫП САКЛАНА ТОРГАН ИДЕ.



Диңгез буенда җәйрап ял иткәндә бер борчу-мәшәкатең калмый. Әйбәт кенә урыннан такта ятак хәстәрләп, шуның өстенә зур сөлгеңне җәеп куясың да, диңгезнең шифалы суы белән сихәтле кояш нурын нәүбәтләп кабул итеп, рәхәтләнеп ятасың. Төрле су өсте аттракционнарына исең китмәсә, кызыкны янәшә-тирәдән күзлисең. Ял итүчеләрне күзәтеп ятуның үзгә бер хозурлыгы. Ял итәргә килгән кеше дөньяга ачулы булмас, шуңа күрә тирә-юнендәгеләр белән теләп аралаша. Таныша, ят кешене үз дөньясына һич шикләнми кертә. Инде ял иткәндә дә һаман сагайсаң...

Мин дә күзәтергә яратам. Иң әүвәле килеш-килбәтләренә, үз-үзләрен тоту рәвешләренә карап, яр буендагы халыкның милләтен ачыкларга тырышам. Әллә нинди бер сөйкемле сөякләреннән үзебезнекеләрне – татарларны танып алсам, аларның илнең кай төбәгеннән килү ихтималын фаразлыйм. Себердәнме, Бардаданмы, Башкортстаннанмы, Оренбургтанмы – моны мин шивәләренә, сөйләшләренә карап тиз чамалыйм. Тик менә Татарстан татарлары да хәзер себер татарына әйләнеп бара – нефть белән газ йөртә безнең халыкны читтә!

Күрше ятакка килеп урнашкан бу ханымнар – Татарстаннан. Берсенең исеме Людмила. Зәй керәшене

инде бу. Икенчесе дә аның якташы – Чаллыдан. Анысы Зөләра исемле икән. Яннарында гына алар телен бик яхшы аңлаучы апалары барын искәрмичә, әллә исләре китмичәме, сайрашалар гына болар. Монда килгәч танышканнар. Әле тагын берәр атна ял итәселәре бар икән. Төрек сәүдә агентларына ияреп, көн товарлар карарга да барып кайттылар. Кичләрен була торган танцыларга йөрмиләр икән. Икесе генә аралашып, серләшеп йөрү дә җитә боларга. Күренеп тора: чын-чыннан дөнья тоткасы болар үзләре эшләгән җирдә. Ирләренә ышыкланып яшәгән хатыннар бөтәнрәк була ул.

Хәзер инде мин ханымнарның эш-шөгылен ачыкламакчы булам. Менә бит – миңа да бер дигән шөгыль. Журналистка кызыклы язмыш хикәятләре аулау үзе бер мавыктыргыч гамәл.

Ачылып китәр әле болар. Ачкычны үзем яратырмынмы, әллә алар сөйләшкәннән дә ни дә булса табыш аулармынмы. Икенче вариант оеша төште. Бер көнне өлкәнрәге – һәр мәсьәләдә нокта сүзне үзе әйтергә тиеш дип уйлый торганы – кинәт кенә әйтеп куйды: «Хәзер менә смс та смс! Безнең заман – хатлар заманы иде. Минем монда рәхәтләнеп ял итеп ятуыма да хатлар сәбәпче. Югыйсә ирем гомер буе бер дә юкка көнләшеп аптыратты. Бер яры ялгызымны җибәрмәде. Икәү барган чагында да: «Ник аңа карадың? Кайда барып килдең? Нигә ул кеше синең белән исәнләшеп үтте?» – дип йөдәтеп бетерә торган иде. Баксаң, хыянәт хикмәтләрен үзе бик яхшы белгән икән.

Тормышларыбыз яхшыра башлагач – минем ирем абруйлы урында эшләде – иске фатирны сатып, яхшырагына күченеп йөрибез. Йөкчеләр чакырып, йорт җиһазының арурагын алып китмәкче булып, ирем ятып ял итәргә ярата торган диванны кузгаттырдым. Диванның ятак өлешен күтәрүләре булды, идәнгә бер өер хатлар сибелде.

– Апа, документларың таралды, җыеп алмыйсыңмы? – дип, эшчеләр, ирен читләре белән генә елмаеп, хатларга ишарәләде. «Документлар» җизнәнеке булып чыкты. Менә ул кайда романтика, менә кайда ул Бразилия сериалы! Минем хәләлем үзенең көн дә эштә күрешә торган секретаре белән хат алышып торган икән. Нигә икәнен аңлый алмый аптыраган идем ул чагында. Тора-бара аңладым. Хатлар бит, гәрчә иремә адресланган булсалар да, ирем белән минем араны бозар өчен махсус язылганнар. Ә теге романтик хыялый, кинолардагыча мәхәббәт утында янам, дип, рухланып яшәгән.

– Люда апа, андый хәлләр була шул ул. Икелемикеле уйланып йөргән ир-атларны сөяркәләре еш кына шулай кызык итәләр. «Синең ирең фәлән белән очрашып йөри» дип, ир кешенең хатынына үзләре үк шалтыратучылар барын да ишеткәнем бар минем. Шуннан соң өйдә тавыш чыга инде. Мут песи сыман тыныч кына йөреп торган ир капкынга кереп каба. Икенең берсен сайларга мәҗбүр була.

– Мин тавыш чыгарып тормадым. Безнең яшьтә аеры-чөере килеп тору файдага түгел. Җизнәгез өстеннән җитәкчеләргә барып та йөрмәдем. Кеше көлдерүнең ни кирәге бар? Башка төрле чишелеш таптым. Сер ачылгач, еллар буе үземнең ирегемне кысып торган йөгәнне йомшарттым. Мине күптәннән ошатып, ошатып кына түгел, яратып йөргән берәү бар иде. Хәзер шул кеше белән ике айга бер булса да очрашып торам. Шулай итеп, минем тормышыма романтика килеп керде. «Син калынайдың», «синең зәвыгың юк», «синең белән кызык түгел» ише комплиментлар гына ишетә торган идем. Хәзер бу кешем мине хатынына үрнәк итеп сөйли икән. Әйе, әйе, мин аның хатыны белән дә дуслаштым. Аларга кунакка барып йөрим. Кыскасы, иремнән үч алудан канәгатьлек кичерәм. Менә мин дә маҗаралы мәхәббәт тоткыны булдым, имеш.

– Диңгезгә дә җибәргән икән әле ирең?

– Диңгезгә җыенуымны белгәч тә ирем каршы төшәргә базмады. Бәлки, аның да никах яңартып аласы килә торгандыр. Карасын инде, миңа барыбер.

Кемнеңдер мине сагынып торуын, көтеп алуын белеп яшәү җан рәхәте икән ләбаса.

– Секретарьшасы белән ул да каядыр җыенадыр әле...

– Юктыр. Секретарь кызның нияте барып чыкмады аның. Хатлар табылу белән, ирем эштән җибәрде аны. Хәзер инде безнең шәһәрдән күчеп үк китте бугай. Серләремне иремнең сеңлесе дә белә. Мине бер дә гаеп итми: «Шул кирәк абыйга. Кадереңне белмәде», – ди. Ирем белән аерылышырга уйламадым да анысы. Оныклар сөябез бит инде. Үзе дә хәзер мут мачыдан назлы песигә әйләнде, миңа тагылып кына йөри.

Людмиланың бу тәүбәсен ишеткәч, хатыннарның яшьрәге кычкырып көлеп җибәрде: «Люда апакаем, минем язмышымны да хатлар пыран-заран китерде бит!» Сөйләми булдыра алмыйм. Югыйсә әнигә дә әйтмәгән идем. Әнием-бәгърем: «Кияү бик әйбәт кеше бит. Никләр генә бозылыштыгыз соң сез?» – дип сораштырып җелегемә үтте. «Минем насыйп ярым түгел ул», – дидем дә котылдым. Ә бу сүзләремдә хаклык бар иде. Чыннан да, насыйп ярым түгел иде ул минем. Безнең Зөбәер белән танышу да очраклы гына, уен арасында гына булды. Берзаман РКБда яттым мин. Нидәндер гемоглобиным төшкән иде. Шуның сәбәбен белә алмый аптырадылар. Ә болай үзем чирләмим кебек. Бөтен сәламәт кеше кебек мин дә хастаханә ишегалдында оешкан караоке җырлаучылар мәйданына чыгам. Активлар бөтен җирдә бар. Кемдер ду китереп биеп ала, кемдер гармун тарта. Мәйданның бер читендә мин басып торам да, икенче читендә аягы гипслы бер егет утырып тора.

Бер көнне теге егеткә өйләреннән гармун китерделәр. Хастаханәгә килеп эләккән авыл егете шул гармуны кулына килеп кергәч, кинәт кенә шаян-җор егеткә

әйләнде дә куйды. Бер кичне әйтә бу: «Әнә теге зәңгәр күзле чибәр кыз җырламаса, гармун уйнамыйм!»

Әллә минем җырлаганымны әйтүче булдымы икән? Кинәт кенә минем үземнең дә җенем уянып китте. «Ә нигә? Җырлыйбыз аны! Тик бу җырның көен уйный алырсың микән?» «Чияләр» дигән җырның чыккан гына чагы иде.

...Кояшка үрелеп, кызара чияләр:
Сез икәү, сез икәү
Бәхетле дияләр...

Җырны гармунсыз гына җырлап чыктым. Егет хәтта гармун белән кушылырга омтылмады да. Йотлыгып мине тыңлады. Яшермим, матур җырлыйм мин. Бер җырлашып утырырбыз әле, җае чыкса...

Шул кичтән соң дуслашып киттек Зөбәер белән. Күңелендә юшкын йөртә икән егет. Авылда яратышып йөргән кызы ул хастаханәдә дәваланган ай ярым вакыт эчендә бер дә килеп карамаган. Шуңа бик эче поша бугай. Үзе сер бирмәгән булып кылана: «Яратам дип йөргәнмен генә, ахрысы. Менә бит синең белән очрашкач, аның образы күз алдыннан томан кебек эреде дә бетте», – ди.

Без аның белән бик аз торып калдык, ләкин шул аз вакытта да бәхетнең ни икәнен татып карадым.

Зөбәернең инде гипсын алдылар. Иртәгә чыгаралар дигән көнне ярып салмасынмы бу: «Мин сине үзем белән алып китәм. Яратасыңмы дип тә сорамыйм».

Ә мин ярата идем инде. Аны яратмаска мөмкин түгел иде. Кызлар, гомумән, ни теләгәннәрен белә, үз ихтыярына буйсындыра ала торган ир-атларны ярата.

Кыскасы – Казан янындагы авылга килен булып төштем мин. Дөресрәге, иярдем дә киттем. И-и, мин беркатлы, мәхәббәт яңартып алу өчен сәбәпче генә булганмын икән ләбаса! Тик моны соңрак кына аңладым. Мине һәр кич янына утыртып җырлату – Зөбәернең иң яраткан, иң рәхәт ялы иде. Ихластан бирелеп тыңлый да аннан мине назлый, иркәли, үбә башлый бу. Шулай матур гына, бәхетле генә яшәп киттек. Унсигезем генә тулган, тәҗрибәсез, садә чагым. Шуңа күрә бөтен эштә Зөбәергә таянам. Таянам гына түгел – сыенам.

Бәхетем Сабан туе көнне кителде.

Без дә чыктык Сабан туена. Зөбәернең мине халык алдында җырлатасы килде: «Минем Зөләрәмне җырлатыгыз!» – дип, үзе барып әйтте Сабантуйны оештыручыларга. Машина әрҗәсен сәхнә иткәннәр иде. Мине шунда күтәреп менгезде. Өстемдә алсу күлмәк иде. Буем зифа, үзем матур. Бәхетле кеше матур була бит ул! Бер менгәч, өч җыр җырладым. Авыл кешеләре дә яшь киленнең җырлавын яраттылар. Бүләк тә бирделәр әле. Шулай итеп, бу авылдагы беренче Сабан туеннан бүләк белән кайттым.

Машина әрҗәсенә миннән соң менеп җырлаган кызның миңа нинди бүләк әзерләгәнен белмәгәнмен әле мин.

Гөлзыя! Гөлзыя! – диделәр, пышын-пышын килделәр. Игътибар итмәдем. Әйтәм бит, яшь идем әле. Сизгерлегем юк иде. Югыйсә Гөлзыя җырлаганда Зөбәернең алмашынып китүен сизеп алган булыр идем. Гөлзыя да бик матур җырлый икән.
Ул җырлаган җырны мин дә элек ярата идем:

Китмә син йөрәкне яралап,
Барыбер әйләнеп кайтырсың...

Ул җырның шушы сүзләре гомерем буе колагымда яңгырый. Китте шул Зөбәер минем куенымнан, китте. Башта Сабан туй көнне йокларга яткач, төнлә аның янымда юклыгын абайладым. Озак кына керми торды бу. Икенче төнне дә югалды. Берсендә түзмәдем, әкрен генә артыннан чыктым. Нишли ул төнлә? Ишегалдыннан чыгып китмәде. Чормага менеп китте бу. Мин дә шыпырт кына баскычтан үрмәләдем. Куйган җиреннән фонарен чыгарды Зөбәер. Түбә кайчысы арасына кыстырган җирдән бер төргәк кәгазь табып алды. Җайлап утырып, укый башлады. Мин, тынычланып, төшеп киттем. Урыныма менеп яттым. Бераздан ирем дә әйләнеп керде. Урында бик озак көрсенеп ятты.

Иремнең чормага йөрүләре тукталмады.

Бер көнне мин түзмәдем. Ирем эшкә китү белән чормага инде мин үрмәләдем. Ниткән төргәк икән ул? Ирем ни-нәрсә укып утыра икән анда? Теге төргәкне таптым. Хатлар! Мәхәббәт хатлары. Тугыз хат! Барысы да Гөлзыядан.

Ярату тулы ул хатларны мин дә укыдым. Гөлзыя белән Зөбәернең бөтен мәхәббәт тарихы узды күз алдымнан. Елый-елый укыдым. Гөлзыя, мөгаен, елый-елый язгандыр. Без бит романтик буын балалары. Ничекләр итеп мин иремнең олы мәхәббәте юлында аркылы ятыйм, ди.

Иремә бөтенесен елый-елый әйтеп бирдем дә әни янына кайтып киттем. Әни мине үгетләп караган иде дә, мин кайтып төшмәдем, ул чагында сәбәбен дә әйтмәдем. Аннары Зөбәернең авылда бер хатын янына йөргәнен кемнәндер ишеткән әни дә: «Яшьсең әле. Берүзеңә берне табарсың әле. Кеше якасын иснәгән ир мәңге ят булып кала инде ул», – дип, үзен дә, мине дә тынычландырды.

Тик Зөбәер нигәдер Чаллыга бик озак килеп йөрде. Хәтта анда эшкә дә урнашты. Әллә мине ярату чын булган иде микән соң? Очрашу эзләп карады. Күрәсең, ул шулай югалтып табарга һәвәс булгандыр. Әмма мин инде ныгыган идем, кайтып төшмәдем. Аның бөгелеп төшеп, хат укып утырган сыны күз алдымнан китмәде.

Зөбәер, бер-ике елдан авылына кайтып, шул Гөлзыясына өйләнде. Бәхетле булгандырмы-юкмы, ә мин менә үкенәм. Безне хатлар гына аерды. Ак тешләрен елтыратып, гармун уйнап һаман төшләремә керә.



Асия
ЮНЫСОВА

КИЧКЕ ИФТАРДАН СОҢ НИЧЕК КАЙТЫРГА ИКӘН ДИП ТОРГАНДА ӘЛЕ БЕРСЕ, ӘЛЕ ИКЕНЧЕСЕ: «ӘЙДӘ МИНЕМ БЕЛӘН», – ДИП ӘЙДӘКЛИ БАШЛАДЫЛАР. «САВАП СИҢА ГЫНА ТҮГЕЛ, МИҢА ДА КИРӘК!» – ДИЕШӘЛӘР...

ӘҖЕР САВАП

Гамәлләрең фәкать саваплы гына түгел, бәлки, игелекле дә булырга тиешле ай шул ул Рамазан ае. Изге Рамазан! Гайбәт сөйләмичә, ямьсезгә карамыйча, нәфесне узындырмыйча яшәүдән ләззәт алып яшәп кала мөэмин мөселман өммәте ураза аенда. Уразасын да кылган гөнаһларыннан арыну, тазарыну, пакьләнү өчен дип тота. Гамәлләре кабул булсын аларның! Югыйсә шулай матур итеп яшәү елның һәр фасылы өчен дә хас булырга тиештер ул.

Савап, игелек турында болай да, Рамазан ае кермәгән булса да, язарга ниятем бар иде. Чөнки әҗерсез, рәхмәтсез яхшылык кылганнары өчен битәр, әр сүзләре ишетелгәләп куя. Әҗер савап, вәҗеп савап дигәннәре ни нәрсә соң ул? Риясыз эшләнгән яхшылык – чын яхшылык шул була дип өйрәттеләр безне үскәндә. Халык мәкале дә гел шуны искәртеп торды: яхшылык эшлә дә, суга сал – Халикъ белер, Халикъ белмәсә, балык белер! Кодрәтеннән килгән бирәүнең икенче берәүгә ярдәме беренчесенә җиңеллек китерсә, икенчесенә әҗер савап китерүе дә хак.

Җавапка һичшиксез әҗер күздә тотылган гамәл ничек дип атала икән?

Күрше кызы Карина музыка мәктәбендә укыды. Әти-әнисе аны танылган пианист итеп күрде. Кыз сәләтле булгандыр, чөнки һәртөрле конкурсларда бәләкәйдән катнаша башлады. Әмма ул шук бала музыканы, бигрәк тә пианинода уйнауны бер җәза, хәтта ки каза кебек кабул итә иде бугай. Һәрхәлдә, дәресләрдән азат булу өчен ул такта белән сугып, кулын сындырып



та карады. Кыш көне юеш җәймәгә төренеп балконга чыгып та торды.

Әти белән әни кызларының бу «бәхетсезлекләренә» бик көенәләр иде. Көенмәслекме? Дәрәҗәле генә урыннар биләүче бу икәү тормыш мәгънәсе, яшәү максаты итеп кызларының киләчәк данлы балкышын гына күрәләр иде.

Ничек итсәләр иттеләр, Каринага мәшһүр остаз таптылыр. Бу әбинең шәкертләре танылган музыкантлар иде. Хәзер әби Карина белән генә шөгыльләнәчәк. Тик профессор әби шактый олы яшьтә – ярдәмгә мохтаҗ. Күршеләрем әбине кул очында гына йөртергә керештеләр – якшәмбе саен кунакка алалар. Өенә барып йөриләр. Өен җыештыралар, азык-төлеген илтәләр. Табибка-нигә машинада гына алып баралар... Мин бу ата-ананың бала хакына кылган игелекләрен сөенеп күзәтеп йөрим: әбинең кызыксыз тормышын ямьләделәр ләбаса!

Каринаның холкы үзгәрмәде. Ул һаман шулай шаян, шук! Профессорның сабакларын өйрәнгәндәй итә дә, конкурс көне килеп җиткәндә генә берәр шуклык эшләп, сафтан чыга. Ата-ана биреште. Ташлады кыз музыканы. Әмма әбине карау тукталмады. Хикмәт музыкада булмаган икән бит. Музыкалы уйнау нечкә күңелле, талантлар хакына дөньясын онытырга әзер әбинең йөрәген яулау булган икән соңгы максат. Йөрәк кирәк! Чөнки әбинең әйбәт фатиры бар, ә менә варислары юк. Ул заманда әле фатирларны мирас итеп язып калдырулар, бүләк итүләр юк иде. Фатирга пропискага кереп урнашасың да, фатир үзеннән-үзе шунда яшәп торучы кешегә күчеп кала.

Инде Каринаны әбигә пропискага кертәбез дигәндә генә, профессорның ерак туганы пәйда булды. Табигый ки, әби варис итеп туганын сайлады. Менә шушы хакыйкать ачылгач, әбинең кунакка килүләре тукталды, хәлен белеп йөрүләргә дә чик куелды. Алай гына да түгел, рәхмәтсез әбине сүз белән каһәрләүләр башланды. Берничә елга сузылган «игелек акциясе» әнә шулай күңелсез тәмамланды. Әле пионер галстугын да салмаган кызыкай: «Фатирын да калдырмагач, нигә кирәк ул безгә?» – дип, өйдә сөйләнгән сүзләрне безгә дә бушатып чыгып китте.

Ә Каринадан менә дигән бизнесмен килеп чыкты. Чит илдән товар ташый-ташый кибетләр ачып җибәрде. Рухланып эшли. Бер фатирын сатып икенчесенә күченгәндә пианиносын да подъездда калдырып китте. Исәп-хисап рәтен бик белә торган кыз булып чыкты ул.

16+

ЧИЛӘГЕНӘ КҮРӘ КАПКАЧЫ

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя... Ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.



Ркаил ЗӘЙДУЛЛА,
шагыйрь;
өйләнгән;
гаилә стажы — 21 ел;
ике бала атасы.

1 Иң элек хатын-кызда нәрсәгә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

— Һәр ир-ат кебек башта буй-сынына игътибар итәм, әлбәттә. Башкача акыл сатсалар, ышанмагыз. Аннары күзенә карыйм. Дикъкать белән карасаң, күбесенең буй-сыны бөтенләй кызыксындырмый башлый. Шулай да бер нәрсәне онытырга ярамый: без язучы да бит әле. Язучының күзе бөтенләй бүтән аның, башкалар игътибар итмәгән нәрсәләргә дә күз төшерә һәм, үзе дә сизмәстән, хәтеренә салып куя. Язганда кирәге чыгарга мөмкин. Хәер, моның өчен әллә ни зур талант та кирәкми бугай. Хатын-кыз, төрле сәбәпләр аркасында үз-үзенә кул селтәмәгән булса, башка җенестәшләреннән аерылып торыр өчен җанын да бирергә әзер. Язучы өчен монда табыш, һи-и... Әлбәттә, бик үзенчәлекле хатын-кызлар да була, монысы аның нәселенә, тәрбиясенә, белеменә бәйле. Бер ишарәсе үк синең күзеңне «бәйләп» куюы мөмкин.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

— Җиңел акыллылыкны... Бу сыйфат хатын-кызга килешеп тора. Гомумән, гафу итәргә-итмәскә мин кем соң әле? Хатын-кызның кайсыдыр сыйфаты ошамый икән, читкәрәк кит. Кач! Инде һаман аралашасың икән, димәк, күнеккәнсең. Иң мөһиме күнегүдә... Кеше тәмугка да күнегә, диләр бит. Шул күнегә белү сәләте кешелек дөньясын саклап калган да, минемчә.

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

— Хыянәтне. Хәер, аңа да күнегүчеләр бар. Яман сыйфатлар кешедә, шул исәптән, хатын-кызда да, күп инде ул. Мәкер, көнләшү, ялган... Әгәр барысын да гафу итми яшим дисәң, бөтенләй яшәмәскә кирәк. Үз-үзеңне яман сыйфатлардан тыя белү механизмын ничек гамәлгә кертергә? Тәңредән курку хисе генә кешене ниндидер кысаларда тота ала. Дәһриләр өчен, әлбәттә, «җинаять кодексы»ның кырыс булуы кирәк. Ләкин югары фәлсәфи биеклеккә, рухи сафлыкка ирешкән кеше бар нәрсәне дә кичерә. Кичерә һәм үз юлы белән китә. Бәндәнең нинди «җимеш» икәнен белә бит ул. Мин андый биеклеккә ирешмәсәм дә, кеше турында бик үк югары фикердә түгел.

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсысы якынрак?

— Мин оригиналь түгел: ир-ат йөрәгенә юл — ашказаны аша. Ач кешенең ачуы яман. Аның өчен бер тузан бөртеге дә ызгыш чыганагы булырга мөмкин. Тук кеше юк-бар белән вакланмый. Шулай да мин хатын-кызны болай икегә бүлмәс идем. Хатын-кыз да, ир-ат кебек үк, уңганга һәм уңмаганга бүленә. Пешерә белгәне җыештыра да белә.

5 Ир кеше өчен хатыны аңа дус та була аламы?

— Бергә-бергә озак яши алсаң, дус кына түгел, ул тумачага әверелә. Шулай ук гомер буена күңелләрендә үзара дошманлык хисе асраучылар да бар. Сиздерми йөрсәң, үтә инде ул. Гомерне әйтүем. Бервакыт Әхәт Гаффарның хикәясе чыккан иде. «Хатыным һәм дустым Фәридәгә» дип багышлаган. Ул чакта миңа бу бик сәер булып тоелды. «Хатын» төшенчәсе бүтән терәүләргә мохтаҗ түгел югыйсә. Чехов әйтмешли, «жена есть жена».

6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганны хәтерлисезме?

— Нинди тәкъдим? Ә-ә, өйләнергә! Мин аны урлап кайттым. Мин бит соң өйләндем. Утыз ике тулып килә иде. Авылга кайткан саен әнәй колак итен ашый: кайчан өйләнәсең, янәсе. Ә егерме биш яшьләрдән соң өйләнәсе бик килми... Ләкин әнәй битәрләве... «Өйләнәм!» — дидем Яңа елга кайткач. 1994 елга керергә дип сәгать курантлары сукканда урлап кайттым бакча күршесе булган яшьтинең сеңлесен. Ярты сәгать тә үтмәгәндер, яшьти үзе дә килеп җиткән. Ул әле үзе дә өйләнмәгән иде, әллә шуңа кәефе кырылган... Сеңлесен чакырып чыгарды: «Ихтыярыңнан башка урладымы?» — дип сорый. «Үз ихтыярым белән урлады», — дип җавап бирде сеңлесе, ягъни минем кәләш. Яшереп тормыйм, абыйсы әллә алып китәргә җыенамы,

дигән нәни генә өмет тә кузгалып алган иде күңелдә. Тик ул тынычланып кайтып китте. Шула-ай... Бар иде яшь чаклар, утыздан ашкан дәверне яшь чак дип атасаң инде... Кыз урлау! Бездә шундый гадәт бар иде. Кыз белән килешәсең дә урлыйсың. Уңышлы урлаганмын, күрәсең – әлегә кадәр бергә яшибез.

7 Ир кеше, хатын итеп, әнисенә охшаган кызны сайлый...

– Бу шулайдыр. Тик моны шактый яшәгәч кенә аңлыйсың. Үзең сайлаган очракта, билгеле. Еш кына кыз үзе сайлый бит. Акыллысы аны сиздерми генә. Егет үзе сайлаган кебек оештыра сценарийны. Кыз, әлбәттә, күңеленнән әтисен күздә тота. Хәзер элеккеге җәмгыять сыйныфлашты бит. Монда инде әти-әнинең роле зурая. Алар холыкларының кодаларныкына охшавын теләр микән? Хәер, нәфес җәһәтеннән алар болай да охшаш булачак инде.

8 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар... Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Күләгәдә. Ул инде, бичара, күләгәдә булырга мәҗбүр. Хәзер моңа беркем дә гаҗәпләнми. Кешелек җәмгыяте баштүбән килде бит. Телевизордан күрәбез: Көнбатыш илләренең башкалаларында йөзәр меңләгән кеше гей-парадка чыга. Сабый кызлар, сәхнәгә чыгып, чибәрлек ярышында катнаша. Аларны сайлап алалар. Саный китсәң... Мин морализатор түгел. Һәм мин берни дә үзгәртә алмыйм. Ләкин ир-ат белән хатын-кыз үз урыннарын белми башласа, бу инде Һәлакәтнең башы. Димәк, Ахырзаманга ерак калмаган.

9 Гашыйк булуын башлап хатын-кыз үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Бу яшемдә яхшы карыйм. Тик инде моңа өметләнү үзе үк мәгънәсезлек. Һәр нәрсәнең үз вакыты. Ә гашыйк булган кыз мәхәббәтен белдерергә җаен таба инде ул. Аның арсеналында меңнәрчә ысул. Фатих Хөсни, мәхәббәт тарихын язганда, үзенә хас юмор белән, булачак хатынының чишмәдән кат-кат су ташуын искә ала. Чөнки чишмә юлы ул кунакка кайткан өй каршыннан үтә икән.

10 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә?

– Хатын-кыз ир-атка караганда меркантильрәк, нәфселерәк (Пушкинның «Алтын балык» әкиятен искә төшерегез). Күбесен, тәгаен, ир-атның кесәсе җәлеп итә. Әмма кызларны гына гаеплисем килми. Телевидение, интернет, газеталар – карагыз! – эшләмичә генә матур, бай яшәү турында тоталь пропаганда, коткы уздыра. Шундый пычрак зилзилә эчендә «Тургенев яки Әмирхан кызлары» булып калу мөмкинме? Нишлисең, хатын-кызның җиңел генә бәхетле буласы килә, үз учагын корасы килә. Тик тормыш кино түгел шул.

11 Хатын-кызның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүне көтәсез?

– Мин ихлас! Әйтүемчә, инде мин шактый өлкән кеше, хатын-кыз игътибарын өметләнеп йөрү көлке булыр иде. Җенси игътибар турында әйтүем. Ә болай игътибар үзегендә буласы килү теләге һәркемдә бардыр инде ул. Сәхнә кешеләрендә, сәясәтчеләрдә ул көчлерәк тә була. Юкка гына аларны публичный һөнәр ияләре дип әйтмиләр бит. Публичный!

12 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр.

– Ир-аты нинди бит?! Чиләгенә күрә капкачы. Хатынының чибәр һәм җәмгыятьтәге югары урыны белән горурланучылар да бар. Нәрсә сөйләп торырга, кол булудан ләззәтләнүчеләр дә еш очрый.

13 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Икесе ике галәмнән дигәнгә ышанмыйм. Бу мине рәнҗетә. Һичшиксез, хатын-кыз ир-атның кабыргасыннан яратылган. Шуңа бер-берсен яхшы аңлыйлар. Ят бер кабырга булмаса инде. Мин хатынның бер сыйфатын гына аңламыйм: нигә өй җиһазларын гел күчереп тора ул? Олыгайган саен бу сыйфат көчәя бара. Язу өстәлен мин инде куып җитә алмыйм! Караватка бигрәк тә авырга туры килә. Әле бу якка борып куя ул аны, әле теге якка. Аңламыйм! Юкса, саннарның урынын күпме үзгәртмә, сумма шул килеш кала бит. Мин моны ир-ат буларак тәгаен беләм, ә ул һаман нәрсәгәдер өметләнә. Әлеге дә баягы шул нәфсе галәмәте...

14 Хаклы икәнеңне яхшы беләсең, әмма хатыныңның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный.

– Көндәлек тормышта хатын тәҗрибәлерәк. Кайчакта аның киңәшенә дә колак салырга кирәк. Ләкин үземне хаклы дип санаганда мин беркем сүзенә дә карамыйм. Һәм... еш кына хаксыз булып чыгам.

15 Ир кеше ачыгып, арып-талып эштән кайтып керә, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатын, мин арыдым дип, диванда кырын ятып тора...

– Арып-талып, соң кайтканда, гадәттә, тамак тук була...

Җитди әйткәндә, тату, бер-берсен аңлап яшәгән гаиләләрдә мондый вак-төяк проблемаларга игътибар итмиләрдер. Бик ачыккан икәнсең, тиз генә йомырка кыздырып алып та була. Төнгә каршы ашамасаң, тагын да яхшырак.

16 Берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан...

– Хатын-кызның җыенганын көтүдән һәм кием кибетендә бергә йөрүдән дә зур җәза юк чын ир-ат өчен. Ләкин бу котылгысыз хәл. Кул астында һәрвакыт китап булырга тиеш (мондый чакта электрон варианты да ярый). Китап укырга яратмыйсың икән (бүген гадәти хәл!), мин башкаларны үземә хас булмаган сабырлыкка өндим!

Беренче шәмаилен Юлия сыйныф җитәкчесенә бүләккә дип чиккән булган. Шуннан бирле, менә инде ничә ел, шәмаилләр чигә ул. Әнисеннән күреп, 16 яшьлек улы да бу эш белән мавыгып киткән. Юлиянең шәмаилләре Екатерина Гоголева иҗат иткән әзер схемага нигезләнеп чигелгән. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәднең исеме язылган бу шәмаилнең сызымы да — Екатерина иҗаты. Журнал битендә аны тулысынча бирү мөмкинлеге булмаганлыктан, лалә чәчәге өлешен генә бирәбез. Схеманы тулысы белән сайтыбыздан таба аласыз.





Мастер-классны Юлия МАТВЕЕВА үткәрә.

ГАЕТ БҮЛӘГЕ

Кирәк:

• буе – 47 см, иңе 26 см булган канва. Без «Аида-14» дигәнен кулландык. «Аида-11» дигәнен алсагыз да була;
• 10 нчы санлы 50 г алсу һәм 50 г яшел сәйлән (чех сәйләне);
• 12 нче санлы сәйлән энәләре;
• армирланган нык җеп. Ул ак төстә яки сәйлән төсенә ярашлы булырга мөмкин.

Канва үлчәменә туры килгән киерге. Андый киерге булмаса, рәсем кысасы да ярый.

Эш барышы:

■ иң элек канваны чигү өчен әзерләргә кирәк. Безнең канвага кибеттән алганда ук 10 шакмак саен эз салынган иде инде. Сезнеке алай тамгаланмаган булса, канваны һәр 10 шакмак саен башта буйга, аннан соң аркылыга машина җөе белән эре атлатып тамгалап чыгарга кирәк. Эз салгач, канваны яхшылап үтүклибез, чөнки чиккәннән соң аны үтүкләп булмаячак.




■ Шәмаилне канваның кыл уртасын табып, уртадан чигә башлыйлар. Схемада уртадагы шакмак ук белән күрсәтелгән. Өстәге ук – буйга бөкләнешнең уртасы, сул яктагы ук – аркылыга бөкләнешнең уртасы.



■ Бер терсәк буе җеп кисеп алып, энәгә саплыйбыз. Җепнең очын төенләмибез.

■ Чигү тәртибе болай: энәне тиешле шакмакның аскы яктагы сул почмагыннан уң якка чыгарып, сәйлән эләктерәбез һәм шакмакның өске уң почмагыннан сул якка тартып алабыз. Җепнең сул якта калган очын яңа атламнар белән «бастырып» барабыз. Рәсемгә карагач, аңлашылыр ул сезгә.



■ Шәмаилне астан өскә таба да, сулдан уңга таба да чигәргә була. Без астан өскә таба чиктек. Рәсемдә чәчәкнең сабак өлешен чигү тәртибе күрсәтелгән.

■ Чигүне төгәлләгәч, җепнең очын төенләмибез, ә энәне сул якка чыгарып, җеп очын элгәреге атламнар астыннан уздырабыз. Рәсемдә җеп очын ничек итеп яшерергә кирәклеге күрсәтелгән.

■ Иң соңыннан канваны шакмакларга бүлгән җепне нечкә ыргак белән эләктереп, тартып алырга кирәк. Ул бик җиңел генә суырылып чыга.

■ Чигеп бетергәч, шәмаилне матур кысага куябыз.

Кадерле укучыларыбыз! Барыгызны да Рамазан гаете белән тәбрик итәбез. Бәйрәмдә бер-берең бүләк бирешү гадәте бар. Бу шәмаил дә якыннарыгызга бик күркәм бүләк булыр.

Җәй җитте! Елның иң ямьле чорына аяк бастык! Җәй көне күпләребез аклы кием киярга ярата. Эсседә андый кием тәнгә рәхәтен бик рәхәт, әмма тиз керләнә. Бер-ике юсаң, соргылт төскә керә, ямьсезләнә. Төсен җуйган яки җиң төпләре тирдән саргайган кием чынлап та берәүне дә бизәми. Мондый очракта нишләргә?

Кием соры төскә кермәсен өчен:

■ 30 процентлы водород перекисе (аны даруханәләрдә саталар) бик яхшы агарту үзлегенә ия.

Табакка җылы су агызып (30 градустан 60 градуска кадәр), бер бөке чамасы водород перекисе салыгыз. Шушы суга керне ким дигәндә бер сәгатькә, күп дигәндә дүрт сәгатькә батырып тотыгыз. Соңыннан чиста су белән чайкап, кояшка кибәргә элегез. Водород перекисе белән биттәге кара төкләрне дә агарталар;

■ натрий пербораты. Натрий бикорбанатын күпләр белсә дә (чәй содасы), мондыен ишеткәнегез булдымы икән? Аны да даруханәдән сатып алырга мөмкин. Керне агарту процессы водород перекисе белән эш иткәндәге кебек үк. Натрий пербораты 1 литр суга 3 аш кашыгы нисбәтеннән салына. Соңыннан юган керне яхшылап чайкап, кояшта киптерергә кирәк;

■ натрий бикорбанаты (чәй содасы). Керне агарту өчен, ярты стакан соданы машинаның кондиционер сала торган бүлеменә салалар.

Шулай ук ярты лимонның сутын да кушарга була.

Кер саргаймасын өчен:

■ ак күлмәкләрне 1 литр суга 1 стакан коры сөт порошогы кушып та юалар. Саргайган яка һәм җиң очларын менә дигән итеп агарта ул;

■ кер юдырганда машина барабанына кечкенә генә янчыкка төрелгән йомырка кабыгы салып карагыз әле. Соңыннан керне гел йомырка кабыгы белән генә юа башлаячаксыз.

Киемдәге косметика тапларын бетерү өчен:

■ тапларны бит чистарту өчен тәгаенләнгән дымлы салфетка белән ышкырга керешкәнче, иң элек ул урынга салфетканы куеп кына торыгыз, таплы урын чылансын. Менә хәзер ышкып бетерсәгез дә була;

■ савыт-саба юа торган сыекчалар да тапларны яхшы бетерә. Профессиональ визажистлар пумалаларын шуның белән юалар. Күп кенә бизәнү әйберләренең составында майлар була, аеруча төсле кремда, менә шуңа да бу сыекча косметика тапларын «ялап» кына ала.

ТАШКАБАКТАН — «ТОРТ»



Эльмира ИСМӘГЫЙЛЕВА — «Вести—Татарстан» телеканалының корреспонденты. Татарстан яңалыклары белән бөтен Россияне таныштырып баручы Эльмираның әзерләгән тәмле сый-ризыклары белән «Сөембикә» журналының «Хуҗабикә» рубрикасында күренгәне бар инде. Бу юлы ул безне ташкабактан «торт» әзерләргә өйрәтә. Җәй челләсендә дә аппетит уята торган бу сыйны сез дә әзерли аласыз. Бакчаларда ташкабаклар өлгереп килә.



Кирәк:

- уртача зурлыктагы 2 ташкабак;
- 3 помидор;
- 2 тырнак сарымсак;
- 2 йомырка;
- 2-3 зәйтүн җимеше;
- 4 аш кашыгы он;
- 200 г сыр;
- 50 г үсемлек мае;
- 2 аш кашыгы майонез;
- тоз-борыч.

Эш барышы:







■ Ташкабакның кабыгын әрчеп, эре угычтан уабыз. Шуңа 2 йомырка сытып, тәменчә тоз белән борыч сибәбез. Он салып, кашык белән әйбәтләп туглыйбыз.

■ Майонезга вак угычтан уган сыр белән сарымсакны кушып туглыйбыз. Помидорларны исә юка гына итеп тәгәрмәчләп турыйбыз.

■ Шул рәвешле өсте-өстенә биш коймакны да катлам-катлам итеп тезә барабыз.







■ Үсемлек мае тамызылган табага 2 аш кашыгы ташкабак измәсен салып, кашык белән тигезлибез. Зур гына коймак килеп чыгарга тиеш. Коймакның ике ягын да алтынсу төскә кергәнче кыздырабыз. Без шундый 6 коймак кыздырдык.

■ Зур тәлинкәгә бер коймакны салып, өстенә сарымсаклы майонез ягабыз, помидор телемнәрен тезәбез. Помидор өстенә икенче коймакны куеп, шул ук эзлеклелектә сарымсаклы майонез ягабыз, помидор тезәбез.

■ Алтынчы коймак өстенә майонез белән тугланган сыр яккач, помидор телемнәрен тезәбез һәм өстеннән тәгәрмәчләп туралган кара зәйтүн җимешләре белән бизибез. «Торт»ны кайнар килеш тә, салкын килеш тә ашарга мөмкин.

«Ә» дигәнче.

БӘРӘҢГЕЛЕ ЖУЛЬЕН

Бу рецептны җырчы Нурзадә үзе уйлап тапкан. Бик тәмле ул, әзерләве дә ансат кына. Көтмәгәндә кунаклар килеп төшсә, Нурзадә өйрәткән шушы ризыкны сез дә әзерләп карагыз әле.

Кирәк:

- 0,5 кг шампиньон;
- 6-7 бәрәңге;
- 3 баш суган;
- 200-250 г каты сыр;
- 3-4 аш кашыгы майонез;
- үсемлек мае;
- тоз-борыч.

Эш барышы:

■ үсемлек мае тамызылган табага гөмбәне угычтан уабыз. Бу рецептның сере дә шунда: бөтен нәрсә турыдан-туры табага уыла. Бер савыттан икенчесенә күчерсәң, ризык күперенке булып пешми, тыгызлана.

■ Гөмбәле табаны утка куеп, суган турап салабыз. Ярты стакан чамасы кайнаган су өстибез.

■ Гөмбә яртылаш әзер булгач, табаны уттан алып, өстенә бәрәңге уабыз. Тәменчә тоз һәм борыч сибәбез.

■ Бәрәңге өстенә майонез ягып, сыр уабыз. Табаны ярты сәгатькә уртача кызулыктагы мичкә тыгабыз. Ашларыгыз тәмле булсын! Кадерле укучыларыбыз, Нурзадә сезне изге ураза гаете белән котлый. Җан тынычлыгы, тән сихәте теләп кала.



Күп кеше татлы ризыкларсыз яши алмый. Кемнәрдер әчене яки тозлыны ярата. Ә менә зәһәр тәм бер кешегә дә ошамый. Чынында, әче-зәһәр тәмнәр организмга бик файдалы. Әрем белән дәвалауга табиблар гомер-гомергә игътибар күрсәткән. Заманында Әбугалисина да, Гиппократ та бу үләнне үз хезмәтләрендә еш телгә алганнар. Бүгенге көн табиблары да әремне бик әйбәт дәва чарасы дип саный.



ӘРЕМ ИСЕ, ӘРЕМ ТӘМЕ

Әрем чистарта. Безнең эчәклектә файдалы микроблар гына түгел, зарарлылары да яши. Нәкъ менә шулар төрле сырхауларның сәбәбе була ала. Әйтик, бавыр чирләре, псориаз, диатез, аллергия генә түгел, бәлки инфаркт та шул микроорганизмнарның зәхмәте булырга мөмкин. Әрем – эчәклекне чистартырга сәләтле менә дигән үлән. Безнең халык элек-электән кипкән әрем токтан. Җепселле үлән булганга күрә, әрем эчәклектәге утырымнарны да әйбәт куалый.

Дәвалану өчен 100 г әрем алына. Баштагы өч көндә кипкән әремне берәр чәй калагы чамасында өч сәгать саен кабып, әйбәтләп чәйнәгез дә, артыннан су йотып куегыз. Өч көннән соң көнгә дүрт тапкыр гына каба башлагыз. Ашау вакытына яраклаштыруның кирәге юк. Дәвалану курсы – бер атна. Шушы рәвешле дәвалану сезне бабасырдан, суалчаннан, геморройдан, зарарлы бактерияләрдән коткарыр. Мондый чистарынуны елга ике тапкыр кабатларга кирәк.

Шул ук вакытта көнгә ике мәртәбә әрем белән клизма эшләсәң дә әйбәт була. Моның өчен бер литр кайнаган суга 1-2 чәй калагы кипкән әрем алына. Су тән температурасына кадәр суынгач, клизма ясарга була.

Үзенең хасиятләре ягыннан әрем көчле дарулар белән бер рәткә куела. Шуңа күрә тиешле дозаны саклау мәҗбүри. Доза артып киткәндә йокысызлык, бармаклар калтырау, йөрәк кагу, күңел болгану күзәтелә.

Әрем дәвалый. Әремнең бер гаҗәеп үзенчәлеге бар: аның органик составы кеше ашказанындагы үт сыеклыгына тәңгәл килә. Менә шуңа күрә ашказаны асты бизе һәм үт юлы авыруларын дәвалаганда, ашкайнату сүлпән булганда, эч күпергәндә, авыздан ис килгәндә әрем киң файдаланыла. Әрем әчесе эчәклек эшчәнлеген яхшырта, бавырны сәламәт тота. Әрем тәме бик ошап бетмәсә дә, авызга тәм кертә ул.

Шулай ук әрем әчесенең сапониннарга бай булуы да билгеле. Сапониннар эритроцитларны һәм гемоглобинны мускул тукымасына илтә, майларны, аксымны углеводларны үзләштерүне яхшырта, мускулларны үстерә. Әрем кайнатмалары татлы ризыкларга хирыслыкны бетерә. Аның шушы сыйфаты шикәр чирле кешеләргә әйбәт ярдәм итә.

Даруы исә болай ясала: ике аш кашыгы әрем вагын эмаль савытка салыгыз да, бер стакан кайнап кына чыккан суны шуның өстенә коегыз. Капкач каплап, икенче бер сулы савытка утыртып, 15 минут кайнатып алыгыз. Суытыгыз, сөзегез. Кайнаган су өстәп, кайнатманың күләмен 200 граммга кадәр җиткерегез. Әзер даруны суыткычта ике көн сакларга ярый. Ашарга 30 минут кала, көнгә өч мәртәбә чирек стаканлап эчеп куегыз. Дәвалау курсы ике атнадан артмасын. Ике атна тәнәфестән соң, дәвалануны кабатлагыз.

Онытмагыз!

■ Әремнең спиртлы төнәтмәләре агулы була. Суда әзерләнгән әремдә агулы матдәләр булмый диярлек.

■ Әрем төнәтмәсе – бик көчле дару. Кайбер очракларда, әйтик, ашказаны-эчәк трактын дәвалаганда, нәтиҗәсе сизелерлек була.

■ Йөкле һәм бала имезүче хатыннарга, ашказаны җәрәхәте, гастрит борчыганда, әчелек түбән очракларда, үт куыгында таш кузгалганда әрем белән дәваланырга ярамый. Энтероколит, астма чирләреннән дә табиб күзәтүе астында гына әремнән файдаланырга мөмкин.


КУЧКАР. Уйламаган җирдән эшләрегез җайланып китәчәк. Яңа эшкә тотынсагыз, ахыры бик уңышлы булачак. Ярдәм тәкъдим итәләр икән, кабул иткәнче, ныклап уйлагыз. Шул ярдәм аркасында кемгәдер кабалага төшүегез бар.


ҮГЕЗБОЗАУ. Көтелмәгән сюрпризлар ае. Үзегез дә белмәгән сәләтегез ачылып китәр. Ай ахырына таба башкарган эшләрегезгә үзегез үк башкача бәя бирәчәксез. Бу исә хезмәт юлыгызны бөтенләй яңа юнәлешкә алып кереп китәргә мөмкин.


ИГЕЗӘКЛӘР. Тормышыгыз чишмәдәй ургып, кайнап торачак. Үзегезне җиңүче итеп хис итәрсез. Яңа тәкъдимнәр дә күп булыр. Әмма барысына да риза булмагыз. Ай ахырында күңелегезне күтәрердәй яңалык көтелә.


КЫСЛА. Эчке сиземләүгә ышаныгыз. Аны тыңласагыз, оттырмассыз. Хезмәтегезгә бәйле яңа идеяләрне тормышка ашыру өчен илһам килер. Эшләрегезне кичектермәгез, соңыннан аларны башкарырга көчегез калмавы ихтимал.


АРЫСЛАН. Айның беренче яртысы ыгы-зыгылы булырга охшаган. Күп кенә ниятләрегез тормышка ашмый калыр. Эшегез күп, ялга чыксагыз да, алар сезгә тынгы бирмәс. Айның икенче яртысында хәлләр яхшырачак.


СӨМБЕЛӘ. Ял итү, аралашу өчен менә дигән ай. Ниһаять, иркенләп, бөтен эшләрне онытып, ял итү форсаты туар. Эшләрегез үз җае белән барыр. Айның икенче яртысы шатлыклы вакыйгаларга бай. Бик кызыклы яңа танышыгыз килеп чыгар.


БИЗМӘН. Еллар буе бер дә кирәкмәгән эш белән мәшгуль булып, инде тормышны үзгәртергә вакыт җиткәнен тоярсыз. Ләкин барысын да бер селтәнүдән себереп ташларга ашыкмагыз. Идеяләрегез күп, әмма аларны тормышка ашыруы җиңел түгел.


ЧАЯН. Алдан ук план корып яшәсәгез, бик күпкә ирешерсез. Күптәнге хыялыгызның тормышка ашуы ихтимал. Ниятләрегезне сөйләп йөрмәгез, кеше сүзенә карамый гына алга баруыгызны дәвам итегез.


УКЧЫ. Тормышыгызга һәркем кызыгырлык. Ни теләсәгез, шул тормышка ашар. Эштә дә зур уңышларга ирешерсез. Читләрнең киңәше сезнең өчен файдага булмас, эчке сиземләүгә колак салыгыз.


КӘҖӘМӨГЕЗ. Айның беренче яртысы эш белән узар, икенче яртысында рәхәтләнеп ял итү җае чыгар. Әмма ерак сәфәргә кузгалмавыгыз хәерле. Ниятләрегез тормышка ашмый кала дип тә кайгырмагыз, уңышлы вакыт алда булачак әле.


СУКОЯР. Уңышлы ай. Җитди вакыйгалар көтелми. Әз-мәз авырлыклар килеп туса да, аларны бик җиңел хәл итеп, дәрәҗәгезне генә күтәрәчәксез. Ай ахырында хисләрегезнең тулып ташуын тоярсыз, үзегезне кулда тоту зарур.


БАЛЫК. Финанс мәсьәләсендә тотрыклылык көтелә. Хезмәт баскычы буенча югары күтәрелерсез. Үзегез өчен бик тә файдалы тәкъдим булыр, аны кабул иткәнче, шул өлкәне белгән кеше белән киңәш-табыш итегез.

ИЮЛЬдә кабынган йолдызлар

Татарстан



Зифа Басыйрова (4.07.1910–7.02.1979) – **җырчы, Татарстанның атказанган артисткасы.**
Мөслим районы Мөслим авылында туа. 1936 елда Казан театр училищесын тәмамлап, 20 елга якын Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында эшли. Талантлы драма артисты булып таныла. Оркыя Ибраһимова белән иҗади берләшеп, халык көйләрен баянга җырлауның искиткеч үрнәген күрсәтә. «Су буйлап», «Өй артында шомыртым», «Дөм-дөм», «Шөгер», «Таң атканда» һәм башка бик күп моңлы, халыкчан җырларыбызны тамашачы беренче тапкыр аның башкаруында отып ала. 1956 елдан Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә эшли. Ике мәртәбә «Хөрмәт билгесе» ордены, күпсанлы медальләр белән бүләкләнә.

Россия



Клара Лучко (1.07.1925–26.03.2005) – **СССРның халык артисты.**
Украинада туа. Сугыш башлангач, гаиләләре белән Казакъстанга эвакуацияләнәләр. Мәктәпне тәмамлаган елны ВГИКка студентлар җыйганнарын ишетеп, Мәскәүгә хат яза. Әнисенең каршы булуына карамастан, 1943 елны шунда укырга керә. Зур экранга беренче тапкыр «Молодая гвардия» фильмындагы Марина түти роле белән чыга. 1950 елда «Кубанские казаки» фильмында уйнаган роле өчен II дәрәҗәдәге Сталин премиясенә лаек була. Ә иң зур уңышны 1979 елда «Цыган» фильмында уйнаганнан соң казана. Кинога төшү белән бергә, ул Киноактер үзәк студиясе сәхнәсендә дә уйный. 2002 елда аның үзе турында язган «Виновата ли я?» китабы басылып чыга.

Чит илләр



Хелен Миррен (26.07.1945) – **актриса.**
Лондонда туа. Чын исеме – Елена Васильевна Миронова. Бабасы Петр Миронов патша армиясе полковнигы була. Англиягә революциядән качып китә. Хеленның актерлык карьерасы атаклы Old Vic театрында куелган постановкаларда катнашудан башлана. 60 нчы еллар ахырында ул Шекспир Король театры труппасында уйный башлый. Зур танылу аңа «Калигула» һәм «Террорист көндәлеге» фильмнарыннан соң килә. 2006 елда «Шаһинә» («Королева») фильмында Елизавета II булып уйный. Бу роле өчен «Оскар» премиясенә лаек була. «Дөнья киносына керткән өлеше өчен» 2012 елда аңа Европа киноакадемиясенең премиясе тапшырыла. «Дан аллеясы»нда Хелен Мирренның да йолдызы бар.







ДҮРТ ФАСЫЛ ҖӘЙ

Рәсемнәренә беренче юлыккач, туган тойгы: өйгә кайту. Сүз туган нигез, Ватан турында бармый. Җанның вакыт һәм чиксезлек кырыннан ирекле булган яссылыгын, тәңгәллеген табуы дисәм, дөресрәк булыр.

Аның киндерләрендә дүрт фасыл буена Җәй яши. Хәтта кышкы пейзаж, натюрмортларында да. Әйтерсең, киндер түгел, ә куе, кызгылт-сары бал белән тулы кәрәзләр. Һәм ул бал синең күңелеңдәге кәрәзләргә салмак кына саркыла. Җылыта. Аларда вакыт-вакыт Густав Климт картиналарыннан кубарылып төшкән алтын кабырчыклар да сиземләнә.

Ольга Сушкованың картиналарын фотокәгазьгә төшереп, өемдәге аш бүлмәсе диварларына элдем. Кышкы озын кичләрдә мәтрүшкә, бөтнек, гөлҗимеш, киптерелгән кура җиләге салып пешергән хуш исле чәйне бизәкле юка чынаякларга агызам да, аякларымны бөкләп урындыкка менеп кунаклыйм һәм аның картиналарыннан сирпелгән алтынсу нурда коенам.

Без үзебезнең климатта озын Кышны ярым уяу-ярым йокылы халәттә уздырабыз бит. Җәйне сагынып. Җылыга сусап. «Төш» картинасында нәкъ менә шул күзгә бәрелә: тәрәзә артында бауга элгән керләр, күләгәләр яткан зәңгәрсу кар, салкын буяулар, ә киндернең икенче өлешендә – алтынсу-кызыл җылылык.

Аның дөньясы – хатын-кызларның мең төсмерле кичерешләр гаммасыннан торган мозаика. Әби-бабайлардан килгән гадәтләр, йолалар, без акрынлап югалта барган салмак, тынычлык, булганына шөкер итеп яши белгән тормыш тукымасы бу. Монда ханымнар, Вакытны ашыктырмыйча гына, нарасыен көтә, тирбәтә, имезә: көзгедәге сурәтен барлый, кое янында тукталып, уйларын тәртипли. Ачык калган китап-дәфтәр битләрен ефәк җил җилфердәтә. Өстәлдәге гөлсарда тере чәчәкләр кинәнеп утыра. Хәтта «Яңгыр» картинасындагы караңгы фондагы ялгызлык та чын мәгънәсендә дөм ялгызлык түгел. Ул ашъяулыкның чуар бизәкләрендә «укылган» өмет, көтү халәтенә һәм гөрләп чәчәккә баткан сирень белән сердәшлеккә манылган.


Россия рәссамнар берлеге әгъзасы Ольга Сушкова Казан сәнгать училищесын кызыл диплом белән тәмамлый, Дрездендагы Югары сәнгать мәктәбендә профессор Ральф Кербах классында дәресләр ала. Эшләре Россиядәге, Украина, Алмания, Швейцария, АКШ, Франция, Австралия, Эстониядәге шәхси коллекцияләрдә саклана.

Аның дөньяга карашында балалык чорыннан калган яктылыкка, самимилеккә, яратуга урын бар.

– Һәркемнең картиналар язар өчен үз сәбәпләре табыла. Алар күп. Минем очракта бу сәбәп – иң беренче чиратта тойгы-кичерешләрне искә төшерергә, кайтарырга омтылу, – ди Оля үзе. – Рәсемнәремә мотивны мин як-ягыма күз ташлауга табам – яктылыкның ничек уйнавын күреп, ел фасылларының алмашуына шаһит булып. Һәм һәр утырган саен киндеремне балачак тәэсирләре, кичерешләре белән өртәсем килә. Без сабый чакта тирә-юньгә тылсым вәгъдә итүче тынлык җәелгән иде бит. Минемчә, хәзерге тормыш шаукымында безгә шул тынлык һәм гадилек җитми...

Луиза ЯНСУАР





ОЛЬГА СУШКОВА



МАССАКҮЛӘМ МАТБУГАТ ЧАРАЛАРЫ БӘЙГЕСЕ



ЛЕГЕНДАЛАРНЫ БЕЛЕГЕЗ!
БРЕНДЛАРНЫ САЙЛАГЫЗ!

татмедиа

ЛЕГЕНДАР БРЕНДЛАРЫ

TATMEDIA.RU САЙТЫНДА
ТАВЫШ БИРҮДӘ КАТНАШЫГЫЗ



ДҮРТ НОМИНАЦИЯДӘ ТАВЫШ БИРЕРГӘ МӨМКИН:

- ЛЕГЕНДАР **ГАЗЕТА**
- ЛЕГЕНДАР **ЖУРНАЛ**
- ЛЕГЕНДАР **ТЕЛЕРАДИОКОМПАНИЯ**
- ЛЕГЕНДАР **МУЛЬТИМЕДИЯЛЕ РЕДАКЦИЯ**

TATMEDIA.RU — татмедиа

Реклама, 16+. Акцияне оештыручы – "ТАТМЕДИА" АҖ. Үткәрү сроклары һәм акция турында тулырак мәгълүмат www.tatmedia.ru сайтында.



КОНКУРСНЫҢ ГЕНЕРАЛЬ ПАРТНЕРЫ:
«ПРОСТО МОЛОКО» ИК ҖЧҖ

ЯРАТКАН ЖУРНАЛЫБЫЗ ӨЧЕН ТАВЫШ БИРЕРГӘ СОҢЛАМАГЫЗ!
«СӨЕМБИКӘ» ИСЕМЕН БЕРГӘЛӘП ТАНЫТЫЙК!